**Рецензия**

на сборник методических разработок «Яратыгыз туган илебезне Яратыгыз туган җиребезне...” МБДОУ детский сад «Миляуша» села Терси Агрызского МР Республики Татарстан; МБДОУ «Детский сад № 107» Ленинского района города Ижевска Удмуртской Республики

Авторы составители:

*Юсупова Лейсира Наилевна*, воспитатель ммуниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад № 107» г. Ижевска УР;

*Давлетбаева Рузиля Нуршаеховна,* учитель начальных классов муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения Терсинская средняя общеобразовательная школа Агрызского муниципального района Республики Татарстан;

*Нурмеева Лилия Ильясовна, Саитова Наталья Алексеевна, Уразаева Расиля Расимовна, Хакимова Алсу Разимовна, Ибатуллина Ильсина Хамитовна, Закирова Гульшат Фирдависовна, Губайдуллина Филиса Рамзиевна,* воспитатели муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения - детский сад №1 «Золотой ключик» города Агрыз Агрызского муниципального района Республики Татарстан;

*Залилова Гульнара Рафисовна, Васильева Фарида Мирсаетовна, Шайхиева Гульсина Мансуровна,* воспитатели муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения детский сад «Миляуша» села Терси Агрызского муниципального района Республики Татарстан;

*Рамазанова Гульчачак Мусавировна,* воспитатель муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения Кадыбашская средняя общеобразовательная школа Агрызского муниципального района Республики Татарстан;

*Ягьфарова Гульназ Гамировна,* заведующий муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения детский сад

«Миляуша» села Терси Агрызского муниципального района Республики Татарстан;

*Гараева Флюра Миннефаизовна*, заведующий муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения детский сад «Теремок» села Красный Бор Агрызского муниципального района Республики Татарстан.

Федеральный государственный образовательный стандарт (далее ФГОС) дошкольного образования указывает педагогам на необходимость поиска современных образовательных технологий, и средств развития ребенка, применение различных образовательных технологий и методик, которые способствуют приобщению детей к истокам народной культуры, любознательности, активности; овладение средствами общения и способами взаимодействия с взрослыми и сверстниками.

В настоящее время актуальность проблем, связанных с нравственно-патриотическим воспитанием детей, приобретает чрезвычайную значимость. Современные дети мало знают о родном городе, стране, особенностях народных традиций, часто равнодушны к близким людям, в том числе к товарищам по группе, редко сострадают чужому горю. Явно недостаточной является работа с родителями по проблеме нравственно-патриотического воспитания в семье.

В связи с этим становится очевидной потребность в создании новых моделей организации работы по нравственно-патриотическому воспитанию детей, поиске инновационных подходов и технологий

.Данное пособие предполагает широкий выбор деятельности, инициативу, творчество, поиск его участников.

*Задача педагогов и родителей* – как можно раньше пробудить в детях любовь к родной земле, формировать у них такие черты характера, которые помогут стать достойным человеком и достойным гражданином своей страны, воспитывать любовь и уважение к родному дому, детскому саду, родной улице, городу формировать чувство гордости за достижения страны, любовь и

уважение к армии, гордость за мужество воинов, развивать интерес к доступным ребенку явлениям общественной жизни.

Мировоззрение педагога, его личный пример, взгляды, суждения, активная жизненная позиция – самые эффективные факторы воспитания. Поэтому реализация данной работы в практике дошкольного воспитания позволит разработать целостную систему нравственно-патриотического воспитания дошкольников. Создана авторская модель, в центре которой все участники образовательного процесса – дети, их родители, педагоги ДОО.

Оригинальность пособия в том, что педагог находит инновационные подходы в организации данной работы и активно взаимодействует с педагогами и родителями воспитанников. Грамотно сформулированы задачи, содержательные методические материалы, в том числе планирование по темам, презентации по теме для детей и коллег с целью рассмотрения опыта, другой практический материал.

Данное методическое пособие «Яратыгыз туган илебезне  Яратыгыз туган җиребезне...”  составленное авторами  МБДОУ детский сад «Миляуша» села Терси  Агрызского МР Республики Татарстан;  МБДОУ «Детский сад № 107» Ленинского района города Ижевска Удмуртской Республики  соответствует требованиям, предъявляемым федеральным государственным образовательным стандартам дошкольного образования. Все перечисленное дает основание достойно оценить работу и рекомендовать в ДОО для использования в работе педагогам.

Рецензент: кандидат филологических наук,
доцент кафедры татарской  филологии
Елабужского института КФУ __________ А.С.Хайруллина

**Татарстан Республикасы**

**Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы**

**муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.**

**Удмуртия Республикасы**

**Ижау шәһәре Ленин районы “107 номерлы “Энҗе” балалар бакчасы”**

**муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.**

**Әхлакый – патриотик тәрбия һәм белем бирү буенча**
**мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләренә,**
**башлангыч сыйныф укытучылары өчен методик җыентык.**

# “Яратыгыз туган илебезне
# Яратыгыз туган җиребезне...”



**Тирсә авылы.**

**2023 ел.**

**Баш мөхәрирләр:**

*Ягьфарова Г.Г.,* Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, мөдир.

*Абдрахманова Б.Р.*, Удмурт Республикасы Ижау шәһәре Ленин районы “107 номерлы “Энҗе” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, мөдир.

**Автор - төзүчеләр**:

*Шайхиева Г.М.,* Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, тәрбияче.

*Йосыпова Л.Н.,* Удмурт Республикасы Ижау шәһәре Ленин районы “107 номерлы “Энҗе” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, тәрбияче.

**ЭЧТӘЛЕК.**


| | | |
|---|---|---|
| 1 | Аңлатма язуы | 4 |
| 2 | Йосыпова Ләйсирә Наил кызы. Мәктәпкә әзерлек төркемендә шөгыль конспекты “Ижау буйлап сәяхәт”.<br>. | 7 |
| 3 | Дәүләтбаева Рузилә Нуршаех кызы. 1 нче сыйныф укучылары өчен сыйныф сәгате “Тынычлыкның кадерен белик!”. | 9 |
| 4 | Нурмеева Лилия Ильяс кызы. Зурлар төркемендә әхлакый –патриотик тәрбия белем бирү эшчәнлеге конспекты “Яратыгыз туган җиребезне, яратыгыз туган илебезне”, | 12 |
| 5 | Җәлилова Гөлнара Рафис кызы. Зурлар төркемендә уен конспекты «Минем Ватаным – Татарстан»,. | 15 |
| 6 | Сәитова Наталья Алексей кызы. Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты “Дөньяда Ватаныбыздан да матуррак нәрсә юк”. | 18 |
| 7 | Уразаева Рәсилә Рәсим кызы. Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты «Туган илебез, туган ягыбыз». | 21 |
| 8 | Васильева Фәридә Мирсәет кызы. Мәктәпкә әзерлек төркемендә шөгыль конспекты «Кече Ватаныбыз Әгерҗе шәһәренә сәяхәт». | 23 |
| 9 | Шәйхиева Гөлсинә Мансур кызы. Мәктәпкә әзерлек төркемендә шөгыль конспекты “Туган авыл буйлап сәяхәт”. | 27 |
| 10 | Хәкимова Алсу Разим кызы. Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты «9 май – Җиңү бәйрәме» | 32 |
| 11 | Ибәтуллина Ильсинә Хәмит кызы. Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары, ата- аналары өчен “ Шигырьләрем- күңеллем көзгесе” исемле күңел ачу кичәсе сценарие. | 35 |
| 12 | Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы, Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты “Минем гүзәл җирем”. | 39 |
| 13 | Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы. Мәктәпкә әзерлек төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты “Һөнәрле халкым”. | 42 |
| 14 | Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен шөгель конспекты “Чишмә эзтабарлары”. | 44 |
| 15 | Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы. Проект “Туган авылым–Кадыбашым” | 46 |
| 16 | Закирова Гөлшат Фирдәвис кызы. Кечкенәләр төркемендә патриотик тәрбия буенча проект "Батыр солдатларга рәхмәт". | 48 |
| 17 | Гобәйдуллина Филисә Рамзи кызы. Өлкәннәр һәм мәктәпкә хәзерлек төркемендә балалары өчен күңел ачу кичәсе "Яз уята күңел кылларын" | 51 |
| 18 | Ягьфәрова Гөлназ Гамир кызы. Мәктәпкә әзерлек төркемендә проект эшчәнлеге «Кече Ватаныбыз Әгерҗе шәһәренә сәяхәт». | 56 |
| 19 | Ягьфәрова Гөлназ Гамир кызы. Бөек Җиңүнең 78 еллыгына багышланган әдәби кичә сценариясе. | 63 |
| 20 | Гәрәева Флүрә Миннефаиз кызы. 5-7 яшьлек балалар белән патриотик тәрбия бирү буенча шөгыль “Минем кече Ватаным”. | 68 |

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ.

Туган (татар) телдә әхлакый – патриотик тәрбия һәм белем бирү буенча методик җыентык Удмурт Республикасы Ижау шәһәре Ленин районы “107 номерлы “Энҗе” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләре, Тирсә авылы урта мәктәбе укытучыларының тәҗрибә уртаклашу максатыннан төзелде.

Балаларга әхлакый-патриотик тәрбия бирү балалар бакчасында төп максатларның берсе булып тора.

Патриотизм хисе эчтәлеге буенча күпкырлы: туган якка мәхәббәт, үз халкың белән горурлану, үз илеңнең байлыгын арттыру һәм аны сакларга теләк булдыру, җәмгыять һәм Ватан алдындагы гражданлык бурычларын аңлы һәм актив үтәү, ватанпәрвәрлек, кешеләргә һәм табигатькә гуманлы мөнәсәбәт һәм башкалар.

Шулай итеп, әлеге эш бербөтен максатлар комплексын үз эченә ала:

- балада үз гаиләсенә карата мәхәббәт тәрбияләү, шулай ук үз йортына, балалар бакчасына, урамына, авылына (шәһәренә);
- табигатькә һәм барлык тереклек ияләренә сак караш формалаштыру;
- татар (рус һ.б.) халык традицияләренә һәм кәсәбәчелеккә карата кызыксынучанлыкны үстерү;
- кеше хокуклары турында элементар белем формалаштыру;
- Татарстан (Русия һ.б.) шәһәрләре турында күзаллауны киңәйтү;
- хөкүмәт символлары (*герб, флаг, гимн*) белән таныштыру;
- үз республикаңның уңышлары өчен горурлану һәм җаваплылык хисен үстерү;
- толерантлык, башка халыкларга, аларның традицияләренә карата хөрмәт хисе формалаштыру.

Бу максатлар балаларның барлык эшчәнлек төрләрендә үтәлә: шөгыльләрдә, уеннарда, хезмәт эшчәнлегендә, көнкүрештә - чөнки алар балада патриотик хисләр тәрбияләү белән бергә аның өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләрен дә формалаштыралар.

Әхлакый-патриотик тәрбия – катлаулы педагогик процесс. Аның нигезендә әхлакый хисләрне үстерү ята.

Ватан хисе... Балада бу хис гаиләсенә, иң якын кешеләренә - әнисе, әтисе, әбисе, бабасына, апасы, абыйсы, сеңлесе, энесенә карата мөнәсәбәттән башлана. Болар барысы да аны туган йорты һәм якын тирәлек белән бәйләүче тамырлар.

Һәр халыкның үз әкиятләре бар, һәм аларның барысы да нәселдән-нәселгә төп әхлакый кыйммәтне тапшырып киләләр: яхшылыкны, дуслыкны, үзара ярдәмләшүне, хезмәт сөючәнлекне. К.Д.Ушинский рус педагогикасы әдәбиятенә “*халык педагогикасы*” дигән термин керткән. Ул фольклор әсәрләрендә халыкның милли үзенчәлегендә Ватанга мәхәббәт тәрбияләү өчен бай материал күрә.

Шулай итеп, халык авыз иҗаты үз халкының традицияләренә карата мәхәббәт формалаштырып кына калмый, ә шәһеснең патриотик рухта үсешенә ярдәм итә.

Балаларда туган ягы белән кызыксыну, һәм аңа карата мәхәббәт тәрбияләү өчен якын тирәлек тә зур мәгънәгә ия. Әкренләп бала балалар бакчасы, үзенең урамы, авылы (шәһәре), ә аннары иле белән дә, аның башкаласы һәм символлары белән таныша.

Һәр як, өлкә, кечкенә генә авыл да кабатланмый, һәрберсенең үз табигате, үз традицияләре һәм үз көнкүреше. Тиешле материалны сайлап алу балаларга туган ягы нәрсә белән данлыклы икәнен күзалларга ярдәм итә.

Туган авыл... Балага туган авылының үз тарихы, традицияләре, истәлекләре, һәйкәлләре, яхшы кешеләре белән данлыклы икәнен күрсәтергә кирәк. Туган авылы (шәһәре) турында балалар нинди мәгълүмат һәм төшенчәләрне үзләштерергә сәләтле соң?

- 4 яшьлек бала үзе яши торган һәм балалар бакчасы урнашкан урамнар исемен белергә тиеш;
- өлкәнрәк балалар игътибарын якын-тирәдәге урамнарда урнашкан объектларга юнәлтергә кирәк: мәктәп, мәдәният йорты, почта, аптека һ.б., аларның ни өчен кирәклеге турында сөйләргә, барысы да кешеләргә уңайлы булсын өчен эшләнгәнен аңлатырга;
- зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәре балаларын объектлар диапазоны белән таныштыру киңәя – авыл һәм район (шәһәр), гомумән алганда, аның истәлекле урыннары һәм һәйкәлләре. Балаларга һәйкәлләрнең кемгә куелуы аңлатыла.

Балалар үз авылының (шәһәренең), урамының, якын-тирә урамнарның исемнәрен һәм кем истәлегенә аталганнарын белергә тиеш. Аларга һәр кешенең туган йорты һәм авылы (шәһәре) барлыгы аңлатыла. Моның өчен авыл (шәһәр) буйлап, табигатькә экскурсияләр, өлкәннәр хезмәтен күзәтүне оештырырга кирәк. Бала хезмәтнең кешеләрне берләштерүен, алардан көйлелек, үзара ярдәмләшүне, үз эшен белүне таләп итүен аңлый башлый. Балаларны туган якның кәсәбәчеләре, алтын куллы кешеләре белән таныштыру да зур әһәмияткә ия.

Әхлакый-патриотик тәрбиядә өлкәннәрнең, бигрәк тә якын кешеләрнең үрнәге зур роль уйный. Гаиләдәге өлкәннәрнең (*әби-бабайлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, аларның фронттагы, хезмәттәге батырлыклары*) тормышыннан конкрет фактлар аша балаларга “*Ватан алдындагы бурыч”, “Ватанга мәхәббәт”, “Хезмәт батырлыгы”* һ.б. кебек мөһим төшенчәләрне аңлату зарур.

Балага безнең Җиңү үз Ватаныбызны яратканлыктан булуын аңлату мөһим. Кешеләрнең бәхете өчен үз гомерләрен кызганмаган батырларны туган ил онытмый, аларның исемнәре шәһәрләргә, урамнарга, мәйданнарга бирелә, алар хөрмәтенә һәйкәлләр барлыкка килә.

Алдагы бу эшнең дәвамы булып, балаларны Татарстанның, Россиянең башка шәһәрләре, Татарстанның һәм Россиянең башкалалары, аларның гимннары, флаглары һәм герблары белән таныштыру тора.

Балаларда үзенең туган авылына (шәһәренә) карата мәхәббәт тәрбияләгәндә, аларның авылы (шәһәре) – туган илнең бер өлеше икәнлеген аңлатырга кирәк, чөнки һәр урында да күп кенә охшашлыклар бар:

- һәр җирдә кешеләр һәркем өчен хезмәт куя (укытучылар балаларны укыта; табиблар авыруларны дәвалый һ.б.);
- бар җирдә дә традицияләр саклана: ил үз батырларын онытмый;
- һәр җирдә төрле милләт кешеләре яши, бергәләп хезмәт итәләр һәм бер-берсенә ярдәмләшәләр;
- кешеләр табигатьне саклыйлар һәм яклыйлар;
- гомуми профессиональ һәм иҗтимагый бәйрәмнәр бар һ.б.

Гражданин, патриот булу – интернационалист булу да. Шуның өчен үз Ватаныңа мәхәббәт, үз илең белән горурлану хисе тәрбияләү эше башка халыклар культурасына карата, һәр кешегә карата (аның тән төсенә һәм нинди диндә булуына карамастан) яхшы мөнәсәбәттә булуны формалаштыру белән туры килергә тиеш.

Билгеле, төрле милләт кешеләренә карата гуманлы мөнәсәбәт балада иң беренче чиратта әти-әниләр, педагоглар йогынтысы астында барлыкка килә. Бу хәзерге көндә бигрәк тә актуаль, чөнки өлкәннәрнең кайбер өлешендә бу проблема буенча каршы торышлар барлыкка килә. Шуның өчен балалар бакчасында балаларның башка милләт кешеләре белән кызыксынуларын күәтләргә кирәк, теге яки бу милләтнең кайда яшәвен, аларның табигать үзенчәлеге, климат шартлары һ.б. турында сөйләргә кирәк.

Мәктәпкә баручы балалар бакчасы баласы түбәндәгеләрне белергә тиеш:

- безнең илдә төрле милләт халкы яши;
- һәр халыкның үз теле, гореф-гадәтләре һәм традицияләре, сәнгате һәм архитектурасы;
- һәр халык үзенең осталары, музыкантлары, рәссамнары һ.б. белән бай һәм талантлы;

Әхлакый-патриотик тәрбия максатларын үтәгәндә һәр педагог үз эшен җирле шартларга һәм балаларның үзенчәлекләренә туры китереп һәм түбәндәге принципларны истә тотып төзергә тиеш:

- “позитив центризм” (бала өчен актуаль булган белемнәрне сайлап алу);
- педагогик процессның өзлексезлеге;
- һәр балага индивидуаль якын килү, аның психологик үзенчәлекләренең, мөмкинлекләренең һәм кызыксынуларының максималь учёты;
- төрле эшчәнлек төрләренең рациональ туры килүе, интеллектуаль, эмоциональ һәм хәрәкәт йөкләнешләренең яшькә карата тәңгәл балансы;
- эшлекле якын килү;
- балаларның активлыгына нигезләнгән укыту-тәрбиянең үстерешле характеры.

Әхлакый-патриотик тәрбиянең кирәкле шарты булып әти-әниләр белән үзара тыгыз элемтә тора. Хәзерге вакытта бу эш актуаль һәм бигрәк тә авыр, зур такт һәм түземлелек таләп итә, чөнки яшь гаиләләрдә патриотизм, граҗданлык тәрбияләү кебек төшенчәләр мөһим булып саналмау, еш кына аңлашылмаучанлык китереп чыгара.

Билгеле, болар барысы да балаларны туган якның һәм үз халкының тарихына тарта, туган илгә мәхәббәт тәрбияли.

Авторлар коллективы методик җыентык та тәкъдим ителгән материаллар балаларга әхлакый-патриотик тәрбия бирүдә тәрбиячеләргә зур ярдәм булыр дип ышанабыз. Әлеге методик җыентык милли балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, башлангыч мәктәп укытучыларына, педагогик уку йортларында белем алучы студентларга адреслана.

**Мәктәпкә әзерлек төркемендә шөгыль конспекты**
**“Ижау буйлап сәяхәт”**
(Рус телле балаларга татар телен өйрәтү)

*Йосыпова Ләйсирә Наил кызы,*
*Удмуртия Республикасы Ижау шәһәре*
*107 нче балалар бакчасы тәрбиячесе*

**Максат:** туган шәһәргә карата горурлык хисләре булдыру.
**Бурычлар:**
– балаларны рәсемнәргә (слайдларга) карап Ижау шәһәренең истәлекле урыннарын танып белергә өйрәтү өстендә эшне дәвам итү;
- балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтләрен, кызыксынучанлыкларын үстерү;
- татар телендә сүзлек запасын баету һәм кыска җөмләләр төзүне булдыру;
- туган якны ярату, туган җиребезгә, шәһәребезгә, телебезгә, милли уеннарга, гореф-гадәтләребезгә мәхәббәт тәрбияләү.
**Шөгыль барышы**
**Тәрбияче:** Хәерле көн, балалар. Мин сезне күрергә шатмын. Түгәрәккә басыйк, бер-беребезгә сәлам юллыйк. *(Балалар түгәрәккә басалар)*
Кулларны кулга куйдык,
Бер-беребезгә елмайдык.
Җылы китте кулларга,
Рәхәт булды дусларга.
*(Балалар күрше балалар белән кочаклашалар)*
**Тәрбияче:** *(Кыңгырау шалтыратып)* Игътибар, игътибар, бүген безнең тылсымлы кыңгырау сәяхәткә чакыра. Ә кая юл тотачагыбызны табышмакның җавабыннан эзләгез.
Иж буенда урнашкан,
Урман, суга бай булган
Син дә, мин дә яшәгән
Матур, зур һәм бай шәһәр.
**Тәрбияче:** Балалар, нинди шәһәр турында сүз бара?
Кайсыгыз әйтер икән?
**Балалар:** Ижау - шәһәр турында сүз бара.
**Тәрбияче:** Дөрес.Балалар, Ижау буйлап сәяхәткә барабызмы?
**Балалар:** Әйе, бик теләп сәяхәткә барабыз.
**Тәрбияче:** Ә сезнең нәрсәгә утырып барасыгыз килә?
**Балалар:** Безнең автобус, машина, поезд, самолет…барасыбыз килә.
**Тәрбияче:** Никадәр транспорт атадыгыз.Ә сезнең һава шарында очканыгыз бармы?
**Балалар:** Һава шарында очканыбыз юк.
**Тәрбияче:** Минем дә бер дә очканым юк. Әллә соң, һава шарында очып карыйбызмы?
**Балалар:** Әйе, безнең дә очып карыйсыбыз килә.
**Тәрбияче:** Тик без очасы шар гади түгел, ул тылсымлы. Аңарга утырыр өчен биремнәр эшләргә кирәк. Сез әзерме? (*Кыңгырауны шалтырата)*
**Тәрбияче:** Матур, ягымлы сүзләр әйтеп утырсак, бу тылсымлы шар безне Ижау буйлап сәяхәткә илтәчәк. Сез нинди матур, ягымлы сүзләр беләсез?
**Балалар***:* Рәхим итегез, рәхмәт, исәнмесез, сау булыгыз, сәламәт булыгыз, зинһар өчен, хәерле иртә, көн, кич, тыныч йокы…

**Тәрбияче:** Балалар, шарның бауларын ычкындырыйк та һавага күтәрелик. (Слайдта шар күтәрелү күренеше)
**Тәрбияче:** Балалар, без һавага күтәрелдек, башларыгыз әйләнмиме, курыкмыйсызмы? Нинди матур безнең шәһәр! Барыгыз да беләме, без кайсы шәһәрдә яшибез?
**Балалар**: Без удмуртия Республикасы Ижау шәһәрендә яшибез.
**Тәрбияче:** Әнә безнең балалар бакчасы? Ул кайсы урамда урнашкан? *(Экранда балалар бакчасы рәсеме күрсәтелә. Алга таба башка рәсемнәр)*
**Балалар:** Безнең балалар бакчасы Азин урамында урнашкан. Без бакчада уйныйбыз, җырлыйбыз, биибез. Анда безнең дуслар күп.
***(“Цирк” рәсеме)***
**Балалар:** Бу цирк. Минем цирка барган бар. Анда кызык тамашалар була. Циркта күп хайваннар уйный.*(Бала сораулар ярдәмендә дә сөйләргә мөмкин)*
**(“Зоопарк” рәсеме)**
**Балалар:** Ә бу зоопарк. Безнең зоопарк зур һәм матур.
**Балалар:** Анда кошлар да күп. Миңа фламингалар ошый.

***Уен: “Җәнлекләрне, кошларны беләсеңме?”***

*(Слайдта җәнлекләрнең, кошларның рәсемнәре чыга, балалар аларны танып, татарча атамаларын һәм характер үзенчәлекләрен әйтәләр. Мәсәлән: Бу – төлке. Ул бик хәйләкәр.)*

***(“Курчак театры” рәсеме)***
**Тәрбияче:** Нинди матур бина .
**Балалар:** Бу курчак театры бит. Курчак театрында мин бик еш булам. Быел татарча театр да карадык.
**Тәрбияче:** Балалар, ә бу елганы беләсезме?
**Балалар**: Бу Иж елгасы.
**Тәрбияче:** Әйе. Безнең шәһәр Иж елгасы буйлап урнашкан. Исемен дә шушы елга исеменнән алган.Иж елгасы чишмәләр белән туена. Безнең якларны чишмәләр ягы да дип атыйлар.
(**Иж елгасы, чишмә, чишмәләр ягы**, **туена** *сүзләренең тәрҗемәсен әйтү һәм бу сүзләрне кабатлау*).\
Сулар, елгалар, чишмәләр белән бәйле удмуртларның үзләре яратып уйный торган уеннары да бар. Шуларның берсе *Вумурт «Водяной»дип атала. Ә безнеңчә “Су иясе”. Эйдәгез бергәләп уенны уйнап алыйк.*

(**Уенның тәртибе**: Санамыш ярдәмендә “Су иясе”( Водяной-Вумурт) сайланып алына. Аның күзләрен бәйлиләр, чүгәләп утыра. Балалар аның тирәли йориләр. Су иясе, су иясе , су атында торасың.Су астыннан чык та син, безнең белән уйна син”. ) «Вумурт, вумурт, мар пукиськод ву пыдсын? Пот, пот ми доры вераны, коня ни дыр!» («Водяной, Водяной, что сидишь ты под водой? Выйди, выйди к нам, скажи, который час!»).Балалар түгәрәктә туктап калалар.Су иясе чыга, берәр баланы тотып, таныргa тиеш. Су иясе каршында калган бала алга чыга. Бу кем?, дип сорыйлар балалар. Су иясе төрле сораулар биреп каршында торучының кем икәнлеген белергәтиеш. Аның сораулары болай булырга мөмкин:
-Бу кем: малаймы, кызмы?
- Озынмы, кыскамы?
-Чәче нинди?
- Нинди күлмәк кигән?Һ.б.ш.

Су иясе сорауларына балалар җавап бирәләр. Җаваплар ярдәмендә су иясе үз каршысында торган баланың кем икәнлеген дөрес әйтсә, шул уенчы су иясе була. Дөрес әйтмәсә, су иясе кире үз урынында кала.)

**Тәрбияче:** Безнең Удмуртия республикасында, шәһәребездә бик төрле милләт халыклары дус һәм тату яшиләр.Сез аларның кайберләрен беләсез дә. Өстәлләрдә төрле милләт киемнәре белән карточкалар. Сезгә дөрес итеп курчакларны киендерергә кирәк.

*(“Курчакларны киендер” –дидактик уен)*

**Тәрбияче:** Сез нинди милләт курчакларын киендердегез, күрсәтеп үтегез әле.

(*Балалар әйтеп үтәләр. Мәсәлән: Бу – татар кучагы. Ул калфак, алъяпкыч, күлмәк, читек кигән.)*

**Тәрбияче:** Безнең татар халкының да бик күп уеннары бар. Нинди уеннар беләсез?

(Балалар уеннарны әйтеп үтәләр: “Түбәтәй”, “Капкалы”, “Җебегән”,”Менлебай” һ. б.ш.)

**Тәрбияче:**“Читекче” уенын уйнарга телисезме?

**“Читекче” уены уйнала.**

(**Уенның тәртибе**. Бер бала уртага чыга. Кулында читек. Ул түгәрәк эчендә балаларга каршы читекне күрсәтеп бара. Калган балалар аңа каршы әйләнәләр. Бергәләп җырлыйлар.

Итек , читек, энәбез
Читек башы чигәбез
Кирәкмиме, кирәкмиме, кирәкмиме
Алмыйсызмы, алмыйсызмы, алмыйсызмы
Әллә биеп карыйсыз. карыйсыз.

Җырның соңгы юлларыннан соң, уртадагы бала бии-бии берәүнең алдына читекне тиз генә куеп китә. Алдына читек куелган бала, аны тиз генә алып, уртага чыгарга тиеш. Өлгермәсә, “җәза” бирелә)

Уен шулай дәвам итә.

**Тәрбияче:** Рәхмәт, балалар. Сәяхәтебезне бүгенгә тәмамларга да вакыт. Шәһәребезнең калган кызыклы урыннары әле бик күп.Аларны өйрәнүне без дәвам итәрбез. Һава шарына утырыйк та, бакчага кайтыйк. (Кабат кыңгырау тавышы)

**Тәрбияче:**.Бүгенгә сәяхәтебез тәмам. Нәрсә бигрәк тә сезнең хәтерегездә калды. Нинди яңа сүзләр өйрәндегез? (Балалар сорауларга җаваплар бирәләр.)

**Тәрбияче:** Минә кайтып та җиттек.Минем татар малае һәм татар кызы төшкән смайликлар бар. Әгәр сезгә сәяхәт ошаган икән, сез елмайган смайликларны, әгәр сәяхәтебез ошамаса, моңсу смайликларны алып ябыштырыгыз. (Балалар смайликларны ябыштыралар)

Шундый кызыклы һәм мавыктыргыч сәяхәттә булганыгыз өчен сезгә зур рәхмәт.

## 1 нче сыйныф укучылары өчен сыйныф сәгате
## “Тынычлыкның кадерен белик!”

*Дәүләтбаева Рузилә Нуршаех кызы,*
*Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе*
*башлангыч сыйныфлар укытучысы*

**Максат:** балаларга тыныч тормышның , бәхетле балачакның бәясен төшенергә ярдәм итү;

**Бурычлар:**

1. Ватанны ярату хисе тәрбияләү;

2. Бөек Ватан сугышы чоры вакыйгаларын, аның авырлыгын, михнәт, кайгы сагыш китергәнен укучы күңеленә аңлаешлы итеп җиткерү;

3. Сугыш һәм тыл батырларына карата хөрмәт, Ватанны ярату хисе тәрбияләү.

Җиһазлау: презентация “Тынычлыкның кадерен белик!”, видеоязма “Бөек Ватан сугышы ветераны Мансур аганың сугыш хатирәләре, “Истә, һаман да истә”исемле альбом.

**Сыйныф сәгате барышы.**

**1.Оештыру өлеше**. Уңай психологик халәт тудыру.Хәерле көн, укучылар!

Йөзләрегездәге елмаюны иптәшләрегезгә дә бүләк итегез әле. Елмаю күңелләргә рәхәтлек, җылылык, эшкә дәрт өсти.

**2. Уку мәсьәләсен кую.**

*1 слайд.*

Шигъри юлларны игътибар белән укып чыгыгыз әле. Шигырь нәрсә турында?

Тынычлык булсын
Килер көннәрдә,
Иминлек булсын
Бөтен җирдә дә!

Укучыларның фикерләре тыңлана. Шигырьне хор белән уку.

-Әйе, шигырь тынычлык турында. Димәк, бүген без нәрсә турында сөйләшербез? (Укучыларның җаваплары).(Сыйныф сәгатенең темасын ачыклау, максатны билгеләү).

**3. Уку мәсьәләсен чишү.**

- Сыйныф сәгатен без тыныч тормышның, бәхетле балачакның никадәрле кадерле икәне турында сөйләшүгә багышларбыз.
- Тыныч тормышны безгә кемнәр бүләк иткән дип уйлыйсыз?
- Ни өчен тынычлык безнең өчен бик кадерле?

*2 слайд.*

Һәр яңа көн тууга без бер-беребезгә тынычлык һәм иминлек телибез. Ә бит тыныч тормышта яшәмәгән, сугышларда катнашкан, балачакларын рәхимсез сугыш урлаган кешеләр бик күп. 1941 ел, 22 июнь... Таң атып килә. Гүзәл авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләрнең җылы куенында, тәмле төшләр күреп, нәни сабыйлар изрәп йоклый. Шул вакытта дошман безнең чикләрне бозып, авылларны, шәһәрләрне үлем утына тоткан. Бөек Ватан сугышы башланган.Бөек Ватан сугышы башлангач, авылдашларыбыз, якташларыбыз, бабаларыбыз Ватанны саклау өчен яу кырына киткән.Кечкенә Чишмә авылыннан да туган Ватаныбызны саклап, 67 кеше яуда катнашкан. Шуларның 27есе генә туган авылына әйләнеп кайткан, ә 40ы батырларча һәлак булган.

Бүген без сугышның бөтен авырлыкларын күргән Бөек Ватан сугышы ветераны Мансур абый Нәбиуллинның тормыш юлы, сугыш вакытында күргән авырлыклары турында видеоязма карап узарбыз.

*3 слайд.*

(Видеоязма карау.) Укучылар белән фикер алышу.

-Укучылар, әңгәмәне тыңлаганда сездә нинди хисләр уянды?
-Сугышта Мансур абый нинди батырлыклар күрсәткән?
-Укучылар, Мансур ага ни өчен моңсу? Аның сәбәбен әйтә аласызмы?

**Нәтиҗә**. Укучылар фикере тыңлана. Мансур абый Бөек Ватан сугышында катнашкан. Безнең тыныч яшәвебез өчен көрәшкән. Ул - безнең хөрмәтле сугыш ветераны. Күкрәгендәге орден-медальләр моны исбатлап тора.Мансур абый сөйләгәннәрдән сугышның никадәрле куркыныч, кешеләргә күпме авырлыклар, югалтулар китерүен аңладык.

Ә сугыш елларында авылда хатын-кызлар һәм балалар гына кала. Бөтен эш алар җилкәсенә төшә. Ачлы-туклы килеш  ил өчен, фронт өчен дип, көнне төнгә ялгап эшлиләр. Колхоз терлекләрен карарга, урак урырга, ындыр табагында эшләргә туры килә аларга. Ләкин алар зарланмаганнар, иңнәренә төшкән авыр йөкне җигелеп тартканнар. Әбиләребез, сугышка киткән ир-егетләребезне алмаштырып, трактор, комбайн штурвалы артына утырган. Җир сөрергә дә, тырмаларга да, чәчәргә дә туры килгән аларга.
(Укучыларны  "Истә, һаман да истә" альбомда тупланган материаллар белән таныштыру.)
Мәгълүмә апа хатирәсе (1укучы сөйли)
*4 слайд.*
"Безнең үсмер чакларыбыз  авыр сугыш елларына туры килде. Ул вакытлар искә төшсә, хәзер дә тәннәр чемердәп китә. Сугыш башланганда, миңа 14 яшь иде.  Авылда эшче көчләр җитешмәгәнлектән, мине, 1943 нче елны МТСка тракторчылар курсына укырга җибәрделәр. Курсларны бетергәч, трактор иярләдем. 18 ел буена алны-ялны белмичә, бөтен көчемне куеп, тракторда эшләдем. Сәламәтлегем какшау сәбәпле, лаеклы ялга чыкканчы, тавыклар фермасында хезмәт куйдым. Сугыш елларында без кичергәннәрне сезгә күрергә язмасын, күгебез һәрвакыт аяз булсын, шулай бәхетле булып яшәгез, яхшы укыгыз, хезмәтне яратып үсегез, дөньялар тыныч булсын!"
-Укучылар Мәгълүмә апаның язмасын тыңлаганнан соң сездә нинди хисләр туды? (укучыларның җавабы тыңлана)
**Нәтиҗә.** Димәк, безнең тыныч яшәвебездә тыл ветераннарының да өлеше зур булган.
Сугыш- газап һәм кайгылар алып килүе белән беребез дә теләмәгән куркыныч бер вакыйга. Безнең бабаларыбыз туган җирне саклау, халкыбызны фашизмнан коткару өчен, зур батырлыкларга барганнар, сугыш кырларында гомерләрен биргәннәр. Каһарманлык күрсәтеп вәхшилек, кансызлыкны җиңгәннәр, Ватаныбызны дошман явыннан саклаганнар. Шушы батырлыклары — Ватанны саклаганнары  һәм илебезгә тынычлык алып килгәннәре өчен сугыш һәм тыл ветераннарын исебездән чыгармыйк. Тыл һәм хезмәт ветераннарының якты истәлеген 1 минут тынлык белән искә алыйк.

**4. Ә хәзер төркемнәрдә эшләп алырбыз.**

*5 слайд.*
-"Тынычлык" сүзенә синквейн язарга.
Укучыларның чыгышларын тыңлау.

**5. Рефлексия.**

- Сыйныф сәгатендә нинди мәгълүмат алдыгыз?
- Сыйныф сәгатеннән соң сездә нинди теләкләр туды?

Киләсе сыйныф сәгатендә  үзегезнең гаиләдәге сугышта катнашкан яки сугыш чорындагы тыл ветераны турында сөйләргә әзерләнергә.
*6 слайд.*

**6. Йомгаклау.**

-Укучылар, сыйныф сәгатебезне тәмамлап, шуны әйтәсе килә: җиһанда сугышлар һичкайчан тынмаган. Хәзер дә дәвам итә.( Авылыбыздан махсус операциягә киткән ир-егетләр турында укытучы сүзе).
Укучылар:
-Сугышлар һәм канлы вакыйгалар алып килгән күз яшьләрен коярга насыйп  булмасын;
-Аяз күгебездә беркайчан да туплар шартламасын;
- Ятимнәрнең саны артмасын иде!
Бүгенге сөйләшүдән гыйбрәт алыйк һәм тыныч тормышыбызның кадерен белергә өйрәник!

“Һәрвакыт булсын кояш!” җырын башкару.

**Зурлар төркемендә әхлакый –патриотик тәрбия белем бирү эшчәнлеге конспекты**
**“Яратыгыз туган җиребезне, яратыгыз туган илебезне”**

*Нурмеева Лилия Ильяс кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәре муницпиаль бюджет 1 нче мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениясе “Алтын ачкыч” балалар бакчасы тәрбиячесе*

**Максат:** Туган илебез, халкыбыз турында алган белемнәрне ныгыту, камилләштерү.

**Белем бирү бурычлары:** бәйләнешле сөйләм телен үстерү; сүзлек запасын баету;

**Үстерү бурычлары:** балаларның логик фикерләү күнекмәләрен, пазл җыю осталыкларын арттыру, күрү һәм ишетү хәтерләрен камилләштерү; мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

**Тәрбия бурычлары:** туган илгә, туган җиргә мәхәббәт, гуманлык хисләрен тәрбияләү.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** танып белү үсеше, сөйләм үсеше, социаль-коммуникатив үсеш.

**Алдан үткәрелгән эш**: “туган ил”, “туган җир” төшенчәләрен өйрәнү- ныгыту, шигырьләр ятлау, карта белән танышу, Татарстан республикасы , шәһәрләре турында әңгәмә."Читек","Түбәтәй" уеннарының сүзләрен өйрәнү.

**Сүзлек эше:** символика, республика, гимн, герб, флаг, КамАЗ, шәһәр.

**Җиһазлау:** түбәтәй, музыка, ромашка чәчәге, Россия, Татарстан флагларыннан пазл, хат, читек ( яки читек рәсеме) медальләр, милли киемнәр төшкән рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы.**

**Кереш өлеш.**

**Тәрбияче:**Хәерле көннәр, балалар, кәефләрегез ничек? Минем бүгенге эшчәнлегебезне Зәкия Туфайлованың матур шигыре белән башлыйсым килә. Балалар, игътибар белән тыңлагыз әле.

“Туган ил”.

Туган ил ул – алтын арышлар,
Туган ил ул – зифа камышлар
Туган ил ул – иркен болыннар,
Болыннарда – нәни колыннар.
Туган ил ул – зәңгәр диңгезләр
Туган туфрак, үскән нигезләр
Туган илдә - барабыз бертуган
Бик кадерле безгә ул шуңа.
Туган ил ул була бер генә,
Туган илнең кадерен бел генә.

**Тәрбияче:** Балалар, сезгә шигырь ошадымы? Шигырьнең эчтәлеген ничек аңлыйсыз, шигырь нәрсә турында язылган?

**Балалар:** шигырь туган тел турында бара.

**Тәрбияче:** Әйе, балалар, автор туган ил төшенчәсен башка сүзләр белән ачып бирә.Ә сез ничек аңлыйсыз – нәрсә ул туган ил?

**Балалар:** Балалар җавабы ( торган җир, Россия, Татарстан)

**Тәрбияче:** Дөрес, балалар, туган ил ул безнең туган җиребез, безнең шәһәребез, авылыбыз, Ватаныбыз. Безнең әби - бабаларыбыз яшәгән җир. Һәр кешенең туган җире, туган иле, Ватаны була шулаймы? ( *сообщение килгән тавыш ишетелә*) ай, балалар, гафу итегез, миңа кемдер хат җибәрде, карыйм әле. Балалар, минем Америкада бер танышым яши, аның безнең илебез белән бик танышасы килә, бездән ярдәм сорый, булышабызмы аңа? ( Балалар җавабы) Без шулай видеозвонокны кабызып куярбыз да, танышым безнең ярдәм белер безнең илебез белән танышыр.

Балалар,әйдәгез әле, без илебез турында белгән белемнәребезне шушы чәчәк аша тикшереп карыйк. Һәрберегез ромашка таҗларын ала һәм сорауларга җавап бирә, сорау авыррак булса, без бер-беребезгә ярдәм итәбез.

1.Безнең илебез ничек атала? ( Россия)

2. Безнең республикабыз ничек атала? ( Татарстан) Без аны кече Ватаныбыз дип тә атыйбыз.

3. Татарстанда дәүләт телләре нинди?( рус һәм татар телләре)

4. Татарстанда нинди милләт халыклары яши?( рус, татар, башкорт, мордва, мари, чуваш, удмурт)

5. Татарстанның беренче президенты кем? ( М.Ш.Шәймиев)

6.Татарстанның хәзерге президенты кем ? (Р.Н.Миннеханов) Балалар, хәзер безнең президент рәис дип атала.

7. Россияның президенты кем? ( В.В. Путин)

8. Татарстанның башкаласы нинди шәһәр? ( Казан)

9. Россияның башкаласы нинди шәһәр? ( Мәскәү)

**Тәрбияче:** булдырдыгыз, балалар, сорауларга җавап бирдек. Әйдәгез әле, илебез һәм республикабызның символикаларын да искә төшерик. ( экран белән эш яки рәсемнәр белән генә дә күрсәтергә була) Символикага нәрсәләр керә?

**Балалар:** герб, флаг, гимн.

**Тәрбияче:** дөрес, балалар, экранга карагыз әле бу кайсы илнең гербы? ( Россия) Дөрес, балалар, аны ничек белдегез, нәрсә белән аерыла ул?

**Балалар:** ике башла алтын бөркет.

**Тәрбияче:** бик дөрес, балалар, хәзер кайсы илнең гербы ( Татарстан) Аны ничек аердыгыз?

**Балалар:** канатлы ак барс.

**Тәрбияче:** афәрин, балалар. Ә менә флагларны белер өчен мин сезне пазл җыярга чакырам. ( ике төркемгә бүленеп Россия һәм Татарстан флагларын җыялар).

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз, балалар. Әйдәгез әле танышыбызны үзебезнең милли киемнәр белән таныштырыйк. ( рәсемнәр күрсәтә, балалар әйтәләр)

*Түбәтәй, калфак, алъяпкыч, читек.*

**Тәрбияче:** Балалар, ә хәзер мин сезгә читек белән уйнап калырга тәгъдим итәм. Әйдәгез, түгәрәк ясап басабыз, татарча санамыш белән алып баручыны сайлап алабыз. (*бер бала саный)*

*Әке, бәке, кыек сәке*
*Сөт, май, эремчек.*
*Син калып тор*
*Ә син чык*. Марат калды, ул алып баручы була. ( уртага урындыкка алып баручы утыра , читек чиккән кыяфәт ясый.

***Итек, читек, энә, без.***



***Матур итеп чигәбез.***
***Кирәкмиме? Алмыйсызмы?***
***Әллә киеп карыйсызмы?*** ( *шул сүзләрдән соң ике баланың арасына читекне куя, балалар түгәрәкнең икесе ике ягына йөгерә, кем беренче йөгереп килеп килеп читекне ала, шул алып баручы була. Уен шулай дәвам итә.)*

**Тәрбияче:** булдырдыгыз, балалар, уйнап ял итеп алдык. Илебез белән таныштыруны дәвам итәбез. Безнең республикада Казаннан кала башка зур шәһәрләр дә бар бит әле. Әйдәгез ул шәһәрләрне искә төшереп алыйк әле, балалар. Һәр шәһәрнең безгә нәрсәсе беләндер билгеле. Мин сезгә бер шәһәр турында мәгълумат әйтәм, сез миңа кайсы шәһәр икәнен әйтеп бирергә тиеш буласыз.

1. Ул шәһәрдә вертолет заводы, Колшәриф мәчете, аквапарк бар? ( Казан)
2. Кайсы шәһәр нефтьчеләр шәһәре дип атала? ( Әлмәт)
3. Кайсы шәһәрдә КамАЗ машинасы чыга? ( Чаллы)
4. Резин көпчәкләр заводы кайсы шәһәрдә урнашкан? ( Түбән Кама)
5. Чуен савыт- саба, итек басу заводы заводы кайсы шәһәрдә? ( Кукмара)
6. Музейларга бай, тарихи шәһәр? ( Алабуга)
7. Шикәр чыгарыла торган шәһәрләр ( Норлат, Зәй)
8. Сәгать заводы кайсы шәһәрдә урнашкан? ( Чистай)

**Тәрбияче:** булдырдыгыз, балалар. Сез безнең илебез, аның шәһәрләре турында бик күп беләсез икән? Әйдәгез әле, халкыбызның тагын бер уенын “Түбәтәй”не уйнап алыйк. ( *Балалар түгәрәк ясап басалар, уртага санамыш белән бер баланы сайлап куялар, аның кулында түбәтәй. Балалар әйләнеп йөриләр, түбәндәге сүзләрне әйтәләр*)

***Түп – түп- түбәтәй***
***Түбәтәем укалы .***
***Чиккән , матур түбәтәем***
***Менә кемдә тукталды***. (*Кем каршында туктап кала, шәңа түбәтәй кигертәләр.*

**Тәрбияче:** балалар нинди җәза бирәбез Әмиргә. ( мәкаль әйтсен, җырласын, биесен, санамыш әйтсен) Уен берничә тапкыр уйнала.

**Йомгаклау өлеше:**

**Тәрбияче:** Молодцы, балалар. Туган республикабыз, илебез турында сез бик күп беләсез. Минем Америкадагы танышыма бик ошагандыр, ул да күп нәрсәләр белгәндер дип уйлыйм. *( Ишек шакыйлар, хат алып керәләр)*

*Телефонга голосовой сообщение килә. Тәрбияче балаларга тыңлата).*

*“Балалар, сезгә бик зур рәхмәт.Сез үзегезнең илегез турында шундый күп беләсез икән. Сезнең белемнәрегез аша мин бик мәгълумат белдем.Миңа да сезнең республикагыз бик ошады. Үскәч тә, Ватаныгызның горурлыгы булып калырсыз дип ышанам. Мин сезгә тырышлыгыгыз өчен почта аша медальләр җибәрдем. Рәхмәт сезгә”*

*Тәрбияче хатны ачып, балаларга медальләрне кигертә.*

**Тәрбияче:** Бүгенге шөгылебез Г.Тукайның “Туган теле” җыры белән тәмамлыйк. Җыр яңгырый, балалар кушылып җырлый.

Рәхмәт , балалар, шөгыль сезгә ошагандыр дип уйлыйм.Сау булыгыз.

**Зурлар төркемендә уен конспекты**
**«Минем Ватаным – Татарстан».**

*Җәлилова Гөлнара Рафис кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*Тирсә авылы "Миләүшә" балалар бакчасы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе тәрбиячесе*

**Максат**: уен барышында танып белү сәләтләрен формалаштыру.
**Үстерү бурычы:** тәрбиячене тыңлый һәм ишетә белү күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү, реакция тизлеген, логик фикерләүне, игътибарлылыкны, хәтерне үстерү, сүзлек запасын активлаштыру.
**Тәрбия бурычы:** бердәмлек һәм бер-береңне тыңлау әдәбе тәрбияләү, туган җиреңә карата кызыксыну, патриотик хисләр, горурлык уяту.
**Белем бирү бурычы:** балаларда үз Ватаннары турында белемнәр формалаштыру, тәрбияче сорауларына тулы җавап бирүгә ирешү.
**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.
**Интеграль белем бирү өлкәләре**: сөйләм үсеше, социаль-коммуникатив үсеш.
**Методик алымнар һәм чаралар:** сөенеч мизгеле, проблемалы ситуация,күрсәтмә материал, әңгәмә, нәфис сүз, дидактик уен.
**Җиһазлау:** хат, шар, карта, магнитлы такта, Казан шәһәре рәсеменнән пазл өлешләре, дидактик уен «Татарстанда үсә торган агачны таны», хайваннар турында табышмаклар салынган конверт, хайваннар салынган тартма, калфак һәм түбәтәй пазллары салынган алсу һәм зәңгәр төстәге чигүле ике янчык, һәр балага йомшак мендәрләр, кибет уены, аудиоязма «Күрсәт әле үскәнем», бүләккә һәр балага кечкенә чәк-чәк.
**Сүзлек өстендә эш:** рәис, Татарстан Республикасы, калфак, кыңгырау.
**Алдан үткәрелгән эш:** Татарстан табигате турында рәсемнәр карау, китаплар уку, шигырьләр өйрәнү.
**Эшчәнлек төзелеше.**
**I. Кереш өлеш.**
- Оештыру мизгеле.
**II. Төп өлеш.**
- Сөенеч мизгеле.
- Әңгәмә «Татарстан – минем Ватаным».
- Дидактик уен «Татарстанда үсә торган агачны таны»
- Дидактик уен «Пазлны җый»
- Туган җиребез турында иң матур шигырь сөйләү.
- Музыкаль ял минуты. «Күрсәт әле, үскәнем».
- Дидактик уен «Табышмакны чиш».
**III. Йомгаклау.**
- Рефлексия.
- Сюпризны табу.
Эшчәнлек барышы.
**I. Кереш өлеш.**
**Тәрбияче.**
Бергәләшеп без басыйк,
Бик зуртүгәрәк ясыйк.

Кояшның җылы нурыннан
Йөрәкләргә көч алыйк.
Татулашыйк, дуслашыйк,
Уеныбызны башлыйк.
**Шигырь сөйләү:**

**Идел ярларына нурлар сибеп**
**Матур булып ата бездә таң.**
**Таң шикелле якты Туган илем,**
**Бәхет биргән җирем — Татарстан.**

Ә без нинди Республикада яшибез?



***Балалар****:Без Татарстан Республикасында яшибез*
**Тәрбияче:**Безнең Республикабыз нинди?
***Балалар****:Безнең республикабыз бик матур, зур, бай.*
**Тәрбияче**:Татарстанның башкаласы ниниди шәһәр?
**Балалар**: Татарстанның башкаласы-*Казан шәһәре.*
**Тәрбияче**: Казанга баргач нинди матур урыннарны күрдегез?
**Балалар***: Кол шәриф мәчете, музейлар, Кремль, цирк, театрлар...*
**Тәрбияче** Ә сез Татарстанны яратасызмы .
**Балалар:** *Без Татарстанны бик яратабыз , чөнки ул безнең Ватаныбыз: безнең туган илебез, туган җиребез.* Без Татарстанда яшәвебез белән горурланабыз, чөнки монда бар кешеләр дә дус яши.
*(Төркемгә шар очып керә, тасмага төргәк бәйләнгән.)*
**Тәрбияче.** Балалар, кем җибәрде икән безгә бу шарны? *(Җаваплар)*
Бу хат безнең Республикадагы иң зур дәрәҗәле кешедән икән бит.Татарстандагы иң зур кешенең исемен беләсезме?
**Балалар**:*Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миннеханов*
**Тәрбияче**: Ул безгә хат язган, укып карыйк әле.
“Кадерле балалар, мин сезгә үзебезнең республиканың картасын җибәрәм. Тик ул гади түгел, тылсымлы карта. Карта буенча йөреп, биремнәрне үтәсәгез, Татарстан Республикасы Рәисеннән сюрприз табырбыз”.
**Тәрбияче**: Сюрпризны эзләргә сез әзерме?!
**Балалар:** Әйе, әзер.
**II. Төп өлеш.**
**Тәрбияче.** Тылсымлы картада 1 саны янында Татарстанның бай, матур табигате сурәтләнгән.Үзебезнең төркемдәге табигать почмагына барыйк әле. Безне монда «Татарстанда үсә торган агачны таны» уены көтә.
*(Балаларга төрле агачларның яфраклары һәм агачларның иллюстрацияләре күрсәтелә. Яфракны агач белән туры китереп беркетергә кирәк.)*
**Тәрбияче.** Булдырдыгыз, биремне үтәдегез, рәсемнең бер өлешен таптык.Аны магнитлы тактага беркетәбез. Тылсымлы картада 2 саны янында нәрсә күрәбез?
**Балалар:***«рәсем почмагы» рәсемен күрәбез*
Тәрбияче.Димәк, кая барабыз?
**Балалар***: рәсем ясау почмагына.*

**Тәрбияче:** Безгә тылсымлы янчыклар калдырганнар бит. Аларга нинди бизәкләр чигелгән?

**Балалар***: лалә, кыңгырау чәчәкләре һәм матур яфраклар.*

(Алсу төстәге янчык кызлар өчен, зәңгәр төстәге янчык малайлар өчен. Янчыктагы биремне дус команда булып үтәргә кирәк.)

**Тәрбияче:** *Рәсем ясау почмагында алсу төстәге һәм зәңгәр төстәге ике матур янчык табалар. Кызлар һәм малайлар төркеменә бүленеп, кисәкләрдән калфак һәм түбәтәй җыялар.*

**Тәрбияче**. Биремне дөрес үтәдегез, дус булдыгыз, рәсемнең тагын бер өлешен таптыгызмы*?(балалар үзләре табып ала)*Картадагы 3 саны янында нәрсә күрәбез?

**Балалар:** Китаплар күрәбез.

**Тәрбияче**: Безгә кая барырга кирәк?(*китаплар янына)* Йомшак мендәрләргә утырып, китапханәдә туган җиребез, аның матурлыгы турында шигырьләр сөйлик. (*берничә бала)* Рәсемнең өлешен күрәсезме? *(китаплар арасыннанбалалар үзләре табып ала)*

**Тәрбияче:** 4 саны янында нәрсә күрәсез, дуслар?

**Балалар**: *Гармун күрәбез.*

**Тәрбияче:** Әйдәгез, татар халык көенә үзебез ярата торган «Күрсәт әле үскәнем» уенын уйныйк.

*(«Салаватиклар» видеосын кулланырга мөмкин. Уйнап бетергәч, гармун янында тагын бер рәсем табалар.)*

**Тәрбияче.** Соңгы 5 саны янында нәрсә күрәбез, дуслар?

***Балалар****: кибет рәсеме күрәбез.*

**Тәрбияче**: Карыйк әле, кибеттә нәрсәләр сатыла икән бүген? Тик монда конверттан башка берни дә юк! Конверт эчендә нәрсә бар икәнен карыйбызмы? Монда табашмаклар язылган.

1.Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак. *(Куян)*

2. Бер нәрсә тегә белми,
Энәләр тагып йөри. *(Керпе)*

3. Җәен урманга патша,
Кышын кардан да аста. *(Аю)*

4. Сорыдыр төсе,
Үткендер теше.
Урманда йөри,
Бозаулар күзли *( Бүре)*

5. Көлтә-көлтә койрыгым
Селки-селки барамын.
Кетәклеккә кереп мин
Тавык-чеби аламын. (*Төлке)*

(*Дөрес җавапны әйткәч, тәрбияче тылсымлы тартмадан уенчык хайваннарны алып кибет киштәсенә куя.)*

**Тәрбияче:** Табышмакларны дөрес чиштегез. Тартма төбендә соңгы рәсем яшерелгән.

**III. Йомгаклау.**

**Тәрбияче.** Менә кисәкләр җыелып бетте, әйдәгез, тоташтырып карыйк әле, нәрсә килеп чыгар икән.

***Балалар***: Безнең ватаныбызнын баш каласы-*Казан шәһәре*.

Балалар, без бергә дус булып Татарстан Республикасы турында бик күп мәгълүмат белдек! Сезгә биремнәрне үтәү авыр булдымы? Кайсы бирем авыр булды, кайсы бирем җиңел

булды? Бу турыда кемгә сөйләрсез? Республикабыз Рәисе калдырган сюрпризны Казан шәһәре рәсеме янынннан табырсыз. *(уенчыклар арасына яшерелгән Казан шәһәре рәсеме янында чәк-чәк табып алалар)*

**Тәрбияче.** Сезнең өчен сюрприз – татар халкының милли ризыгы чәк-чәк. Хәзер бергәләп чәй эчәрбез.

**Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты**
**“Дөньяда Ватаныбыздан да матуррак нәрсә юк.”**

*Сәитова Наталья Алексей кызы,*
*Татарстан Республикасы*
*Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәре*
*муницпаль бюджет 1 нче мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениясе*
*“Алтын ачкыч” балалар бакчасы тәрбиячесе*

**Максат:** патриотик хисләр тәрбияләү – Ватанга мәхәббәт, Татарстан флагына һәм гербына хөрмәт.

**Бурыч:**

*****Татарстан Республикасы картасы һәм символикасы белән таныштыру;
*Туган якның табигый байлыклары турында сөйләү;
*Балаларның Казан башкаласы һәм туган шәһәре турында белемнәрен ныгыту;
*Казанның истәлекле урыннары белән таныштыру.

**Җиһазлар:** проекция экраны, Татарстан Республикасы картасы, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов портреты, Казанның мәдәни үзәкләре, Татарстан гербы, флагы репродукцияләре.

**Белем бирү эшчәнлеге барышы.**

**Тәрбияче:** Исәнмесез балалар, бүген мин сезне виртуаль экскурсиягә дәшәм.



Теманы бергәләп билгелик.

С.Михалков шигырен тыңлагыз (Данияр Темурчи укый)

Минем яраткан җирем
Бу таулар һәм урманнар,
Бөтен җирдә кош тавышлары,
Әти, әни, абый һәм мин,
Балалар бакчасы, дусларым,

Шәһәр, матур җирләр –
Бу минем Туган илем.
**Тәрбияче:** Бу шигырьдә нинди тема чагыла?
**Балалар:** Туган ил.
**Тәрбияче:** Сез ничек аңлатыр идегез Туган ил сүзен?
**Балалар:** Бу без туган урын. Туган йорт, әти – әниләр, балалар бакчасы, дуслар.
**Тәрбияче:** Без "Туган җир" дибез . Барлык җавапларыбызны "Безнең Ватаныбыз – Татарстан" темасы белән берләштереп була. Казан – Татарстан Республикасының башкаласы. Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе субъекты.
Төп халык: татарлар, руслар, чуашлар, марилар һ.б.
Татарстан Республикасының төп байлыгы – нефть, газ, торф, эзбизташ.
Ә хәзер Татарстан Республикасы картасына күз салыйк. Картада без зәңгәр сызыкларны күрәбез. Алар нәрсәне аңлата дип уйлыйсыз?
**Тәрбияче:** шәһәр Бөек Волга елгасы буенда урнашкан. Шулай ук Казанка, Кама, Вятка елгалары ага.
Картадагы яшел таплар – урман икәнен аңлата.
Ә менә бу түгәрәкләр шәһәрләрне аңлата.
Республикада барлыгы 24 шәһәр бар:

| | |
|---|---|
| Әгерҗе | Яшел Үзән |
| Азнакай | Лениногорск |
| Әлмәт | Мамадыш |
| Арча | Минзәлә |
| Болгар | Яр Чаллы |
| Бөгелмә | Түбән Кама |
| Буа | Нурлат |
| Баулы | Тәтеш |
| Алабуга | Чистай |
| Зәй | Менделеев |
| Кукмара | Лаеш |

**Тәрбияче:** Шәһәрләр нәрсә белән бай?
Чистайда "Восток" зур сәгать заводы бар;
Яр Чаллыда "КамАЗ" автомобиль заводы эшли;
Түбән Кама химиклар шәһәре;
Әлмәт – нефтьчеләр шәһәре.
Казан – 1000 ел элек нигез салынган иң борынгы шәһәрләрнең берсе. Шәһәрнең исеме казан сүзеннән килеп чыккан котёл дигәнне аңлата, ризык әзерләү өчен савыт-саба.



Бердәм фикер юк, шәһәрнең урнашу урыны котловинны, котёлны хәтерләтә.
Хәзер Казан шәһәре бик зур һәм матур, анда 1 миллионнан артык кеше яши. Казан аша поездлар үтә, самолётлар оча, пароходлар йөзә. Республикага туристлар да килә.

- Әйдәгез, Казан Кремле территориясендә урнашкан һәйкәлләрне карыйк (балалар тәрбияче белән бергә иллюстрацияләрне карыйлар)
- Кремльга кергәндә безне Спас манарасы каршы ала (аның өстендә сәгать урнашкан) иллюстрация күрсәтү.

- Аннары (Сөембикә манарасы)
  (тәрбияче патшабикәнең портретын, Сөембикә манарасының иллюстрациясен күрсәтә. Истәлекле урыннар: Кол – Шәриф мәчете, Благовещен соборы).
- Шәһәрнең үз гербы бар, анда канатлы аждаһа Зилант көч, зирәклек, җиңелә алмаучанлык сүрәтләгән.

Башкалада күп музейлар, театрлар, һәйкәлләр бар, цирк, аквапарк, Бауман урамы буйлап йөрергә, океанариум, күзәтү тәгәрмәче, аттракционнар паркы, “гигантлар” музее, “Динозаврлар” музее, чәк – чәк музее һ.б.

Казан исемнәр белән танылган шәһәр. Шагыйрь С.Сәйдәшев, язучы Г.Тукай, М.Җәлил һәм А.Алиш. Барысында санап бетереп булмый. Ләкин бу портретлар арасында бер исем аерым, М.Ш.Шәймиев – бу бәйсез Татарстанның беренче Президенты (тәрбияче фотоларын күрсәтә).

**Тәрбияче:** экранда күрсәтелгән кешене кайсыгыз таный?

**Балалар:** Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов.

**Тәрбияче:** һәр бәйсез дәүләтнең үз дәүләте символлары бар: флаг, герб, гимн. Алар нәрсәне аңлата? Татарстан Дәүләт флагы өч өлешкә бүленгән: өске өлеше яшел, аскы өлеше кызыл, ә уртасында ак полоса. Һәр төснең үз мәгънәсе бар. Кызыл символ – кояш, ут төсе. Яшел тере табигать символы. Ак чисталык һәм тынычлык символы.
Герб дәүләтнең аерым билгесе. Татарстан Республикасының Дәүләт гербы канатлы Ак Барс рәсеменнән тора, аның ян ягында түгәрәк калкан, кояш дисклары фонында уң алгы аягы күтәрелгән.
Барсның канатлары җиде канаттан тора, калкан чәчәге сигез яфрактан тора.
Барс байлыкны, көчне гәүдәләндерә.
Калкан саклау, чәчәк озын гомер дигәнне аңлата.
Яшел божра эчендә безнең җирнең матурлыгын һәм уңдырышлыгын символлаштырган Татар орнаменты һәм нигезендә Татарстан язуы язылган.
Герб Татарстан Республикасы төсләрендә эшләнгә, түгәрәк формада. Гимн тантаналы җыр, илнең музыкаль символы. Дәүләт гимны авторы композитор Рөстәм Яхин.

**Тәрбияче:** татар халкының төп бәйрәмнәре. Балалар кемнәр белә?

**Балалар:** Сабантуй.

**Тәрбияче:** Сабантуй – милли бәйрәм,гадәттә июнь аенда,басулардагы барлык язгы эшләрдән соң билгеләп үтелә. Күп кенә илләрдә 21 нче мартта яз килү белән бәйле “Нәүрүз” бәйрәме билгеләп үтелә. Мөселманнарның төп бәйрәмнәре – Корбан бәйрәме.

**Йомгаклау.**

**Тәрбияче:** Балалар, бүген без туган илебез турында сөйләштек. Әйтегез әле, без кайсы республикада яшибез? (балалар җавап әйтәләр).
- Татарстан Республикасының башкаласын атагыз?
- Татарстан Дәүләт флагы төсләрен атагыз?
- Республика гербында нәрсә сүрәтләнгән?

**Тәрбияче:** ышанам, сез балалар безнең Татарстан Республикасы һәм Казан турында җитәрлек белдегез.
Дәресебезне Татарстан гимны белән тәмамларга рөхсәт итегез.
Ә хәзер балалар барыбызда бастык.

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.

Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бердастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

**Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты**
**«Туган илебез, туган ягыбыз»**

*Уразаева  Рәсилә Рәсим кызы,*
*Татарстан Республикасы*
*Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәре*
*мунициаль бюджет 1 нче мәктәпкәчә белем бирү дәүләт  учреждениясе*
*“Алтын ачкыч” балалар бакчасы тәрбиячесе.*

**Максат:**
-Баларның туган ил турындагы белемнәрен ныгыту:
-Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү;
-Аның кадерле җир һәм бердән бер булуын белү;
-Туган илнең, туган халкың белән горурлану, аның гореф-гадәтләрен, бәйрәм, йолаларын хөрмәт итү.
**Метод һәм алымнар**: кереш әңгәмә сораулар бирү, тәрбияченең хикәясе, (аңлату, күрсәтмәлелек, матур әдәбият уку, уен, әйтеп җибәрү, искә төшерү, анализ ясау, бәябирү, йомгак).
**Сүзлек өстендә эш**: Ватан, Рәис.
**Җиһазлау:** туган ягыбызның матур, истәлекле урыннары сүрәтләнгән иллюстрацияләр, Рәис Р.Н.Минниханов портреты, ТР ның дәүләт флагы, уен өчен сораулар, язылган карточкалар, “Казан шәһәренең истәлекле урыннар” дигән  презентация.

**Шөгыльбарышы**
*Бүлмә туган ил төшенчәсен аңларга ярдәм итәрлек итеп җиһазландырылган: төрлерәсемнәр, картиналар, китап, альбомнар. «Туган як» почмагында Рәис Р.Н.Минниханов портреты, астарак аның ике ягында флаг һәм герб. Балалар Г.Тукайның “Туган тел” музыкасы астында залга керәләр һәм ярым түгәрәк ясап утыралар.*
**Тәрбияче:** Хәерле иртә, исәнмесез балалар?(исәнләшү). Әйдәгез бер- беребезгә матур итеп елмаеп, хәерле иртә телик,  бөтен җиһанны, табигатьне сәламлик:
Саумы кояш,
Саумы һава,
Саумы иртә,
Саумы йомшак җил,
Саумы Туган ил!!!
Менә без сезнең белән күпме кешеләргә, табигатебезгә үзебезнең  күңелебездәге матур теләкләребезне җиткердек.
Балалар, без бүген сезнең белән туган ил турындасөйләшербез. Әйтегез әле, нәрсә ул туган ил, Ватан? Сез аны ничек күз алдыгызга китерәсез?
**Балалар (чиратлашып):**
– Туган ил ул – алтын басулар
– Туган ил ул – көмешчишмәләр
– Туган ил ул – киңболыннар
– Туган ил ул – ясле-бакчалар

– Туган ил ул – без яшәгәнавыл, өй.
– Әти белән Әни.

**Тәрбияче:** Әйе, балалар, сез бик дөрес уйлыйсыз. Чыннада безнең һәрберебез өчен Туган илебез кадерле һәм якын. Дөньяда бик күп илләр, республикалар бар. Ләкин шулар арасында иң матур, иң бай ил- ул безнең илебез.Безнең яшәгән җиребез бик матур. Аның тирә-ягында җиләкле, гөмбәле урманнар, тирән сулы елгалар бар. Безнең яши торган өебез, без йөри торган балалар бакчасы, безнең шәһәр, безнең өй – болар барысы да туган як була инде.

Иркен һәм матур
Безнең туган илебез.
Урманга бай, суга бай
Гөл бакчалы җиребез.



**Тәрбияче**: Һәр кешегә үз туган җире кадерле, якын, анны һәркем ярата. Без сезнең белән балалар кайда, кайсы районда яшибез? (**слайд)**

**Балалар:** Без Әгерҗерайоны Әгерҗешәһәрендә яшибез.

**Тәрбияче**: Туган ил, Ватан бары тик бер генә була. Бик кадерле ул. Кая гына китсәдә, кеше туган ягын сагынып кайта. Туган якның һавасы да шифалырак, сулары да татлырак. Балалар, ә безнең туган илебез нинди ил соң? Безнең Республика ничек атала?

**Балалар**: Безнең туган илебез Татарстан.

**Тәрбияче:**Анда татарлар гына яшиме?

**Балалар:** анда күп төрле халыкяши.

**Тәрбияче**: Татарстан – ул күп милләтле республика. Анда татарлар,чувашлар,марилар һәм башка бик күп төрле милләт кешеләре бердәм гайлә кебек дус- тату яшиләр.

**Тәрбияче:** Туган илебезнең баш шәһәре ничек атала? )*(җаваплар )*

Без Татарстан җирендә яшибез. Татарстанда бик күп шәһәрләр, авыллар бар. Безнең шәһәребез да Татарстан җирлегендә урнашкан. Татарстанның баш шәһәре – Казан шәһәре. Ә сезнең Казан шәһәрендә булганыгыз бармы? Анда бик күп кеше яши. Казанда зур заводлар, фабрикалар бар. Мәктәпләр, балалар бакчалары бик күп. Казанда тагын курчак театры, цирк, зоопарк бар. *(Слайдлар күрсәтелә).* Урамнарында трамвайлар, троллейбуслар, автобуслар йөреп тора. Казан шәһәренә автобус, самолет, поезд, теплоход белән барып була.

Менә балалар, без сезнең белән Казаннын Кремелен күрәбез, аның искиткеч матур ,серле бина булуына сокланырлык***.(слайд).*** Ә менә бу борынгы манара- Сөембикә манарасы. Аның турында бик күп риваятьләр йөри. Ә менә бусы инде зиннәтле, гөмбәзләре күкә ашкан мәчетләрнең берсе Кол – Шәриф мәчетен күрәбез. Бу мәчет дөнья күләмендә югары дәрәҗәдә тора***.****(слайдлар).* Күрәсезме Кремль өстендә Татарстаныбызның- байрагы җилферди. Ул милләтебезнең көчле рухлы, горур халык булуын исбатлый**.( слайд)**

**Тәрбияче:** Балалар , әйдәгез без сезнең белән уйнап алабыз.

Җил исә, исә, исә,исә ( *кулларны як-якка селтәү)*
Агачларны селкетә ( *кулларны як-якка селтәү)*
Җил тына, тына, тына *(кулларны аска таба селтәү)*
Агачлар үсә, үсә, үсә *(өскә таба күтәрү)*

**Тәрбияче:** Ә менә безнең шушы матур, горур халкы булган Татар иленең хуҗасы кем икән балалар? *(җаваплар)* Әйе, ул бик төпле, акыллы шәхес Рөстәм Нургали улы Миннеханов**. *(слайд)***

Балалар, әйтегезәле, сез татарларның нинди бәйрәмнәрен беләсез?

– Ә хәзер без сезнең белән татар халкының элек- электән бик яратып уйный торган уеннарын уйнарбыз

*. (Һәруенныуйнаганда, уенныңкагыйдәләреаңлатыла).*

**1)“Зәлидә” уенын** Өстәл өстендә төрле сораулар язылган карточкалар куела. Уенда җитез була алмасаң*(ягъни уеннан чыккан кешегә)* “җәза” бирелә. Ул үзенә охшаган карточканы ала, дөрес җавап биргән кешегә татар орнаменты белән бизәлгән открытка бирелә.

**2) “Ачык авызлы” уены.** Уенның тәртибе.Тәрбияче әйткән сүздән яңа сүзләр ясарга кирәк

– Бакча – бакчачы

Буяу –

Урман –

Иген –

– Безнең башкалабыз нинди шәһәр, исемен әйт?

– Рәисебезнең фамилиясе ничек?

Һ.б сораулар бирелергә мөмкин.

**Йомгаклау.**

**Тәрбияче**:

– Балалар, сез бүген шундый матур уйнадыгыз. Кем җиңүче булып калды? Әйдәгез аңа берәр сорау бирик. Соравыбыз музыка телендә – нинди көй? *(Туган тел*).

*(Җырны күмәк башкару.*

– Балалар, без бүген сезнең белән туган илебез, Татарстан, аның башкаласы Казан шәһәре турында сөйләштек, халкыбызның уеннарын искә төшереп үттек. Туган илдәндә кадерле җир юк.

-Рәхмәт балалар, сез бүген бик актив булдыгыз, сәяхәттә үзегезне бик тәртипле, тыйнак тоттыгыз, мин сезне бик яратам. Сау булыгыз.

**Балалар:** Сау булыгыз.

## Мәктәпкә әзерлек төркемендә шөгыль конспекты «Кече Ватаныбыз Әгерҗе шәһәренә сәяхәт».

*Васильева Фәридә Мирсәет кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе тәрбиячесе*

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотик хисләр һәм үзеңнең кече Ватанына мәхәббәт тәрбияләү.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:** кызыксынучанлык һәм танып белү мотивациясен күрсәтүгә ярдәм итү, «Минем кече Ватаным» темасына сүзлек запасны киңәйтү, балаларның фикерләү һәм сөйләм активлыгын стимуллаштыру.

**Тәрбия бурычы:** әйләнә-тирә дөньяның күптөрлелегеен танып белергә кызыксындыру, патриотик һәм гражданлык хисләрен, туган якка сакчыл мөнәсәбәт һәм мәхәббәт тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:** «Кече Ватан» төшенчәсен формалаштыру, Әгерҗе шәһәре, аның тарихы, истәлекле урыннары турында күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү.

**Төп белем бирү өлкәсе:**танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирүөлкәләре**: сөйләм үсеше, социаль-коммуникатив үсеш.

**Методик алымнар һәм чаралар:**проблемалы ситуация,күрсәтмә материал, әңгәмә, нәфис сүз, дидактик уен.

**Җиһазлау:** глобус, экран, ноутбук, проектор, автобус корылмасы, дидактик уеннар«Табышмаклар җыегыз»,«Табибка нәрсә кирәк?», ребус, шәһәр планын төзү өчен рәсемнәр, туп, юл макеты, бүләккә һәр балага медальләр.

**Сүзлек өстендә эш:** Әгерҗе, һәйкәл, җайдак.

**Алдан үткәрелгән эш:**Әгерҗе шәһәретурында рәсемнәр карау, китаплар уку, шигырьләр өйрәнү, тәрбияченең презентация төзүе.

**Эшчәнлек төзелеше.**

**I. Кереш өлеш.**

- Оештыру мизгеле.Аз хәрәкәтле уен «Исәнме».

**II. Төп өлеш.**

- «Туган ил» җырын тыңлау.
- Әңгәмә «Нәрсә ул туган ил?»
- Сәяхәткә кузгалу.
- Дидактик уен «Табышмаклар җыегыз»
- Әгерҗе шәһәренең тарихы турында әңгәмә.
- Дидактик уен «Табибка нәрсә кирәк?»
- Ребус чишү.
- Ял минуты. «Туган илем».
- Татар халык уены »Капкалы».
- Сәяхәттән кайту.

**III. Йомгаклау.**

- Рефлексия. Туп белән уен «Безнең шәһәр нинди?»
- Шәһәр планын төзү.

Эшчәнлек барышы.

**I. Кереш өлеш.**

**Тәрбияче.** Балалар, бүген безгә кунаклар килде. Әйдәгез, аларны сәламлик. Моның өчен мин сезгә уен тәкъдим итәм.

Аз хәрәкәтле уен «Исәнме».

*Исәнме, якты кояш!*
*Исәнме, яшел агач!*
*Исәнме, җылы җил!*
*Исәнме, ямьле көн!*
*Яшибез тату бергә,*
*Бездән күп сәлам сезгә.*

**Тәрбияче.**Яхшы, рәхмәт. Балалар, карагыз әле, минем кулымда нәрсә бар*?(глобус күрсәтә)(Җаваплар).*

**Тәрбияче.** Дөрес. Бу – глобус. Глобус – планетабызның кечерәйтелгән күчермәсе. Планетабызның исеме ничек икәнен кем белә? *(Җир)*. Әйдәгез әле, глобуста Россияне

табарга тырышыйк, карагыз, ул нинди зур. Дөньядабергенәилнендә Россиянекекебекзуртерриториясеюк. Балалар, әйдәгез әле «Туган ил»җырынтыңлыйк.

**II. Төп өлеш.**

**Тәрбияче.** Бу җыр нәрсә турында? *(Туган ил турында)* Туган ил нәрсәул? *( Туган ил – без туганһәмяши торган урыныбыз. Урманнар, кырлар, елгалар. Якын кешеләребез: әни, әти,әби, бабай яшәгән урын. Бу безнең балалар бакчасы. Еракларга киткән кешеләрнең сагынып кайта торган урыны. Туган ил ул кеше өчен иң кыйммәтлесе. Бу – безнең ата-бабаларыбыз эшләгән җир).*

**Тәрбияче.**Әйе, һәрберегез минем сорауга дөрес җавап бирде. Ничек уйлыйсыз, бүгеннәрсә турында сөйләшәчәкбез? *(Туган ил турында.)*Әйе, бүген кече Ватаныбыз турында сөйләшәчәкбез. Балалар, һәр кешенең туган һәм яшәгән урыны була. Ә без сезнең беләняшәгәнавылныңисеменичек? *(Терси)*

**Тәрбияче.**Ә безнең гүзәл районыбыз ничек атала? (*Әгерҗе)* Дөрес, Әгерҗе, безнең район үзәге – ул безнең бөек Ватаныбыз – Россиянең бер өлеше – безнең кече Ватаныбыз.Мин сезгә Әгерҗе шәһәрен күрсәтергә телим, сәяхәткә барабызмы? *(Әйе)* Бүген сәяхәткә автобус белән барабыз, үз урыннарыгызга утырыгыз. *(автобуска утыралар)*

**Тәрбияче.**Сез ничек уйлыйсыз, бу шәһәрдә, районда яшәүчеләрне ничек атыйлар? *(Әгерҗедә яшәүчеләр).* Районыбызда нинди милләтләр яшәгәнен беләсезме? ( *татарлар, руслар, удмуртлар, марилар)* Алар ничек яшиләр?(*дус яшиләр)* Балалар, Әгерҗе шәһәре турында бик матур шигырь дә язганнар.

*1 слайд.*

Әгерҗем – туган төбәгем,
Назлап тирбәткән бишек.
Гүзәл калам, хөр яшә син,
Җырдан җырларга күчеп.

**Тәрбияче.** Менә килеп тә җиттек. Безне Әгерҗе шәһәре каршы ала. (*автобустан чыгалар)*Безнең өчен «Табышмаклар җыегыз» уенын әзерләгәннәр*(балалар табышмаклар җыялар һәм сөйлиләр)*

*2 слайд*: Балалар, һәр шәһәрнең аерым билгесе – гербы һәм флагы була. Бу символлардан шәһәр турында күп нәрсә белергә мөмкин. Ә безнең шәһәрнең гербы һәм флагы нәрсә турында сөйли? *(җаваплар)*

*3-4 слайд:*

Көмеш –ачыклык, татулык, дуслык символы. Алтын – уңыш, байлык, тотрыклылык, хөрмәтһәмакыллылык символы. Кара төсмәңгелек, зирәклек, тыйнаклык символы.Яшелтөсязны, сәламәтлекне, табигатьне, уңдырышлылыкнысимволлаштыра. Кызыл төсбатырлык, көчһәмматурлык, бәйрәм символы. Зәңгәр төс – югары омтылышлар, намус, дан, тугрылык, үлемсезлек символы.

**Тәрбияче.** Герб безнең туган җиребезгә нигез салучы Әгерҗе исемле кеше турындагы легенданы чагылдыра. Гербтагы төп фигура – татар милли киемнәрендә ат өстендә утыручы җайдак.

*5 слайд*. Һәр шәһәрнең үз яше бар. Ә менә Әгерҗе шәһәренең яшен саннарны дөрес атасагыз белерсез. Беренче сан 2дән бергә күбрәк, икенчесе 8дән бергә кечкенә, өченчесе 6дан бергә күбрәк, бу нинди сан? *(377)*

*6 слайд.*

Әгерҗе башта шәһәр булмаган. Борынгы заманнарда Агрызка елгасы ярында кешеләр килеп яши башлаганнар. Алар авыллар төзегәннәр, җир эшкәрткәннәр, икмәк чәчкәннәр, дошманнардан сакланганнар. Алар елгага шундый исем биргәннәр.

*7 слайд*: Аннары тимер юл участогы төзелеше белән бәйле рәвештә Әгерҗе станциясе барлыкка килгән. Станция – поездлартуктый торганурын. Аннары станция Әгерҗе шәһәренә әверелә.

*8слайд:*

**Тәрбияче.**Балалар, карагызәле, без кая килеп җиттек? (*бу вокзал).* Сезнеңчә, вокзал ни өчен кирәк? *(җаваплар, автобуска утыралар)*

*9-10 слайд*:

**Тәрбияче.** Безнең сәяхәт дәвам итә, хәзер Карл Маркс урамыннан барабыз. Карагыз, безнең автобус Әгерҗе шәһәре администрациясе яныннан уза.

*11 слайд*.

**Тәрбияче.** Безнең район башлыгы Нургаянов Ленар Фәрит улының эш урыны бу.

*12 слайд*: Поликлиникага килеп җитәбез. Әйдәгез автобустан чыгыйк. Балалар, кем сәламәт булырга тели? Сәламәтлек нәрсә ул дигән сорауга кайсыгыз җавап бирә ала? (*җаваплар).* Сәламәт булыр өчен без нәрсә эшлибез? *(Иртән зарядка ясыйбыз, төрле уеннар уйныйбыз...)*Әйе, сез хаклы. Сәламәтлек ул – матурлык, көч, акыл, яхшы кәеф. Әгәрдә без авырыпкитсәк, табибкаполиклиникага барып дәваланаалабыз. Поликлиникада кемнәрэшли?*(табиб, шәфкать туташы, санитарлар*) Поликлиникада эшләүче һәркемнең үз эш коралы бар. Табибка нәрсәләр кирәк? *(җаваплар).*

Уен: «Табибка нәрсә кирәк?»

*13 слайд:*

**Тәрбияче.** Юлыбызны дәвам итәбез.Һәйкәлгә игътибар итегез. Ничек уйлыйсыз, ул кемгә куелган?*(җаваплар).*Дөрес, бу Бөек Ватан сугышы елларында Ватаныбызны саклаганда һәлак булган Әгерҗе солдатларына һәйкәл. Үзе турында уйламыйча, намус белән, безнең бәхетебез өчен гомерләрен биргән солдатларны искә төшерик. Мәңгелек Дан Монументы янында басып, сугышчыларны бер минутлык тынлык белән искә алыйк.

**Тәрбияче**.Ничек уйлыйсыз, ни өчен солдатлар безнең илебезне яклаганнар икән? *(җаваплар).*Мин сезгә ребус тәкъдим итәм,чишкәч без бу сорауга җавапны беләчәкбез.*(*«Тынычлык» *сүзен табалар)*

Дөрес, солдатлар тынычлык булсын өчен Ватаныбызны якладылар. Кешеләр солдатларның батырлыгын хәтерлиләр һәм бу һәйкәлне алар хөрмәтенә төзегәннәр.

*14слайд.*



**Тәрбияче.** Шәһәр паркына килеп җиттек, әйдәгез кереп ял итик.

Ял минуты.

Хәзер бераз зарядка ясарбыз. Барыбыз да матур итеп басабыз

Туган илебез бик зур *(куллар якка җәелә).*

Мул сулы елгалар буйлап матур кораблар йөзә (*куллары белән дулкыннар сурәтлиләр)* .

Урманнарда биек агачлар үсә *(куллар өскә күтәрелә)*

Урманнарда кәкре аяклы аюлар, соры куяннар, хәйләкәр төлкеләр яши (*аюлар,куяннар, төлкеләр булып йөриләр)* .

Болыннарда төрле төстәге күбәләкләр оча, чикерткәләр сикерә*(күбәләкләр һәм чикерткәләр сурәтләнә)*

*15слайд:*

**Тәрбияче.**Ял иттек, алга таба барабыз. Парк янында районыбыз мәдәният йорты урнашкан. Сез ничек уйлыйсыз, ул нәрсә өчен? *(җаваплар).* Дөрес, монда кешеләр ял итә, концертларга, спектакльләргә йөри. Балалар җырлыйлар, бииләр, талантларын үстерәләр.

Без дә »Капкалы» татар халык уенын уйныйк.

*16 слайд:*

**Тәрбияче.**Шәһәрдәбикматурбоз сарае бар. Сез ничек уйлыйсыз, анда нәрсә эшлиләр?*(Тимераякта шуалар).*Нинди спорт төрләрендәтимераякташуалар? (х*оккей, фигуралышуу)*

*17 слайд*: **Тәрбияче.**Хәзер без кайда килеп җиттек? *(Без балалар бакчасына килдек.*)Безнең сәяхәтахырынаякынлаша. Автобустанчыгыгыз.

**III. Йомгаклау.**

Туп белән уен «Безнең шәһәр нинди?»

**Тәрбияче**. Бу уенда һәркайсыгыз шәһәребез турында сөйләргә тиеш. Беренче сорау: безнең шәһәр нинди? *(Безнең шәһәрматур, чиста, яшел, заманча, чәчәкле, искиткеч, кунакчыл, күпмилләтле...).*Шәһәребезне ни өчен яратасыз? *(Мин Әгерҗене мәктәпләр, скверлар, парклар, бакчалар,өем, дусларым анда булган өчен яратам)*Бүген без Әгерҗе турында күп белдек. Сезгә Әгерҗе шәһәренең кайсы уены кызык булды? Бу турыда кемгә сөйләрсез? Бүгенге сәяхәт исегездә калыр дип уйлыйм. Бүген үзегезне чын патриотлар итеп күрсәттегез. «Әгерҗе районының яшь патриоты» медале белән бүләкләнәсез.Үз тәэсирләрегезне калдыру өчен шәһәр планын төзергә тәкъдим итәм. Күргәннәребезнең нindиэзлеклелектә булуын искә төшерегез. Мин без барган юлны әзерләдем, ә сезгә юл буендагы биналарны ябыштырырга калды. Өстәлдәге фотолар, рәсемнәр арасыннан кирәклесен сайлап, бергәләп Әгерҗе шәһәренең планын төзибез.

**Мәктәпкә әзерлек төркемендә шөгыль конспекты**

**“Туган авыл буйлап сәяхәт”.**

*Шәйхиева Гөлсинә Мансур кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе тәрбиячесе*

**Максат:** балаларда кече Ватанга карата мәхәббәт формалаштыру.

**Бурыч:**

Балаларны кече Ватан тарихы белән кызыксындыру, туган һәм яшәгән урыннары, авылдашлары өчен горурлык хисе тәрбияләү.

Балаларның сөйләм активлыгын арттыру.

Балаларны сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтү.

**Җиһазлау**: мультимедиа проектор, компьютер.

**Сүзлек**: балалар бакчасы, мәктәп, кибет, китапханә, элемтә бүлеге,мәдәният йорты.

**Шөгыль барышы:**

***1.* Оештыру өлеше.**

**Тәрбияче :** Матур итеп елмаеп

Исәнләшик дусларым.

Малайларым, кызларым

Исәнмесез дусларым!

**Сәламләү “Дуслык түгәрәге”**

**Тәрбияче :** Әйдәгез әле,балалар, түгәрәк ясап басыйк әле.(түгәрәктә)

Түгәрәктә җыелышып

Басыйк әле бергәләп.

Син-минем дус,

Мин-синең дус

Яшик шулай бергәләп.

Балалар, кәефләрегез ничек?

**Балалар:** Яхшы.

**Тәрбияче:**Балалар, игътибар белән мине тыңлагыз әле.

Кадерледән дә кадерле

Туган үскән ил генә.

Чит-ят җирләр күп булса да

Туган илем бер генә.

Балалар, элеге шигырьдән өзек нәрсә турында икән?

**Балалар:** Туган ил турында.

**Тәрбияче:**Әйе, бик дөрес.Җир йөзендәге һәр кешенең туган иле бар. Ә сез ничек уйлыйсыз, нәрсә икән ул Ватан?

**Балалар: (җаваплар)**

Ватан ул-без туган һәм яшәгән ил.

Ватан ул-бу безнең ата-бабаларыбыз яшәгән, эшләгән җир.

Ватан ул-безнең туган авылыбыз.

Ватан ул -безгә якын һәм кадерле кешеләр әни, әти ,аби, бабай яшәгән урын.

Ватан ул-безнең балалар бакчабыз.

Ватан ул- кайдадыр чит җирдә булып, үз торган ягыңны сагыну.

**Тәрбияче:** Рәхмәт, балалар. Без яши торган ил ничек дип атала?

**Балалар:** Рәсәй дип атала.

**Тәрбияче:**Илебезнең искиткеч матур исеме бар - Рәсәй. Җирдә бик күп искиткеч илләр бар, һәр җирдә кешеләр яши, әмма Рәсәй бердәнбер, гадәти булмаган ил, чөнки ул Безнең Ватаныбыз! Без бөек Ватаныбыз белән горурланабыз. Рәсәй, балалар, дөньядагы иң зур ил.

**Тәрбияче:**Балалар, сез күп мәкальләр беләсез. Туган ил, Ватан турында нindиләрен беләсез икән?

**Балалар:** (җаваплар)

*Ватаны юк - җырсыз сандугач.

*Илсез кеше - җырсыз сандугач

*Туганилем - тугананам.

* Ватан барыннан да газиз.

**Тәрбияче:** Балалар, бәлки берәрегез туган як турында шигырь сөйләр?

**Исмат:**

Ал чәчәкле туган җиребез

Гөл чәчәкле туган җиребез.

Җир шарында кояш булып

Балкый безнең туган җиребез.

**Милана:**

Якындагыурманда

Шаулапүсә пар каен.

Чәчәкататуганҗирем

Матурланакөнсаен.

**Тимур:**

Ниндиматур минем туганҗирем

Җиршарындатиңдәшюкаңа.

Киң кырлардаүсә мул игеннәр

Авылымныуратыпалганзуркүл.

Авылымның матурлыгын

Сөйләптүгел, җырлапбирәм,

Чөнкитуганавылымнысезнең кебек,

Чынкүңелдәнөзлепсөям.

**Тәрбияче:** Искиткеч матур шигырь сөйләдегез, балалар.Рәхмәт сезгә! Чыннан да безнең Тирсә авылы-ул безнең кече Ватаныбыз, туган авылыбыз.

**Тәрбияче:**Әйдәгез, хәзер матур Ватаныбызның картасы янына килик әле. Менә бу балалар, безнең Татарстан җөмһүрияте (картадан күрсәтәм). Без монда яшибез. Төп шәһәребез ул-Казан шәһәре.(картадан күрсәтәм). Ул элеге картада зур түгәрәк белән күрсәтелгән. Монда ук безнең кече Ватаныбыз-Әгерҗе районы Тирсә авылы. Ул-туган җиребез, туган авылыбыз.

**Тәрбияче:** Бүген үзебезнең туып үскән җир турында сөйләшик әле. Һәрбер кешенең җирдә туып-үскән урыны бар. Ул беренче тапкыр таңны, үләндәге чыкны, назлы кояшны шунда күргән. Бу урын кече Ватан дип атала. Безнең өчен кече Ватан-ул туган авылыбыз Тирсә. Сез туган авылыгызны яратасызмы?

**Балалар:** Әйе, туган авылыбызны яратабыз.

**Тәрбияче:** Сез ни өчен туган авылыгызны яратасыз? Моның өчен уен уйнап алабыз. Мин сезгә түгәрәк буенча тупны җибәрәм, ә сез минем сорауга җавап бирерсез.

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз, балалар, афәрин. Әйтегезче миңа, ни өчен туган якны кече Ватаныбыз дип әйтәләр икән?

МИНЕМ-чөнки монда минем гаиләм, минем дусларым, минем йортым, минем урамым.

КЕЧЕ- чөнки ул, минем зур Ватанымның бер кечкенә өлеше.

ВАТАНЫМ-чөнки монда миңа иң якын кешеләр яши.

**Тәрбияче:** Балалар, бер урында туып шунда үскән кешеләрне кем дип әйтәләр икән? (Якташлар) Менә безнең якташлар да туган як турында бик матур шигырьләр язып калдырганнар. Тыңлап үтик әле.

**Ч.Мусин "Әгерҗе таңнары"**

Таң белән уяна Әгерҗем,

Ил гизгән поездлар шавына.

Хөрмәткә лаеклы кешеләр,

Яшиләр Әгерҗе ягында.

**"Тирсә иртәләре"**

Таң кояшы нурын сипте,

Гөлләрне иркәләде.

Якты нурларга төренде,

Кошлар моңына күмелде

Тирсәнең иртәләре.

**Тәрбияче:** Чыннан да, бик матур шигырьләр. Ә хәзер инде бераз ял итеп алабыз.

Безнең илдә биек таулар (аяк очларында өскә күтәреләләр)

Тирән елгалар (чүгәлиләр)

Киң далалар (кулларын як-якка сузалар)

Куе урманнар (куллар өстә)

Һәм менә дигән балалар.

**Тәрбияче:** Балалар, Ватанны нинди матур сүзләр белән атап булыр иде? Нинди ул безнең Ватаныбыз?

**Балалар:** Безнең Ватаныбыз матур, зур.

**Балалар:** Безнең Ватаныбыз көчле.

**Тәрбияче:** Сезнең үзебезнең кече Ватаныбыз буенча сәяхәткә барасыгыз киләме?

**Балалар:** Әйе, сәяхәт итәсебез килә.

**Тәрбияче:** Иң элек без сезнең белән фотокүргәзмә карарбыз.Игътибар белән карагыз әле, нинди таныш урыннарны күрәсез?

**Тәрбияче:** Инде юлга кузгалырга вакыт җитте.Сәяхәткә җәяүләп барырбыз.

**(Музыка яңгырый, балалар исәнләшеп үтәләр)**

**Тәрбияче:** Балалар, ни өчен сез исәнләшәсез?

**Балалар:** Авылда кешеләр бер-берсен беләләр, шуңа исәнләшергә кирәк.

*(экранда авыл панорамасы)*

*Балалар урындыкларга утыралар*

***<u>Беренче тукталыш-балалар бакчасы</u>***

**Тәрбияче:** Бу нинди тукталыш икән?

**Балалар:** Бу безнең “Миләүшә” балалар бакчасы.

**Тәрбияче:** Балалар бакчасы ни өчен кирәк икән?

**Балаар:** Безгә дуслар белән уйнарга кирәк.

**Тәрбияче:** Кемнәр эшли икән балалар бакчасында?

**Балалар:** Балалар бакчасында тәрбиячеләр, пешекчеләр, тәрбияче ярдәмчеләре эшли.

**Тәрбияче:** Алар бакчада нишлиләр?

**Балалар:** Алар безне тәрбиялиләр, җырларга, биергә, өйрәтәләр, ашарга пешерәләр.

**Тәрбияче:** Сез бакчада нәрсәләр эшлисез?

**Балалар:** Без бакчада уйныйбыз, җырларга,биергә өйрәнәбез.

**Тәрбияче:** Бик дөрес, балалар.

***<u>Икенче тукталыш “мәктәп”</u>***

**Тәрбияче:** Сәяхәтебезне дәвам итәбез. Киләсе тукталыш-мәктәп. Сез ничек уйлыйсыз, мәктәп ни өчен кирәк?

**Балалар:** Мәктәп укыр өчен кирәк.

**Тәрбияче:** Мәктәптә кемнәр эшли?

**Балалар:** Мәктәптә укытучылар эшли.

**Тәрбияче:** Сезнең мәктәпкә барасыгыз киләме?

**Балалар:** Әйе, укыйсы килә.

**Тәрбияче:** Менә 1 сентябрь җиткәч сез мәктәпкә барачаксыз. Анда сезне күңелле укулар көтәчәк. Хәзергә без әле балалар бакчасына йөрибез. Юлыбызны дәвам итәбез.

***<u>Өченче тукталыш-элемтә бүлеге</u>***

**Тәрбияче:** Бу тукталыш нинди тукталыш икән?

**Балалар**: Бу-элемтә бүлеге.

**Тәрбияче:** Безгә ни өчен элемтә бүлеге хезмәте кирәк?

**Балалар:** Элемтә бүлеге хезмәткәрләре кешеләрдән хатлар, посылкалар кабул итәләр. Аларны икенче адреска җибәрәләр.

**Тәрбиячсе:** Элемтә бүлегендә кемнәр эшли?

**Балалар:** Элемтә бүлегендә  хат ташучылар, кассирлар эшли.

**Тәрбияче:** Бик дөрес. балалар.

***<u>Дүртенче тукталыш-мәдәният йорты</u>***

**Тәрбияче:** Ә бу безнең Мәдәният йорты. Монда матур кичәләр, концертлар оештыралар. Җыр, бию түгәрәкләре эшли.

Б***ишенче тукталыш-китапханә***

**Тәрбияче:** Ни өчен китапханә кирәк?

**Балалар:** Китапханә матур китаплар, журналлар саклар өчен кирәк.

**Тәрбияче:** Кем ул китапханәче?

**Балалар:** Ул китапханә хезмәткәре. Безгә кирәкле китаплары табарга ярдәм итүче.

**Тәрбияче:** Бик дөрес, балалар.

***Алтынчы тукталыш-кибет***

**Тәрбияче:** Кибет ни өчен кирәк?

**Балалар:** Кибет кирәк-яраклар алыр өчен кирәк.

**Тәрбияче:** Сезнең кибеттә булганыгыз бармы?

**Балалар:** Әйе, кибеттә булган бар.

**Тәрбияче:** Кибеттә әйбер сатучы кешене кем дип йөртәләр?

**Балалар:** Аларны сатучы дип атыйлар.

**Тәрбияче:** Әйбер алыр өчен кергән кешеләрне кем дип атыйлар?

**Балалар:** Алар сатып алучылар булалар.

**Тәрбияче:** Балалар, сез нинди кибетләр беләсез?

**Балалар:** Ашамлыклар, киемнәр, уенчыклар, китаплар кибетләре була.




**Тәрбияче:** Әфәрин, балалар. Без бүген кече Ватаныбыз-туган авылыбыз турында сөйләштек. Туган авылыбыз шундый матур булсын өчен нинди эшләр башкарырга кирәк икән?

**Балалар:** Туган авылны яратырга кирәк. Агачлар, чәчәкләр белән бизәргә кирәк.

**Тәрбияче:** Кадерле балалар! Үзегезнең Ватаныгызны яратыгыз. Авыл тарихы турында күп белергә тырышыгыз. Авылның табигатен саклагыз.Милли гореф-гадәтләрне, йолаларны онытмагыз. Авыл яшәсен, чәчәк атсын өчен яшәгез һәм тырышыгыз.

## Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты
## «*9 май – Җиңү бәйрәме*»

*Хәкимова Алсу Разим кызы,*
*Татарстан Республикасы*
*Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәре*
*муницпиаль бюджет 1 нче мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениясе*
*“Алтын ачкыч” балалар бакчасы тәрбиячесе*

**Максат:** балаларда туган илне ярату, аның белән горурлану хисләре тәрбияләү.

**Тәрбия бурычы**: патриотик хисләр, туган якка, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.
**Үстерү бурычы**: туган ил турындагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү.
**Белем бирү бурычы:** сугыш турында, 9 май –Җиңү бәйрәме турында балаларның белемнәрен арттыру.
**Төп белем бирү өлкәсе**: танып белү.
**Интеграль белем бирә өлкәләре**: аралашу, социальләштерү, музыка, иҗади сәнгатъ.
**ЖиҺазлау:** слайдлар, рәсемнәр, төсле кәгазъләр, кайчы, клей-карандаш, трафаретлар.
**Сүзлек өстендә эш:** ветеран, "Георгий" тасмалары, Һөҗүм, кыю, хәтер, батыр, патриот, парад.
**Алдан үткәрелгән эш**: әңгәмәләр, альбомнар карау, шигырьләр, хикәяләр уку.
**Әшчәлек төзелеше**:

1. Шигырь уку.
2. Төп өлеш.
3. Практик әш (рәеем ясау).
4. Йомгаклау.

**Эшчәнлек барышы**.
**Тәрбияче.** Балалар, мин бүген бакчага барганда бик сөенеп бардым. ШәҺәребез чиста, урамнар матур итеп бизәлгән, баганаларда әләмнәр эленгән, кешеләр киемендә георгиевский ленталар. Озакламый нинди бәйрәм җитә, әйтегез эле? *(Җиңү көне).*

Һәммәбез сагынып
Көттек май килүне.
Китерә ул безгә
Иң Бөек Җиңүне.

- Нәрсә ул Җиңү көне?
- Ни өчен Һәр елны билгеләп үтәләр?
- Георгий" тасмалары нәрсәне аңлаталар?
- Кемнәр ул ветераннар?
- Сезнең ветеран бабаларыгыз бармы?
- Сез аларны ничек хөрмәтлисез?
- Орден, медальләрне аларга ни өчен биргәннәр?
- Җиңү безгә нәрсә китерде?
- Сезнең бу җиңү парадында катнашканыгыз бармы? *(балаларның җаваплары).*




**Тәрбияче**. Балалар, мине игътибар белән тыңлагыз Һәм экранга карагыз. Күп еллар элек сезнең кебек балалар яшәгәннәр, аларның үз гаиләләре, әти-әниләре, әби-бабайлары, энекәш-сеңелкәшләре булган. Сезнең кебек алар бакчага йөргәннәр, уйнаганнар, көлгәннәр. Олылар эшкә йөргәннәр. Кызлар курчаклы уйнарга яратканнар, бер-берсенә "кунакка" йөрешкәннәр. Малайлар машина белән уйнарга яратканнар. Иң яраткан уеннары "атышлы" уены булган. Алар гади таякларны мылтык итеп тотып солдатлы уйнаганнар.
-Малайлар, бу балалар сезгә ошаганнармы?
-Сезнең малайлар яраткан уеныгыз, нинди уен? *(балаларның җавабы).*
**Тәрбияче**. Ләкин көннәрдән бер көнне илебезгә зур кайгы килә. Бик начар кешкләр безнең илебезгә Һөҗүм итәләр. Алар иң тыныч вакытны, бөтен кешеләр йөклаган вакытны сайлыйлар. Самолетлар ярдәмендә илебез авыл, шәҺәрләренә бомбалар ташлыйлар. Йөрт-

җирләр җимерелә, ташка әверелә, бөтен җирдә ут, тотен, кешеләр яраланалар, үләләр. Шулай итеп бөек Ватан сугышы башлана...

**Тәрбияче**. Балалар, сезгә сугыш турында әби –бабаларыгызның сөйләгәне бармы? *(балаларның җаваплары).* Безгә Самат үзенең бабасы турында сөйләп узар.

**Самат.** Минем карт бабайларым сугышта булганнар. Алар, үз-үзләрен кызганмыйча фашистларга каршы көрәшкәннәр, аларны илебездән куганнар. Күп вакыт ашарларына, эчәрләренә дә булмаган. Ләкин алар бердәм булганнар, шуның өчен сугышта җиңгәннәр. Галимулла бабам сугышта үлеп калган, ә Фатих бабам яраланып, бер кулсыз сугыштан әйләнеп кайткан. Мин анаң портреты белән һәр елны парадта катнашам.

**Тәрбияче.** Рәхмәт Самат. Бабаларыңа, безгә тынычлык, бәхет алып килгән кешеләргә рәхмәт.

Начар кешеләр, алар фашистлар дип аталалар. Алар бер нәрсәне дә, бер кешене дә кызганмыйлар. Шәһәр, авылларны җимерәләр, ут тортеп яндыралар, кешеләрне, рәхимсез җәзалыйлар һәм үтерәләр.

Шуларга каршы илебездәге бар кешеләр; бабайлар, әтиләр, абыйлар, апалар кулларына корал алып илебезне якларга, сакларга, сугышка китәләр. Ә корал ясый торган заводларда, төрле фабрикаларда, кырларда бар көчләрен кызганмыйча әби –апалар, балалар эшлиләр. Кай вакыт аларның ашарларына да булмый, бәрәңге кабыгын пешереп ашыйлар. Ләкин аларның берсе дә зарланмый...Безнең Нуриманның әбисенең әбисе турында сөйлисе килә.

**Нуриман.**Сугыш башланганда минем әбиемә 9 яшь кенә була. Әтисен, бабасын сугышка җибәрәләр. Әниләре янында иң зур бала булып ул кала. Әнисе белән фермага сыер саварга йөри, печән чабалар, утын әзерлиләр, сугышчыларга оекбашлар бәйлиләр. Җиңү көнен якынайтыр өчен бар көчләрен биреп эшлиләр.

**Тәрбияче**. Әйе, әбиләр, әниләр, балалар җилкәсенә күп авырлыклар төшә. Сугыш илебезгә бик күп кайгы китерә. Аның турында без сезгә күп сөйләдек, кинолар карап та беләбез. Мин сезгә Ленинград блокадасы турында да сөйләгәнем бар.

**Тәрбияче**. Фашистларны илдән куып чыгару җиңел булмый. Чөнки алар ныклап әзерләнгән булалар, аларның самолет, танклары, төрле кораллары күп була.

Сугыш озак дәвам итә. Күп кешеләр сугыш кырында мәңгегә калалар. Сезнең кыю, батыр бабаларыгызның көче ярдәмендә безнең илебез җиңә. Шуның өчен 9 май- Җиңү көнен без һәр елны зурлап билгеләп үтәбез. Соңгы елларда бабайларыбызның портретларын кулыбызга алып парадка чыгабыз, мәңгелек утка чәчәкләр куябыз, ветераннарыбызны зурлыйбыз.

-Кем инде ул ветеранар? (кем безгә тынычлык алып килде).

-Тагын ветераннарга нәрсә бүләк итәргә була? (чәчәкләр, открыткалар).

**Тәрбияче**.Хәзер үзегезнең урыннарыгызга утырыгыз, һәм открытка ясый башлыйбыз *(балалар төсле кәгазьдән үзләре теләгән чәчәкләрне кисеп открытка ясыйлар).*

**Рефлексия.**

- Сезгә ясаган открыткаларыгыз ошадымы?

-Сез ветераннарга нәрсә әйтер идегез? (безгә тыныч тормыш, аяз күк йөзе бүләк иткән өчен рәхмәт әйтәбез, озак яшәгез)

- Сез үскәчтен илебезне дошманнардан сакларга әзерме?
- Аның өчен нинди булырга кирәк?
- Кем ул патриот? *(балаларның җавабы).*

**Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары, ата- аналары өчен**
**“ Шигырьләрем- күңеллем көзгесе” исемле күңел ачу кичәсе сценарие.**

*Ибәтуллина Ильсинә Хәмит кызы,*
*Татарстан Республикасы*
*Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәре*
*муниципаль бюджет 1 нче мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениясе*
*“Алтын ачкыч” балалар бакчасы тәрбиячесе*

**Максат:** тормышка һәр яктан әзер, камил, үз милләтенең, матди һәм рухи байлыкларын арттыручы, туган халкының киләчәген кайгыртучы шәхес тәрбияләү.
**Бурычлар:** халкыбызның милли үзенчәлекләрен, күркәм сыйфатларын, йола гадәтләрен, гаилә этикасын кече яшьтән үк төшендерү, балаларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләү, кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә өйрәтү, югары әдәп, әхлак сыйфатлары булдыру, иҗади сәләт һәм милли үзаң формалаштыру.
**Кичә барышы:**
Җыр “Күңелле безнең шәһәр”
Күңелле безнең шәһәр
Ямьле язларда килсәң әгәр,
Иж сулары акканда
Күңелле безнең шәһәр.
Күңелле безнең шәһәр
Ямьле язларда килсәң әгәр,
Кошлар очып кайтканда
Күңелле безнең шәһәр.
Күңелле безнең шәһәр
Ямьле язларда килсәң әгәр,
Кояш нурын сипкәндә
Күңелле безнең шәһәр.
Күңелле безнең шәһәр
Ямьле язларда килсәң әгәр,
Без елмаеп торганда
Күңелле безнең шәһәр.
**А.б**. Хәерле көн, балалар! Хәерле көн, кадерле кунаклар,хөрмәтле әти-әниләр! Карагыз әле, безнең балалар бакчасына күпме кунак килгән! Без аларны күптән көттек. Шуңа күрә сезне күрүебезгә бик шатбыз!

Безнең кунаклар арасында,бер гадәти булмаган кунагыбыз бар. Ул үзенең шигырьләре белән күпләрне сокландырган язучы, шагыйрә апа. Безнең “Әгерҗе хәбәрләре” газетасы редакциясендә эшли. Әйдәгез, аны эзләп табыйк әле. Ә мин сезгә аны табарга ярдәм итәрмен:ул- көләч йөзле, сөйкемле, яшел күзле, өстенә _____ кигән. Ягез, балалар күрсәтегез әле аны.

Бу апа, балалар, без яратып укый торган бик күп шигырьләр, хикәяләр иҗат итүче. Әйдәгез әле, аны бәйрәмебезнең түренә чакырыйк. Узыгыз, Асия апа!

*(балалар шигырь өстәле янына чәчәкләр утырталар)*

**А.б.** Шигырьне язам димиләр, шигырь тудырам диләр. Асия апа,үзегез турында, иҗатыгыз турында безнең балаларга, кунакларга сөйләп китегез әле. Кайдан сез, шигъриятькә тартылуыгыз кечкенәдән башландымы, нәрсә сезне кулыгызга каләм алырга этәрде?

**(Асия апа Корбангалиева сөйләве)**

**А.б.** Моңнарым да, җырларым да,

Эшем дә - туган илгә - дип яза Асия апа. Чыннан да туган илгә мәхәббәт Асия апаның каләме астыннан чыккан һәрбер шигъри юлда чагыла. Аның шигырьләре дә табигатебез кебек бай, анда туган якның иләс җиле дә, болынын да кызарып пешкән җиләге дә, җир куеныннан саркып чишмәсе дә, бөдрә таллар ышыгында назланып кына үскән бөрлегән куаклары да үз тормышы белән яшиләр,җанлы бер зат булып күз алдына килеп басалар. Минемчә, табигать белән тыгыз элемтәдә торган, киң күңелле, мәрхәмәтле зат кына үзенең туган табигатен зурлый, хөрмәтли,аңа дан җырлый ала. Шуның мисалы булып Айдар безгә Асия апа Корбангалиеваның “ Туган ил” дип аталган шигырен укып узар:

1. **Айдар**

Туган ил - чишмә агышы,
Ул- сандугач тавышы.
Басуларда җәйрәп үскән
Карабодай, арышы.
Туган ил ул – сукмакларым,
Өзелеп сайрар кошларым.
Өем эти һәм әнием,
Минем якын дусларым.

**А.б.** Әйе, туган илне ярату, аны хөрмәтләү, аңа дан җырлау Асия апа иҗатында төп теманы тәшкил итә. Аның Тирсә, Салагыш, Уразай, Шаршады авылларына багышлап иҗат иткән шигъри юлларын укыганда һәр кеше үзенең туган авылына, туган йортына әйләнеп кайткандай була. Ә безнең барыбызның да уртак йортыбыз, нинди генә чит җирләрдән дә сагынып җирсенеп кайта торган гүзәл туган җиребез – Татарстаныбыз да Асия апа шигырьләрендә бар татар мөселманны үзенә чакырып, берләштереп торучы образ буларак күз алдына килеп баса. Хәзер укылачак “ Татарстан байрагы ” дип аталган шигыре дә шул образны тулыландырып, яктыртып җибәрә. Әйдә, Динар, рәхим ит!

2. **Динар:**

Кызыл, ак һәм яшел төсле
Байраклы ул Татарстан.
Кызыл төс кояш, ут төсе,
Шуңа күрә яратам.
Яшел төс – яшәеш, яшьлек.
Ак – чисталык символы,
Намус, тынычлык сөюнең
Татарстан – мисалы.

**А.б.** Ишетәсезме? Асия апаның шигырьләреннән нинди моң, аһәң тарала? Аларны укыганда ук инде көйгә салып моңлы бер җыр итеп сузасы килә. Моны мин генә әйтмим композиторыбыз да шулай уйлый икән. Ул Асия апа Корбангалиеваның“Серле төн”дип аталган шигыренә көйдә язган икән. Хәзер безгә аны тагын бер кунагыбыз башкарып үтәр

***Җыр:“Серле төн” .***

**3.Динара**

Җырлау әйбәт
Бию дә шәп.
Тик барыбер
Шигырь кирәк.

**А.б.** Дөрес әйтәсең, Динара, шигырь кеше күңеле өчен бик кирәк. Кеше шигырь укып үзенә рухи азык,җан тынычлыгы таба. Шигырь аша нәрсәгәдер өйрәнә, дөньяга карашы тирәнәя. Асия апа да үз укучысын һаман да бөеккә өнди, кече яшьтән үк аларга әдәп - әхлак нормаларын көндерә бара. Кеше белән кеше арасында дустанә мөгаләмә урнаштыру җаен өйрәтә. Ә моның иң гади юлы – кеше белән ачык итеп исәнләшергә кирәклеген әйтә. Яле, Эльвина, Асия апа өйрәткәннәрне безгә дә әйтеп уз әле!

**4. Эльвина:**

Очраштык та дустым белән,
Исәнләштек баш иеп.
Елмаеп күрешкәч әйттек:
Исәнме, дускай! – диеп.
Артты кояшның нурлары
Артты дөньяда шатлык.
Бер елмаю тудыра ала
Яктылык, бәхет, шатлык.

**А.б.**Әйтеп узылганча, Асия апа шигырьләрендә әдәп, әхлак, тәрбия темалары аеруча зур урын алып тора, аны борчыган мәсьәлә - буыннар чылбыры бәйләнеше. Өлкән буын элеккедән калган гадәтләрне балаларга, аларның балаларына тапшырып килмәсә, милләтебез югалыр иде. Аталар белән балалар арасында булган җылы мөнәсәбәтне зурлап чыга авторыбыз. Шуның бер мисалы “ Эшчән сыерчык” шигырен безгә Руслан әтисе белән бергәләп укып күрсәтерләр:

**5.Руслан әтисе белән**

Әти, күрче,бу каенга
Сыерчыклар килгәннәр.
Тыз-быз оча, кортлар ташый,
Җәй җиткәнне белгәннәр.
Әйтче ,әти, көнгә алар
Ничә кортны ашыйлар?
Күрәсеңме, көне буе
Бер туктаусыз ташыйлар.
Ничә тапкыр очканлыгын
Әгәр беләсең килсә,
Каен төбенә утыр да,
Таякчык сыз очты исә.
Утырып каен төбенә
Өч сәгать сызып бардым.
Килде сыерчык ояга,
Беләсеңме, йөз дә ун!
Шуңа кошлар – дуслар, улым,
Корткычларны ашыйлар,
Уңышлар мул булсын диеп
Басуларны саклыйлар.

**А.б.** Әйе, Асия апа үз шигырьләре аша яшь буынны тәрбияли, өлкәннәрне хөрмәтләргә өйрәтә. Иң газиз кешеләребез, ата- аналарыбызны зурларга, кадерләргә өнди. Аларны үз баласы  өчен утка да, суга да керергә әзер торучы изге зат итеп сурәтли. Сез моны үзегез дә хәзер Данис укып китәчәк сүзләрдән аңларсыз.

**6. Данис**:

Әтиләр нинди булалар?
Минем әти күк була.
Кирәк булса,баласы өчен
Керә утка һәм суга.
Шаккатырлык, әти, синдә
Тырышлык һәм сабырлык.
Максатым шул: йөзеңә мин
Китермәмен кызыллык.

**А.б.** Әфәрин, Данис, рәхмәт! Ә без Асия апаның иҗат җимешләре турында сөйләвебезне дәвам итик. Менә шулай, аны гүзәллек җырчысы иткән табигатьне зурлап, туган илен яратып, яши дә яши шагыйрәбез. Аның шигырьләрендә хис-кичерешләре, уй-фикерләре яңгырый һәм укучыга җан дәвасы булып барып җитә. Руслан безгә хәзер Асия апа иҗат иткән иң яраткан шигырен укып узар.

**7. Руслан:**

Рәхмәт яусын, иртәләрем,
Һәр көн саен арта минем
Сезне ярату көчем.
Рәхмәт яусын сиңа, кояш,
Юлым яктырткан өчен.
Сулыйм күкрәгем тутырып
Хуш исле чәчәк исен.
Рәхмәт сезгә, чишмәләрем,
Сезнең су – яшәүгә көч ул
Тормыш юлын кичкәндә.

**А.б.**Җырлыйбыз да, биибез дә,һәм дә шигырь укыйбыз,
Күңелләрне күтәреп, бераз уйнап алыйк без!

*Уен:" Кәрия-Зәкәрия".*

**А.б.** Дөньда ничә тел бар? Һәм аларда ничәмә ничә сүзләр?! Ә үзебезнең татар телендә? Миллионлаган сүзләр!!! Сүзләрнең дә төрлесе: яхшысы – яманы, акыллысы – шаяны һәм бик күпләр, бик күпләр. Асия апа шигырьләрен укып без дә сүзләр дөньясына чумдык!

"Сүзләр дөньсында"

**А.б.** Матур сүзләр өйрәндек без:
**Динара:** Күңел, мәктәп, гөл,ямь
**А.б.** Мәгънәле сүзләр ятладык:
**Булат:** Кеше, дәүләт, җыр гамь.
**А.б.** Бакчабызда баллы сүзләр:
**Женя:** Чия, шомырт, алма.
**А.б.** Ачы сүзләрдә күп икән:
**Аделина:** Суган, балан, торма.
**А.б.** Ә урманда бик күп сүзләр:
**Әнисә:** Чыршы, нарат, каен.
**А .б.** Күңелләрдә бөек сүзләр:
**Данис:** Яшәү, сөю, максат.
**А.б.** Табигать безгә өйрәтте:
**Айдар:** Кояш, һава, таш, су.
**А.б.** Матур сүзләр бик күп икән:

**Руслан:** Яшел, зәңгәр, алсу.
**А.б.** Ә болары иң бай сүзләр:
**Эльвина:** Ашлык, белем, акча.
**А.б.** Күңелле сүзләр дә белдек:
**Яна:** Дуслык, хезмәт, бакча.
**А.б.** Кадерле сүзләр кешегә:
**Динар:** Әти, әни, Ватан.
**А.б.** Туган илем, туган телем –
**Динара:** Беләм күптән яттан!
*(Җыр"Туган тел").*
**А.б.** Менә шулай уйламаганда, матурлык дөньясына алып кереп киттегез безне, Асия апа! Сезнең шигырьләрне укыйбыз да, ләззәтләнеп урман-болыннарда йөреп, салкын чишмәләрнең татлы суын эчеп кайткан кебек булабыз. Я, көтмәгәндә, авыр язмышлар белән очрашасың да, сагыш дөньясына төшеп уйга каласың, я туган төбәкнең күренекле шәхесләрен моңарчы белмәгән яктан ачып, гаҗәпләнеп утырасың. Шуларның барсы-барсы өчен дә рәхмәт сезгә Асия апа! (чәчәкләр бирү)
**А.б.** Әле безнең килгән кунакларыбызның да әйтәсе сүзләре калгандыр:
**А.б.** Ә хәзер сүзне шушы кунакчыл йортыбызның хуҗабикәсе- ______________________ бирәбез. Рәхим итегез!
**А.б.** Шуның белән ,безнең " Шигырьләрем- күңеллем көзгесе" дип аталган әдәби кичәбез тәмам. Алга таба да мондый очрашулар кабатланыр дигән ышаныч белән саубуллашабыз.

## Зурлар төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты "Минем гүзәл җирем"

*Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе*
*Кадыбаш урта гомумбелем бирү мәктәбе тәрбиячесе.*

**Максат:**
Туган ил, туган йортны ярату,аны зурлау, аның белән горурлану хисләрен тәрбияләү.
Балаларның логик фикерләү сәләтен, хәтерен, диалогик сөйләм телен үстерү.
**Җиһазлау**: Рәсемнәр,слайдлар, аудиоязмалар, "Туган тел" "Кадыбаш"җыры.
**Сүзлек:** татлы тел, гөлбакча, милләт.
**Эшчәнлек барышы:**
**Тәрбияче**: Хәерле көн,балалар! Кәефләрегез ничек? (*яхшы*)
**Тәрбияче**: Без үзебезнең яхшы кәефне, матур елмаюыбызны башкаларга да бүләк итик әле.
**Балалар:** (бергә)
Кулларымны сузам сиңа
Дустым елмаеп –көлеп.
Кушылсыннар башкалар да
Безнең дуслыкны күреп.
**Тәрбияче:** Туган ил була бер генә,туган илнең кадерен бел генә.
**Тәрбияче:** Мәкәлдә сүз нәрсә турында бара?
**Балалар:** Туган җир, туган як турында.

**Тәрбияче:** Балалар, без бүген сезнең  белән туган җир, туган як, туган тел турында сөйләшербез. Әйтегез әле: туган як сүзенең мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз?
**Балалар:** Туган як ул –безнең туган җиребез.
**Тәрбияче:** Балалар,туган як ул – кешенең туган җире. Менә безнең өчен туган җиребез ул - Татарстан Республикасы.Әйдәгез әле,без яшәгән авыл ничек дип атала? Сез аны яратасызмы? Ни өчен? Безнең авылда нинди урамнар бар? Исемнәре? (Балалаларның җаваплары)
**Тәрбияче:** Әйе,без яшәгән җиребез бик матур. Аның тирә-ягында җиләкле, гөмбәле урманнары, тирән сулы елгалары, күлләре бар.
Иркен һәм матур да
Урманга бай,суга бай.
Безнең туган илебез
Гөлбакчалы җиребез.
*(Кошлар сайраган тавыш ишетелә.Залга сандугач  булып киенгән бала керә, кош булып йөри ,кулында хат)*
**Сандугач:**
Бик ерактан канат кагып,
Диңгез  кичеп, арып –талып
Туган җирне сагынып кайттым.
Мин булам сандугач
Исәнмесез, балалар! Мин бик ерактан килдем сезгә. Сездә иркен болыннар, яшел урманнар, чиста сулы күлләр бик күп икән. Кешеләрегез бик ягымлы, ярдәмчел, барда татар телендә сөйләшә.
**Тәрбияче**: Эйе, бездә табигать матур.
**Карлыгач:** Мин сезгә бер хат алып килдем. Аны миңа бер малай җибәргән иде.Ләкин хатны биргәнче, туган як турында белемнәрегезне тикшереп карыйсым килә.Мин сезгә табышмаклар әйтәм .Ә сез җавабын әйтәсез.
1 Ап-ак күлмәген кигәнн
Күлмәгенә тап тигән.
Җәй башында җиләгемне
Авыз итәрсез дигән.(Каен)
2.Кышын да ,җәен дә бер төсле(Чыршы)
3.Нинди агач җилсез шаулый? (Усак)
**Сандугач:** Белдегез балалар. Болай булгач, хатны сезгә тапшырам. Мин үз юлым белән китим. Яшәгән җирем минем табигать кочагында.Сау булыгыз, балалар.
**Балалар:** Сау бул, сандугач.
*Сандугач тәрбиячегә хатны биреп китә.*
**Тәрбияче:** ( Хатны укый) Исәнмесез, балалар! Мин Сарапул шәһәрендә яшәүче Камил исемле малай,сезгә Кадыбаш авылына кунакка килергә уйладым. Миңа авылны күрсәтсәгез бик шат булыр идем”.
**Тәрбияче:** Камилгә авылны күрсәтәбезме?
**Балалар:** Эйе, күрсәтәбез.
**Тәрбияче**:Әйдәгез,алыйса Камилне каршы алыйк.Ул безне таба алмыйча, адашып йөри күрмәсен.
***Балалар “күпер “аша үтәләр.***
**Тәрбияче:** Карагыз әле, балалар: каршыбызда нинди матур буа! Әйдәгез,без уйнап-җырлап алыйк.

***Уен"Күрсәтәле әле үскәнем".***
**Тәрбияче:** Менә безнең янга Камил дә килеп җитте.Исәнме, Камил.
**Малай:** Исәнмесез,балалар! Сезне күрүемә бик шатмын.Мин Кадыбаш авылына юл тота идем.Табигатегезнең матурлыгына хозурланып,чәчәкләр иснәп ,агачларга сокланып тик киләм менә. Бигрәк матур туган яклар!
**Тәрбияче:** Әйе, Камил безнең туган ягыбыз чыннан да бик матур.Ә хәзер, әйдә авылыбыз буйлап сәяхәт итик.
***( Камил,балалар тәрбияче артыннан кузгалалар"Кадыбаш" җырын җырлап баралар. Экранда мәчет,мәдәният йоры,шифаханә,китапханә,кибетләр,мәктәп,балалар бакчасы күренеше күрсәтелә).***
**Камил:** Туктагыз, туктагыз мин бик арыдым.Ял итеп алырга кирәк.
**Балалар:** Түз инде Камил балалалар бакчасына да аз гына калды,хәзер кайтып җитәбез.
**Малай:** Юк,минем ял итәсе килә.
**Ял минуты:**
Чәчәкләр
Гөлчәчәкләр күренде.
Һәм кояшка үрелде.
Аларга җылы кирәк,
Кояш астында рәхәт!
Җил исте
Чәчәкләр селкенде
Уңга бөгелделәр
Җиргә иелделәр.
Сулга бөгелделәр,
Җиргә иелделәр
Бар син ,җил,моннан кит,
Чәчәкләргә тими үт.
Алар зур булып үссен.
Безгә шатлык китерсен.
**Камил:** Балалар, Сезнең авылыгызда нинди милләт кешеләре яши?
**Балалар:** Татарлар.
**Тәрбияче:** Без татарлар, нинди телдә сөйләшәбез? Татар теле турында нәрсә әйтә аласыз?
**Балалар:** Бабаларыбыз сөйләшкән борынгы тел.
**Тәрбияче:** Татар телен тагын ничек эйтергә була?(Туган тел,ана теле).
Туган илем-туган анам.
Туган телем-анам теле. (Мәкальәрнең мәгънәсен аңлату.)
**Тәрбияче:** Туган телебез нинди ?
**Балалар:** Матур,бай,моңлы-җырлы.
**Тәрбияче:** Балалар, без тагын нинди телдә сөйләшәбез?
**Балалар:** Без эле рус телендэ дэ сөйләшәбез.
**Тәрбияче:** Безгә рус телен белү ни өчен кирәк?(балаларның җаваплары)
**Тәрбияче:** Әйе,балалар, үз туган телеңдә сөйләшүе – рәхәт, күңелле, җан җылысы бирә.Үзенең әти-әнисен, туган илен яраткан кеше туган телен дә ярата, хөрмәт итә. Без дә үзебезнең туган телебезне, татар телен сакларга, аның белән горурланырга тиеш. Безнең милли йолаларыбыыз, бәйрәмнәребез бик күп.
***Ә хәзер уен уйныйбыз. Викторина.***
**К**-авыл уртасында нинди елгага ага(Кады)

**А**-алма дисәңдә алалар,нәрсә соң ул балалар (Алма)
**Д**-өчтәнсоң нинди сан килә? (Дүрт)
**Ы**-чыршы агачының күлмәге (Ылыс)
**Б**-Утта янмый ,суда батмый (Боз)
**А**-Үзе урак ,үзе тешсез (Ай)
**Ш**-Ите симез, мае юк.
Тиресе  калын, йоны юк( Шалкын)
**Тәрбияче:** Нинди сүз  килеп чыкты?
**Балалар: КАДЫБАШ**
**Тәрбияче:** Нинди татар язучыларын ,шагыйрьләрен беләсез?
**Балалар:** А.Алиш, Г.Тукай, М.Җәлил
**Тәрбиче:** Г.Тукай – безнең бөек шагыйребез безнең өчен матур шигырьләр, әкиятләр язган.Сез нинди әкиятләрен беләсез?
**Балалар:** "Бала белән күбәләк", "Су анасы", "Шүрәле", "Кәҗә белән сарык".
**Тәрбияче:** Ә хәзер "Су анасы" уенын уйныйбыз.
*(Балалар түгәрәккә басалар.Бер балала Су анасы итеп билгеләнә.Күзләре бәйләнгән килеш түгәрәк уртасында утыра.Уйнаучылар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр.*
*Су анасы,су анасы   Каршыңда кем басып тора*
*Ялгышмыйча –әйт әле   Су анасын күр әле.*
*Балалар туктап кала.Күзе бәйләгән су анасы урыныннан тора, тәрбияче күрсәткән бала.Су анасы янына килә. Су анасы баланың тавышыннан кем икәнлеген әйтә.Әгәр дөрес әйтсә, әлеге уенчы  Су анасы була.Уен кабатлана).*
**Йомгаклау:** Рәсем ясау"Авылымның матур табигате"
**Тәрбиче:** Балалар, сезгә бүген иң күбе нәрсә ошады? Нәрсә авырлык тудырды? Камилгә күңелле сәяхат оештырдыгыз.Сезгә бик зур рәхмәт.

**Мәктәпкә әзерлек төркемендә белем бирү эшчәнлеге конспекты**
**"Һөнәрле халкым"**

*Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*муниципаль бюджет  гомумбелем бирү учреждениесе*
*Кадыбаш урта гомумбелем  бирү мәктәбе тәрбиячесе.*

**Максат:** Балаларны халкыбызның элек-электән килгән һөнәрчелек төрләре белән таныштыру, һөнәр осталарының матур эшләренә соклану, аларның хезмәтенә хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү.
**Җиһазлар**:экран, чиккән сөлге, калфак, түбәтәй

**Шөгель барышы:**

**1.Кереш өлеш**

**Оештыру моменты**: Балалар, әйдәгез, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясап басыгыз әле. Хәзер сул ягыгызда торган күршегезгә карап елмаегыз, аннары уң як күршегезгә карап елмаегыз.Сез бер-берегезгә күтәренке кәеф бүләк итегез. Өстәлләр артына утырышып үз урыннарыгызны алыгыз.

**2.Төп өлеш**

**Тәрбияче**: Безнең татар халкы гомер-гомергә эшчән халык булган. Ир егетләр дә, хатын-кызлар да күптөрле һәнәрләр белгәннәр. Үз һөнәрләренә кечкенәдән үк балаларын да өйрәткәннәр, һөнәргә  ир балаларны – ата кеше, кыз балаларны ана кеше өйрәткән. "Егет

кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз”- дигәннәр борынгылар.Моның белән алар һәр һөнәрнең кирәклеген, тормышта һәрвакыт ярап куярга мөмкинлеген аңлатканнар.Эйдәгез искә төшерик эле: татар халкының нинди һөнәрләре бар?

**Балалар:** Әбиләребез чигү чиккәннәр, сөлгеләргә, пәрдәләргә, киемнәргә төсле җепләр белән матур бизәкләр төшергәннәр .

**Табышмаклар чишү:**

1.Тик бер генә һөнәр беләм:
Кыям, турыйм, юынам,теләм. (балта)
2.Тешләремне исәбе юк,
Утын кисәм “Он “ясыйм.
Егет булсаң кадерне бел,
Мине читкә куйма син. (пычкы)
3.Бар очым,бар түбәм.
Сугалар –мин түзәм.
Кайчакта кәпрәям,
Тутыгам,кәкрәям. ( Кадак)

**Тәрбияче:** Әйе бу эш кораллары белән эшләүчеләрне балта осталары дип атыйлар. Алар йортлар, мунчалар салалар.Балта осталарын халык элек-электән хөрмәт иткән.

***Бик матур бизәлешле агач өй рәсеме карау. Балалар белән тәрәзә йөзлекләре, капка-койма бизәлеше турында сөйләшу. Өй эчен күзәтү.***

**Тәрбияче**: Өй эче нинди матур! Нәрсәләр бар монда?

**Балалар:** Өстәл, карават, сандык.

**Тәрбияче**: Карагыз әле челтәр-бизәкле ак пәрдә, чигүле сөлге. Түрдә сандык тора. Безнең әби-бабаларыбыз өйне матур итеп бизәгәннәр.Ә бизәкне ничек итеп төшергәннәр соң?

**Балалар:** Бизәкне чигеп,буяп төшергәннәр .

***Тәрбияче сандыктан чигелгән сөлге ала.***

Матур сөлгеләр элдек без
Бәйрәмнәрдә түр якка.
Күзнең явын алырлыгын
Әни чиккән яшь чакта.

**Тәрбияче**: Карагыз әле бу әйберләр аллы- гөлле җепләр белән нинди матур итеп бизәкләр чигелгән.

***Сандыктан калфак белән түбәтәй алып күрсәтелә***

Балкып тора түбәтәйләр
Энҗе бөртекләр белән.
Алар монда килгән гүя
Чын әкият иленнән

***Аз хәрәкәтле: “Түбәтәй” уен уйнала.***

**Тәрбияче:** Татар халкының борынгы һөнәрләре бүгенге көнгә кадәр сакланган. Хәзер дә искиткеч матур бизәкле түбәтәйләр, калфаклар чигәләр.Үзебезнең авылыбызда да Дулкарнаев Рамил абыегыз балта остасы, Дәүләтшина Ләрисә апагыз түбәтәй һәм калфакларга төрле төстәге җепләр белән,сәйләннәр белән бизәкләр төшерә.

**Интерграцьләштерү.**

**Тәрбияче**: Хәзер без сезнең белән декаратив рәсем ясыйбыз: түбәтәй, калфак бизибез.

**3.Йомгаклау.**

**Рефлексия**: Бүген сез нинди яңалыклар белдегез?

.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен шөгель конспекты**
**“Чишмә эзтабарлары”**

*Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе*
*Кадыбаш урта гомумбелем бирү мәктәбе тәрбиячесе.*

**Бурычлар**:
**Белем бирү бурычлары**. Балаларның табигатькә, туган җиргә кагылышлы сүзләр хисабына татар телендә сөйләм телләрен камилләштерү, үз фикерләрен дөрес эзлеклелектә ана телендә әйтеп бирә алуларына ирешү.
**Үстерешле бурычлар.** Мөстәкыйль фикер йөртергә, тулы җөмлә белән җавап бирергә күнектерү, диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.
**Тәрбия бурычлары**. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен, бер - берең не тыңлау күнекмәләрен, үз туган җиреңне ярату, аны саклау кебек сыйфатлар, ана телендә сөйләшү теләген тәрбияләү.
**Көтелгән нәтиҗәләр**. Балалар шөгыль барышында биремнәрне үтәү хисабына татар телендә сүз байлыгын арттыра, туган җир, аны саклау кебек галәм кагыйдәләрен камилләштерә.
**Җиһазлау:** Татарстан картасы, интерактив такта, тәҗрибә үткәрер өчен материаллар (ташлар, ком,туфрак, яңгыр яудырыр өчен лейка,су), видеоязма, ромашка һәм кыңгырау чәчәкләре, ватман форматында күл рәсеме, аңа беркетелгән тәгәрмәч, сок шешәләре, целлофан пакет, иске аяк киеме рәсемнәре.

**Эшчәнлек барышы**

*Тәрбияче балалар белән әңгәмә кора. Интерактивтактада Татарстан республикасыкартасы*

**Тәрбияче**: Балалар,без нинди республикада яшибез?
- Башкаласы нинди шәһәр?
- Безнең республикада нинди шәһәрләр бар?
-Нинди елгалар? Ә без нинди авылда яшибез?
-Сез ничек уйлыйсыз, Кадыбаш авылы нинди авыл?
-Киләчәктә дә авылыбыз матур,чиста булсын өчен нәрсә эшләргә кирәк?
Балалар әңгәмәнең соңгы соравына җавап биргәндә, интерактив тактада ватсап видео аша звонок килә.
*Тәрбияче звонокны кабул итә: Балалар, кемдер шалтырата, тыңлап карыйк әле. Видеозвонок:*
-Сәлам, дуслар! Мин Камил! Хәерле көн! Хәлләрегез ничек? *(Камил белән балалар исәнләшеп, аның сорауларына тулы җавап биреп, аралашырга тиешләр)* Дусларым, зинһар ярдәм итегез!
**Балалар:** Нәрсә булды, Камил? Син урманда нишләп йөрисең?
**Камил:** Дуслар белән җыелышып, урман тирәсен җыештырырга килгән идек, вакыт бик тиз үткән, тамак кипте,сү эчәсе килә. Монда якын тирәдә чишмә булырга тиеш, ләкин таба алмыйбыз. Дуслар, карта аша табып, миңа ват сапка шалтыратып әйтегез, зинһар! Координатамны язып җибәрәм.
**Тәрбияче:** “Авыл читеннән Кады буасы ага”
**Тәрбияче:** Димәк, балалар безгә нинди карта кирәк була?
**Балалар:** Безгә Кадыбаш авылы картасы кирәк булачак.

**Тәрбияче** Картадан Кады буасын табыгыз.
*(Балалар бик теләп риза була.Камилнең урынын шуннан билгелиләр)*
**Тәрбияче**: Балалар, менә бит ерак түгел бер елга бар. Елганың исемен кем әйтеп бирер микән?
**Балалар**: Кады елгасы.
**Тәрбияче**: Балалар, елга суын бәлки Камилгә эчәргә тәкъдим итәрбез?
**Балалар**: Юк, тәкъдим итмибез. Елганың суын эчәргә ярамый.
**Тәрбияче:** Ә ни өчен елга суын эчәргә ярамый соң?
**Балалар:** Чөнки елга суы пычрак, анда балыклар, бөҗәкләр яши.
*Магнит тактасында бирем. Елга рәсеме, анда балыклар йөзә, ә елга төбендә тәгәрмәчләр, иске аяк киеме, сок шешәләре, целлофан пакетлар.*
**Тәрбияче**:-Камил туган җиребезне саклар өчен бик тырыша. Ә сез, балалар, табигатьне саклар өчен нәрсә эшләр идегез? Каршыда кечкенә елга ага, ләкин ул безнең ярдәмгә мохтаҗ ахрысы. Сез ничек ярдәм итәр идегез?
*Ничек ярдәм итәргә кирәклеген балалар үзләре әйтеп бирергә тиеш. (Аны чистартырга кирәк.) Балалар елганы чүп- чардан җыештыра.*
**Тәрбияче:** Балалар, кешеләр табигатьне, авылларны кадерләп сакласыннар өчен сез аларга нинди киңәш бирер идегез?
**Балалар җаваплары.**
**Тәрбияче:** Алга таба картаны карыйбыз. Чишмәгә чыгар өчен безгә болын аша үтәргә һәм таудан түбән төшәргә кирәк. Балалар, урман белән болын нәрсә белән аерыла?
**Балалар**: Болында агачлар үсми, ә бары тик чәчәкләр, үләннәр, җиләкләр үсә.
**Тәрбияче:** Мин дә сезне үзебезнең болыннан чәчәкләр җыярга чакырам.
**Ял минуты**
*(Малайлар ромашка чәчәге, ә кызлар кыңгырау чәчәге җыя. Балалар чәчәкләрне җыеп бетерүгә челтерәп аккан чишмә тавышы яңгырый)*
**Тәрбияче**:Балалар, сез ишетәсезме? Нинди тавыш соң бу?
**Балалар:** Чишмә тавышы.
**Тәрбияче:** Ә нәрсә соң ул чишмә?
Ул ничек барлыкка килә?
Ә безнең Авылда чишмәләр бармы?
-Күргәнегез булдымы?
Чишмә суын эчәргә ярыймы соң?
**Балалар йомгак ясый:** Чишмә суы чиста, аны эчәргә ярый.
**Йомгаклау**
**Тәрбияче:** Мин сезне тәҗрибә ясарга чакырам: Төрле размердагы ташлар, ком, су. Җирнең өске катламында туфрак, үләннәр. Аннары ком, ком астынд аташлар. Яңгыр ява, яңгыр суы җир аша таш арасындагы бушлыкларда җыела. Таш арасындагы сулар җирнең нечкә генә юллары аша түбәнлекләрдә, тау кыяларында өске катламга агып чыга. Бу җир асты сулары югарыдан түбәнгә таба гына агып чыга, чөнки су бары тик түбәнгә таба гына ага. Менә шулай чишмәләр барлыкка килә.
-Менә без дә сезнең белән чишмә таптык. Ә бу чишмә суын Камилгә эчәргә тәкдим итсәк ярыймы соң?
**Балалар** Чишмә суын эчәргә ярый? Чөнки ул һәрвакыт агып тора,җир асты юллары аша үткәндә чистарып чыга.
**Тәрбияче**: Балалар, ничек уйлыйсыз, чишмәләрне сакларга кирәкме? Ничек аларны сакларга мөмкин? Әйдәгез, Камилгә шалтыратып, чишмә урынын әйтик.

*Видеоязма: Ничек кызлар, малайлар, чишмәне таптыгызмы?*

**Тәрбияче**: Әйе, Камил, Кады буасын  чыккач, болын күрерсең. Болыннан соң текә генә бер урында бик тәмле, чиста сулы чишмә булыр.

**Камил:** Рәхмәт дуслар!

-Сез менә дигән эзтабарлар.

-Мин шундый акыллы, ярдәмчел, туган илен яратучы балалар булганыгыз өчен бик шат!

**Проект**

**“Туган авылым–Кадыбашым”**

*Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы,*

*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*

*муниципаль бюджет  гомумбелем бирү учреждениесе*

*Кадыбаш урта гомумбелем  бирү мәктәбе тәрбиячесе*

**Гамәлгә ашыру срогы – 2022-2023 уку еллары**

**Проектның эчтәлеге:**

1.Проект “Туганавылым  - Кадыбаш”

**2.Кушымта:**

- “Туган авылым–Кадыбаш”, “Туган авыл”  шөгыле конспектлары.
- “Авылым табигате”  эти-әниләр өчен күңел ачу кичәсе.
- “Туган якны өйрәнәбез” альбомы төзү.
- “Минем авылым тарихы” презентация  әзерләү.
- “Кадыбашым” балалар өчен  музыкаль слайд-шоу җыю .
- “Авылымның истәлекле урыннары” рәсемнәр бәйгесе үткәрү.
- Әлеге рәсемнәрдән күргәзмә оештыру.
- Балалар бакчасында “Әбиемнең сандыгы” исемле кечкенә милли музей булдыру.

**Проект “**Туган авылым–Кадыбаш**”**

**Проект төре**: мәгълүмати юнәлештә, иҗади-эзләнүле, 2022-2023нче  уку елларын сыйдырган вакыт аралыгында  үтүче проект.

**Балалар яше**:  (6-7яшьлек) балалар.

**Эчтәлекнең төре:** Бала, тирә-як мохит, туган якның тарихи һәм сәнгать истәлекләре.

**Проектның  этаплары.**

1.Алдан башкарылган эш:

Перспектив эш планы төзү, фотога төшү, проектны иллюстратив материаллар белән баету,ата-аналар өчен анкеталар үткәрү; методик китаплар һәм матур әдәбият әсәрләре сайлау, проект турында әңгәмә оештыру һәм анны педсоветараслау.

Районның картасы белән таныштыру, картадан үзебезнең авылны табу.

**2.Төп өлеш**

Авылның тарихы, истәлекле урыннары, халыкның һөнәрләре, гореф-гадәтләре турында шогыльләр үткәрү, экскурсияләр оештыру.

Авыл китапханәчесе тарафыннан “Кадыбаш авылының килеп чыгышы” турындагы рәсемнәр карау.

Туган якның байлыгын, табигать матурлыгын күзәтү.

Әти-әниләр ярдәме белән “көзге табын-бай табын” ярминкәсе, “Авылымның уңган куллары” исемле күргәзмәләр оештыру.

Балалар белән күмәк хезмәт –авыл картасын төзү.

Сюжетлы-рольле уеннар уйнау”Гаилә”, “Мәктәп”, “Балалар бакчасы”

**<u>Проектның актуальлеге.</u>**

Туган як, туган почмак һәр кеше тормышында аерым бер зур,якын,кадерле урын алып тора. Үз авылыңны,аның тарихын, атаклы ,дәрәҗәле шәхесләрен, халыкның гореф-гадәтләрен белү бик мөһим.

Кечкенәдән балалар аңлармык итеп туган ил, туган авыл турында сөйләп, тарихи вакыйгалар белән таныштырып ; аны яратырга , сокланырга, горурланырга өйрәтеп, авыл тормышы белән даими кызыксындырып торсак-балаларда әхлаки-патриотик тойгылар формалашыр; табигатькә, туган якка, татар халкының йолаларына, сәнгатенә карата мәхәббәт тәрбияләнер, бала туган илнең лаеклы гражданины булып үсәр, аларның кечкенә йөрәкләрендә туган илгә карата мәхәббәт очкыннары кабыныр.

**<u>Проектта катнашучылар</u>**: төркемдәге балалар, бакчадагы тәрбияче, ата-аналар.

**<u>Бурыч</u>**: үз авылыңның тарихын,истәлекле урыннарын белү.

**<u>Максат</u>**:

- Туган як,авыл турындагы белемнәрн екиңәйтү.
- Балаларны авыл тарихы,аның урнашу урыны белән таныштыру.
- Туган авылга хөрмәт тәрбияләү, матурлыкны күрә белергә,аның белән сокланырга күнектерү.
- Бәйләнешле сөйләм ,хәтер,уйлау сәләтен үстерү, сүз байлыгын арттыру.
- Халыкның гореф-гадәтләрен саклап калырга дигән төшенчә кертү.
- Бердәм, бертөркем белəндус,тату уйнауларына ирешү.

**<u>Проектның үтәлеше</u>**

**Программа бүлеге.**

**Танып белү үсеше:**

“Авылның истәлекле урыннары” на экскурсия

Китапаханә, почта, фельшер акушерлык пунктына , мәктәпкә максади сәяхәтләр оештыру.

“Һөнәрләр” темасына рәсемнәр карау

Авыл урамнары,урман-кырларына,табигатенә багышланган “Минем авылым тарихы” исемле презентация тәкъдим итү.

Борынгы газеталар карау.

Элеккеге фотолар аша хәзерге авылны чагыштыру.

**Сөйләм үстерү:**

“Туган авылым–Кадыбаш” - шөгыле.

“Авылым табигате” эти-әниләр, тәрбиячеләр өчен күңел ачу иртәсе.

“Авылым урамнары”.

“Туган ягым-яшел бишек”.

**Матур әдәбият әсәрләре белән танышу:**

Р.Миңнуллин “ Туган илнең улы мин”

Р.Вәлиева “Туганҗир”

С.Юлаев “Туган илем

Ф.Ахметшина “Кадыбашым”

Г.Тукай “Туган авыл”

**Уен эшчәнлеге:**

Сюжетлы-рольле уеннар:

- Даруханә
- Янгын сүндерүчеләр
- Ватанны саклаучылар
- Автобуста

- Балалар бакчасы
- Гаилә
- Шифахәнәдә

**Дидактик уеннар:**

- Букайсыагачтан
- Урман дусларыната
- Кем артык
- Хайваннарны тап

Авылның урамын әйт

**Нәфәсати тәрбия**

Рәсем

- Минем авыл
- Мин яшәгәнйорт
- Милли киемнәр
- Безнең авыл машиналары

**Кисеп ябештерү:**

- Безнең урам өйләре
- Милли киемнәр
- Урман аланындагөмбәләр үсә.

Әвәләү

Кошлар,хайваннар, үсемлекләр

**Конструкцияләү:**

**Кул эше**

**Хезмәт**

Тәрәзәле өйләр.

Табигый материаллардан эшләнмәләр.

Балалар рәсемнәреннән күргәзмәләр.

Милли курчаклар өчен киемнәр тегү,бәйләү.

**Социальләштерү үсеше:**

Авылның мәртәбәле, мактаулы шәхесләре, ветераннары белән очрашу.

Авыл буенча сәяхәт. Китапханәгә бару.

Мәдәният йортындагы ярминкәләрдә, күргәзмәләрдә катнашу.

Төркемдә “Туган як” почмагы, “Әбием сандыгы” милли музей булдыру

**Проект эшчәнлегенә йомгак:**

Тарихи төбәкне өйрәнү һәм аның тарихын язу-энә белән кое казуга тиң. Минем уйлавымча, туган авыл табигатенең һәр географик объекты кешеләрнең яшьлек эзләрен кадерле хатирәләрен саклау белән бергә, һәрбер җирле атама- үзенең килеп чыгышы, барлыкка килү мәгънәсе белән чал тарих хәбәрчесе ул.

Киләчәктә без бу проект эшен дәвам итәргә уйлыйбыз, тагын да тулыландыра алырмын диеп ышанып калабыз.

## Кечкенәләр төркемендә патриотик тәрбия буенча проект "Батыр солдатларга рәхмәт"

*Закирова Гөлшат Фирдәвис кызы,*

*Татарстан Республикасы*

*Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәре*

**Проектны булдыруның актуальлеге**

Илебездә һәм дөньяда иң мөһим вакыйга Бөек Җиңү көне булачак! Бу истәлекле датада катнашучыларны, безгә тынычлыкта һәм татулыкта яшәргә мөмкинлек биргән кешеләрне тагын бер тапкыр искәтөшерү һәм хөрмәт итү өчен менә дигән мөмкинлек. Үзебезне ирекле һәм бәхетле кешеләр, чиксез Ватаныбыз гражданнары итеп хис итү.

9 Май! Халкыбыз өчен зур бәйрәм. Шатлык көне һәм шул ук вакытта кайгы көне. Бу бәйрәмдә без ветераннарны котлыйбыз һәм һәлак булганнарны искә алабыз. Дистә еллар дәвамында бу традиция буыннан-буынга күчә. Хәзер ветераннарны оныклары котлый. Чөнки нәкъ менә балачактан ук үз Ватанына карата мәхәббәт һәм хөрмәт патриотик хисе урнаша.

Ватаныбыз белән шәхси бәйләнеш сизмичә, ата-бабаларыбызның, әтиләребезнең һәм бабаларыбызның аны ничек яратканнарын белмичә, патриот булырга ярамый. Һичшиксез, балачакта ук системалы, максатчан тәрбия эше нәтиҗәсендә балада гражданлык һәм патриотизм элементлары формалаша ала.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны патриотик тәрбияләү-хәзерге Россия шартларында актуаль проблема. Туган илгә мәхәббәт хисе-ул иң көчле хисләрнең берсе, ул булмаса, кеше ыянлы, үз тамырларынсизми. Ә ул туган җиренә карата ярату хис итәрме яки аннан ераклашырмы, бу инде тормыш һәм тәрбия шартларынабәйле. Шуңа күрә баланың мәктәпкәчә яшьтә үк туган җире һәм аның киләчәге өчен шәхси җаваплылык тоюы мөһим.

**Проектның максаты:** балаларны халкыбызның сугышчан традицияләре беләнтаныштыру

**Проектның бурычлары:**

- сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан һәм сугышны кичергән әби-бабалар турындасөйләвен сорап, әти-әниләренә һәм туганнарына мөрәҗәгать итәргә;
- балаларга Бөек Ватан сугышы турында беренчел мәгълүмат җиткерергә. Ватанны саклаучылар, армия функцияләре турында белеем бирү;
- балаларның хәрби техника һәм аның максаты турында күзаллауларын формалаштыру;
- сүзлек запасын баету: Ватан, герой, Җиңү, солдат, диңгезче, очучы, танкист, армия, яклаучы, бәйрәм;
- балаларда Ватанны саклаучыларга карата ярату һәм хөрмәт тәрбияләү, балаларга ачык һәм аларда эмоциональ кичерешләр тудыручы тәэсирләр нигезләү;
- һәр кешенең тормышында Җиңү көненең әһәмиятен балаларга җиткерү.

**Проект буенча көтелгән нәтиҗәләр:**

- ✓ балаларның «Җиңү көне " темасы белән кызыксынуы, аларның танып белү активлыгы;
- ✓ Бөек Ватан сугышы тарихы белән танышу балаларда ветераннарга карата хөрмәт, Ватаныбыз өчен горурлык хисе формалаштыруга ярдәм итү;
- ✓ Җиңү көнендә бәйрәм атмосферасын булдыру;
- ✓ балалар үз инициативаларын үзләре күрсәтәләр: иллюстрацияләрне карыйлар, әңгәмәләрдә катнашалар, сораулар бирәләр; иҗатларын эшләрендә күрсәтәләр;
- ✓ ата-аналарның уртак эшчәнлегендә катнашу.
- ✓ тема буенча сүзлек запасы киңәйтеләчәк һәм активлашачак.

**Проект төре:** танып белү - уен

Проектның түбәндәге юнәлешләре бар: әхлакый-патриотик, тарихи, сәнгать-әдәби, физик.

Проект Ватанга мәхәббәтне популярлаштыруга, гражданлык дәрәҗәсен күтәрүгә һәм тәрбияләүгә юнәлдерелгән.
**Проект этаплары:** әзерлек, төп һәм йомгаклау.
**Проектта катнашучылар:** төркем тәрбиячеләре, ата-аналар, балалар.
**Проектны тормышка ашыру вакыты:** 2023 елныңмарт-май айлары (кыска вакытлы)
**Балаларның яше:** 3-4 яшь

**Проектның йомгаклау чараларын үткәрү формалары:**

| Эш | Йомгаклаучаралары |
|---|---|
| **Белем** | "Җиңү көне-бабайлар бәйрәме" |
| **Сәнгать иҗаты (рәсем, әвәләү, кисеп-ябыштыру)** | "Күктәге торналар» |
| **Легендар "Торналар "җырына коллектив эш.** | Ата-аналар һәм балаларның бәйрәм йөрешендә катнашуы. |

**Проектның перспектив планы**

| Башкарувакыты | Педагог һәмбалаларэшчәнлегетөре | Ата-аналарбеләнэшләү |
|---|---|---|
| **Март**<br>1-2 атна | **I этап әзерлек:**<br>* проект темасын билгеләү;<br>*максатны формалаштыру һәм биремнәргә бүлү;<br>*проектның төп этабы-планынтөзү;<br>*конспектлар язу, әдәбият җыентыгы, методик кулланмалар. | * ата-аналарны проекта катнашуга җәлеп итү |
| 3 атна<br><br>4 атна | **II этап төп:**<br>* «Ватанны саклаучылар көне белән танышу» темасына әңгәмә оештыру;<br>*«Салют» темасына кисеп – ябыштыру шөгыле<br>* Патриотик тәрбия буенча оештырылган шөгыль «Без солдатлар кебек барабыз»;<br>* яраткан әтиләр, бабайлар, олы абыйлар өчен бүләкләр ясау;<br>* А. Бартоның «Флаг»; шигырен уку<br>* «Флажок» хәрәкәтчән уены;<br>* «Флажок» сулышгимнастикасы; | * «Ватанны саклаучылар көне бәйрәмен бала белән ничек үткәрергә» дигән темага ата-аналар өчен консультация.<br>*"Ватанны Саклаучылар" дигән темага күчмә папка.<br>*хәрби тематикадагы уен ситуацияләренә атрибутлар ясау. |

| | | |
|---|---|---|
| **Апрель**<br>1 атна<br><br><br><br><br><br>2 атна<br><br><br><br><br>3 атна<br>4 атна | * "Хәрби техника" иллюстрацияләрен карау;<br>* «Самолетлар» темасына кисеп-ябыштыру шөгыле;<br>* «Самолетлар оча» уен ситуациясе:;<br>*Хәрәкәтле уен «Самолет»;<br>*А. Бартоның «Самолет» шигырен ятлау;<br>*«Хәрби һөнәрләр»темасына предметлы рәсемнәр карау,;<br>* А. Бартоның «Капитан»шигыренуку ,<br>* «Кечкенә капитан» уен ситуациясе;<br>* «Диңгезчеләр» дигән уен ситуациясе;<br>* «Танкист» уен ситуациясе;<br>* «Солдатлар белән» Дидактик уен ;<br>*«Солдатлар парады"дигән темага физик тәрбия юнәлешеннән шөгыль<br>* «Кояш елмайсын өчен» шигырен уку;<br>* «Салют» физкультминуткасы;<br>* «Җиңү көне» темасына шигырьләр уку;<br>* Г. Фридның «Сугыш турында җыр» җырын тыңлау | Ата-аналар белән берлектә «Ветеран янәшәдә яши» акциясен үткәрү. Бөек Ватан сугышы елларында сугышкан туганнары, күршеләре, танышлары язмышы турында мәгълүмат сайлау.<br>Әти-әниләр ярдәмендә хикәяләр язу, рәсемнәр, фотолар ясау.<br>«Балаларны Җиңү көне бәйрәме белән таныштырганда нинди эш формаларын кулланырга мөмкин» дигән әңгәмә |
| **Май**<br>2 атна<br><br><br><br><br><br>3 атна | **III этап- йомгак**<br>* "Җиңү көне-бабайлар бәйрәме"темасына сөйләм телен үстерү буенча шөгыь<br>* А. Филиппенконың "Без флаглар белән барабыз" һәм «Безнең Ватан көчле» җырларны тыңлау:<br>*Җиңү турында<br>"Кояш елмайсын өчен" һ. б. шигырьләр уку;<br>* "Күктәге торналар" темасына рәсем шөгыле;.<br>* «Парад турындатәэсирләр» әңгәмәсе;<br>* «Бәйрәм парады» картинасынкарау;<br>* «Бездә нинди салют бар!» темасына рәсем шөгыле | ата-аналар һәм балаларның бәйрәм йөрешендә катнашуы. |

**Нәтиҗә**

Җиңү көненә багышланган чаралар барышында балалар илебез тарихында ориентлашырга өйрәнделәр;

- Балаларда ветераннар, Ватан, герой, Җиңү, солдат, диңгезче, очучы, танкист, армия, яклаучы, бәйрәм кебек төшенчәләр формалашты;
- үз халкы һәм аның хәрби казанышлары өчен горурлык хисе формалашты;
- Ватанны саклаучыларга, Бөек Ватан сугышы ветераннарына хөрмәт.

## Өлкәннәр һәм мәктәпкә хәзерлек төркемендә балалары өчен күңел ачу кичәсе "Яз уята күңел кылларын"

*Гобәйдуллина Филисә Рамзи кызы*
*Татарстан Республикасы*
*Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәре*
*муницициаль бюджет 1 нче мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениясе*
*“Алтын ачкыч” балалар бакчасы тәрбиячесе.*

**Максат:** туган як табигатен кайгыртучы шәхес тәрбияләү.

**Бурычлар:**

балаларны туган як табигате белән таныштыру;

үсемлек һәм хайваннар дөньясы турында күзаллаулар булдыру, табигатьтәге сезонлы күренешләр, гомумән, балаларга терек яки терек булмаган табигать турында мәгълүмат бирү;
табигатькә карата сак караш тәрбияләү;
тирә-як табигатькә сокланып карарга өйрәтү;
эмоциональ хәләтне күтәрү.

**Методик алымнар:**

1. Күзәтү. Тәрбияче ярдәмендә үсемлекләрне һәм хайваннарны табигать почмагында һәм табигый шартларда күзәтү. Бала үзләштереп кенә калмыйча, үзлекләрен, сыйфатларын, чагыштырып карый, фикерли, сөйләм үстерә.
2. Балалар белән урман, парк, су буена экскурсияләр, йөрү (прогулкалар) оештырыла.
3. Төрле уеннар. Таныштыру процесында өстәл, дидактик уеннар, шулай ук, вак ташлар, ком,балчык, су һ.б. кулланыла.
4. Табигатькә мәхәббәт, сак караш, кызыксыну тәрбияләү, участокта балалар хезмәтен оештыру.
5. Тәрбияче сөйләве, әңгәмә, әдәби әсәрләр уку, рәсемнәр карау, балаларның күзаллавын төрлечә киңәйтү.

| | |
|---|---|
| Алып бар. | Бүген бездә бәйрәм – күңелле Яз бәйрәме. Күрәсезме, әйләнә -тирәбездә төрле төстәге чәчәкләр. Кошлар сайрый.(музыка).<br>Әгерҗе матур саф һавасы<br>Чыклы таңнары белән,<br>Ак каенлы, миләшләре,<br>Гүзәл парклары белән.<br>Әгерҗе матур чишмәләре,<br>Көяз кызлары белән,<br>Кыш артыннан соңламыйча<br>Килгән язлары белән.<br>*Балалар керә. Җыр "Кояшлы ил безнең ил "* |
| Алып бар. | Кыш апрельне ачулана,<br>Тик файда юк һичбер төрле.<br>Тәрәзәне кагып өмет белән<br>Язлар килә, язлар килә!<br>*Яз керә бии бии, кулында кәрзин белән чәчәкләр.* |
| Яз: | Боз һәм кар эреде, сулар йөгерде,<br>Елап елгалар, яшьләр түгелде.<br>Көннәр озая, төннәр кыскара! |
| Балалар: | Яз. |
| Яз: | Исәрмесез, нәни дусларым! Сез мине таныдыгызмы! Әйе, мин- Яз матур. |
| Алып бар. | Исәнме, Яз-матур! Хуш килдең, түрдән уз! Без сине күптән сагынып көтәбез. |
| Яз: | Яз бәйрәме белән дуслар,<br>Тәбриклим сезне,<br>Күп шатлыклар алып килсен<br>Бу- Яз бәйрәме. |
| 1 бала: | Әй, Яз-матур, Яз-матур,<br>Хуш киләсең, уз бире. |

Кунак булып килер дип,
Күптән көттек без сине.

2 бала: Әй, Яз-матур, Яз-матур!
Хуш киләсең, уз бире.
Шатланышып җыр белән
Каршылыйбыз без сине.
*Яз белән җыр “Я балалар әйтегез”.(балалар утыралар)*

Яз: Якты йөз белән каршы алалар
Нинди Әйбәт монда балалар.

Алып бар. Уңган безнең балалар,
Шигырьләр күп беләләр,
Хәзер сезгә матур итеп.
Шуны сөйләп бирерләр

3 бала: Кояш сибә якты нурын
Болын кырларга.
Без җыйналдык, язны мактап
Биеп – җырларга.

4 бала: Син елмайгач, гөрләп ага
Елга, инешләр,
Син елмайгач, сайрый башлый
Нәни кошчыклар.

5 бала: Яз нурлары, көмеш нурлар
Сибелсен җиргә.
Яз шатлыгы, яз бәхете
Телибез сезгә!

Яз: *(чеби булып киенгән балаларны күреп)*
Бу бәйрәмгә кемнәр килә
Матур итеп киенеп?
*“Өй алдында чебиләр” җыры. Кечкенә төркем балалары башкаруында инсценировка.*

Яз: Бик матур биедегез,
Миңа бик ошадыгыз.

6 бала: Яз-матур! Яз-матур!
Безнең сөйгән кунак син,
Ямьле үтсен бәйрәмебез,
Безне көлдер, уйнат син.

7 бала: Бәйрәм бүген, бәйрәм диеп
Бар дөнья көлеп торсын.
Яз бәйрәме икәнен
Бар кеше белеп торсын.

Яз Әйдәгез, мин сезне урманга алып барам. Чәчәкләргә сокланырбыз, кошлар сайравын тыңларбыз, яшел чирәмдә уйнарбыз, шаярырбыз.
*Музыкага баралар.*

Аю *Йокысыннан уянып.*
Бу нинди тавыш? Кем мине татлы йокымнан уятты? Кем минем урманымны таптый, тынычлыгымны боза? *(балаларны куа, берсен тота).*

| | |
|---|---|
| | Әһә, менә кемнәр икән. |
| Яз | Аю абзый, җибәр син бу баланы. Мин Яз-матур, бакча балаларын кунакка алып килдем, куркытма син аларны. |
| Аю | Шулаймыни? Ярый алайса, тик минем күңелемне күрегез – җырлагыз, йә шигырь сөйләгез, йә биегез, аннары җибәрәм. |
| Алып бар. | Ярар, ярар Аю абзый! Без сиңа биеп тә җырлап та күрсәтәбез әле. Тик син бүген нинди бәйрәм икәнен беләсеңме соң? |
| Аю | Ә нинди бәйрәм? |
| Алып бар. | Бүгенге көнне безнең әби –бабаларыбыз "аю йокыдан уяна торган көн" дип билгеләп үтә торган булганнар. Менә без дәсине тизерәк йокыдан уятыйк дип урманга килдек. Әйдә, син дә безнең  белән бәйрәм ит, күңел ач. |
| | *Бию.* |
| Аю: | Матур бию миңа ошады. Уйнапта алыйк инде. |
| Яз: | Аю абзый белән уйныйбызмы, балалар. |
| | *Бал кортлары белән уен.* |
| Алып бар. | Аю абзый без инде синең белән уйнадык та. Биедек тә, хәзер инде юлга кузгалыйк. Ләкин, киткәнче, сиңа бәйрәм хөрмәтенә үзебезнең күчтәнәчебезне дә калдырыйк *( бал-  мичкә белән  ).* |
| Аю. | Рәхмәт сезгә! |
| Балалар. | Сау бул , Аю бабай! |
| Аю. | Тагын килегез. Балалар. |
| | *Балалар юлларын дәвам итәләр.* |
| Яз. | Менә матур урман аланы, шунда туктап ял итик бераз! Урман һавасын исник. Нинди чиста, саф һава. Чәчәкләрдән хуш ис бөркелә. Кошлар сайрый. Әйдәгез тыңлыйк әле. |
| | *Кошлар тавышы(магнитафон)* |
| 8 бала | Яз килә, Яз килә!<br>Кояш елмаеп тора.<br>Урман яңгыратып<br>Кәккүк кычкыра. |
| Алып бар. | Язлар җиткәч, ерак юллар үтеп, озак очып, диңгез кичеп, кошлар җылы яктан безгә кайталар. |
| 9 бала | Кыр казлары, үрдәкләр,<br>Кара каргалар, карлыгачлар,<br>Сыерчыклар, тургайлар,<br>Бакча яме – сандугачлар,<br>Урман күрке күкеләр-<br>Җылы якта булганнар. |
| Алып бар. | Әйе, менә шушы кошлар туган илләренә кайтып үзләренә оя ясыйлар. Ә сез кошларның ояны ничек һәм нәрсәдән ясаганнарын беләсезме? |
| Балалар | Чыбыклардан, саламнан, йоннан һ.б. |
| Алып бар. | Дөрес әйтәсез балалар! Ә менә сыерчыкка ояны кешеләр ясый икән. Ул яз көне кайтып, үзенә ошаган ояны сайлап ала икән. Быел да күпләрегезнең әтиләре оя ясап элгәндер. Безнең .................... әтисе дә сыерчыклар килүенә оя ясап алып килгән, без аны соңрак бакча ишегалдындагы агачка элеп куярбыз. Ә хәзергә бергәләп уйнап алыйк. |

| | |
|---|---|
| | *“Кайсы сыерчык өлгер” уены* |
| Яз | Матур уйнадыгыз. Әйе, салкын кыштан соң җылы көннәр килүе табигатҗтәге барлык җан иясе өчен дә шатлык. Бөтен тереклек йокыдан уяна: җәнлекләр, бөҗәкләр, хәтта агачлар да. |
| 10 бала. | Агачлар яфрак яра,<br>Алмагач чәчәк ата<br>Тургайлар тугайларын<br>Сагынып кире кайта. |
| 11 бала. | Яз килә, яз килә!<br>Елмая күктә кояш.<br>Илебез буйлап атлый<br>Чәчәкле ай, матур яз! |
| Яз | Карагыз әле, алан чәчәкләр белән тулган. Нинди матур алар. Бу – умырзая чәчәкләре. Алар иң беренче булып чәчәк аталар. Күзләрегезне йомыгыз әле, хәзер мин аларны уятам. |
| | *“Чәчәкләр биюе”* |
| | *Ул арада бер почмакка куян кереп ята.* |
| Яз | Нинди күңелле урманда, әйе бит балалар? Чү, нәрсә бу? Нәрсә йоклап ята монда? Берни ишетми, берни күрми. Куян ич бу. Ни булды икән аңа? Тор әле, куян, тор, нишләп ятасың? Әллә син Яз- матурның килгәнен ишетмәдеңме? Тор әле, тор, дим (уянмый). Балалар, әйдәгез аны бергәләп уятып карыйк. |
| | *“Без урманга бардык” уены* |
| Куян | Мин сездән куркам. Сез кемнәр? |
| Яз. | Курыкма. Без сиңа тимибез. Без язгы урманны карага килдек, кошлар сайравын тыңлыйбыз, хуш исен иснибез. Әллә син кышкы йокыдан уянасыңмы? |
| Куян. | Юк, мин бит Аю бабай кебек кыш көне йокламыйм. Дусларым белән кушылып уйнадык та, арып йокыга киткәнмен. Мин бит уйнарга, биергә яратам. Әйдәгез, бергәләп биеп алыйк. |
| | *Уртанчылар төркеме биюе.* |
| | *Ерактан тавыш ишетелә “Ау-у-у!”* |
| Куян. | Мин монда! Мине дусларым чакыра, без киттек. Балалар ,тагын килегез, бергәләп уйнарбыз, җиләк җыярбыз. Сау булыгыз! |
| | *(Сикерә-сикерә китә)* |
| Алып бар. | Әйтегезче, кайсы вакыт<br>Яздагыдан ямьлерәк? |
| Балалар. | Кыш көннәре дә бик матур,<br>Ләкин яз-күңеллерәк. |
| Алып бар. | Кояш нурын сипкән чакта<br>Тып-тып итеп тамчы тама<br>Көзен чәчкән алтын бөртекләргә<br>Терәк булып җиргә иҗче. |
| | *“Тамчы там”җырын музыкаль инструмента уйнау* |
| Алып бар. | Яз-матур!Бик озак йөрдек инде.бакчага да якынлашып киләбез. Сиңа безнең балаларның һөнәрләре ошадымы соң? |
| Яз. | Әйе, ялбәттә ошады. Хәтта үземнең дә биисе килә башлады. |

*Яз биюе.*

Яз. Ә хәзер саубыллашыйк.
Хушыгыз, хуш, дусларым.
Күңелле ял итик без.
Минтагын да килермен әле.
Ә хәзергә минем бүләкләремне алыгыз
Яз килгәндә көтегез. Сау булыгыз.

Балалар. Сау бул Яз-матур.

Алып бар. Балалар! Инде Яз-матурны да каршы алдык. Аңа бездә бик тә ошагандыр дип ышанып калыйк. ә безгә килгән кунак апаларга үзебезнең зур рәхмәтләребезне ирештерик киләсе бәйрәмнәрдә дә аларны көтеп калыйк.

**Мәктәпкә әзерлек төркемендә проект эшчәнлеге**
**«Кече Ватаныбыз Әгерҗе шәһәренә сәяхәт».**

*Ягьфәрова Гөлназ Гамир кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе мөдире.*

**Аңлатма язуы.**

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Авыллар тарихы – халкыбыз тарихының аерылгысыз бер өлеше, мөһим өлеше ул. Аларны кече яшьтән үк өйрәнү, үзең яшәгән төбәк белән горурлану хисләре тәрбияләү – һәрберебезнең бурычы. Рухи кыйммәтләребез үз төсен югалта, онытыла барган бу чорда туган якны өйрәнү шул максатка ирешү юлы булып тора һәм мөстәкыйль, ирекле, намуслы, үз Ватанының лаеклы улы яки кызы булырлык шәхес тәрбияләргә ярдәм итә.

Кечкенәдән балалар аңларлык итеп туган ил, туган авыл турында сөйләп, тарихи вакыйгалар белән таныштырып, аны яратырга, сокланырга, горурланырга өйрәтеп, авыл тормышы белән даими кызыксындырып торсак, балаларда әхлакый-патриотик тойгылар формалашыр иде. Балалар киләчәктә милли җанлы, үз халкының улы яки кызы булып җитлегә алыр, анда милли аң формалашыр, кечкенә йөрәкләрендә туган илгә карата мәхәббәт очкыннары кабынуына без һичшиксез ышанабыз.

Яшь буынның бүген алган тәрбиясе авылыбызның алдагы көнен билгели. Яшь буынга әхлак, патриотик һәм рухи тәрбия бирүдә нинди үтемле чаралар кулланырга соң? Проект эш куллану – балалар бакчасында әлеге мәсьәләне хәл итүдә мөһим чараларның берсе.

Туган ил. Туган авыл. Туган җир. Бу изге сүзләр һәркемгә таныш һәм кадерле.

**<u>Проектның актуальлеге.</u>**

Туган авыл, туган нигез. Кеше өчен иң кадерле сүзләр. Туган җир, туган туфрак... Кеше дөньяга килү белән тәүге тапкыр аваз салган, тәпи баскан җир. Шуңа күрә дә һәркемгә үзенең туган ягы якын. Һәр төбәкнең, һәр авылның тарихи үткәне, истә кала торган урыннары бар. Ул ерак гасырларга барып тоташа.

Әлеге проект бүгенге көндә бик актуаль, чөнки үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала кече яшьтән үк үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша туган авылына якынаерга тиеш. Туып үскән авылны өйрәнү аның

традицияләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, әдәп-әхлагын, шөгыль-кәсепләрен белү һәм дәвам иттерү өчен кирәк. Шулай булганда гына балалар үз авылын яратучы, киләчәктә туган авылының лаеклы улы-кызы булып җитлегә ала. Яшьләр үз авылларыннан читкә китмичә, шунда төпләнеп, авылларыбызны яшәртеп, гөрләп яшәрләр дип өметләнәбез.

**Проектның төп максаты:**

Балаларда авыл тарихы, истәлекле урыннары турында күзаллау булдыру белән берргәттән рухи-әхлакый сафлыкка ия булган авыл җанлы шәхесләр тәрбияләү.

**Бурычлар:**

1. Балаларның танып белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү;
2. Туган илебезгә, халкыбызга, тарихыбызга, гореф – гадәтләребезгә хөрмәт тудыру;
3. Туган авылыбызга мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Максатка ирешү алымнары:**

- ✓ “Туган авылым – Тирсә” шөгыле конспекты.
- ✓ “Авылым табигате” әти-әниләр, тәрбиячеләр өчен күңел ачу иртәсе сценарие.
- ✓ “Туган якны өйрәнәбез” альбомы төзү.
- ✓ “Туган авыл” турында күчмә- папка әзерләү.
- ✓ Ата-аналар өчен белешмәлекләр ясау.
- ✓ Әңгәмә “Балаларда әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү”.
- ✓ Ата-аналар өчен “Баланы һөнәрләр белән таныштырабыз” журналы.
- ✓ “Минем авылым тарихы” презентация әзерләү.
- ✓ “Авылымның истәлекле урыннары” рәсемнәр бәйгесе үткәрү.
- ✓ Әлеге рәсемнәрдән күргәзмә оештыру. Стена газетасы чыгару.
- ✓ Тирсә мәдәният йортының китапханә бүлегендә эшләп килүче “Әбием сандыгы” исемле милли музейга һәм “Тарих битләреннән” музеена сәяхәт кылу.

**Проектта катнашучылар**: мәктәпкә әзерлек төркеме балалары, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе, ата-аналар, китапханәче, мәдәният йорты җитәчесе, Тирсә авыл җирлеге башлыгы, авылыбыз җитәчеләре, авылыбызның Ак әбисе, ветеран мөгаллимә Гимазова Вәсилә Гәрәй кызы.

**Проект төре:** мәгълүмати юнәлештә, иҗади-эзләнүле

**Дәвамлылыгы:** 9 ай (сентябрь – май)

**Проект күренеше:** уен формасында.

**Фараз:** Әгәр дә тәрбия эшендә балаларга, туган илгә, туган авылга карата мәхәббәт тәрбияләүдә төрле чаралар үткәрелә икән, димәк, бу аларның патриотик хисләрен формалаштыруда зур роль уйнаячак.

## ТӨП ӨЛЕШ.

**Проектны тормышка ашыру этаплары:**

**1. Мәгълүмати – мотивацияле**. (сентябрь - декабрь)

**Максат**: Туган авылыбыз тарихы белән танышу.

**Бурычлар**:

*җирлектәге өлкән буын кешеләреннән үткән тарихыбыз турында мәгълүмат җыю;

*балалар бакчасы, мәктәп, китапханә, мәдәният йорты белән тыгыз элемтәдә тотып, бергә хезмәттәшлек итү.

***Бурычларны тормышка ашыруда ярдәм эшчәнлек***

| Программа бүлеге | Эшләү алымы һәм формасы |
|---|---|
| **Танып белү үсеше** | Авылыбызның Ак әбисе, ветеран мөгаллимә Гимазова Вәсилә Гәрәй кызы белән очрашу. |

| | |
|---|---|
| | Борынгы газеталар карау.<br>Элеккеге фотолар аша хэзерге авылны чагыштыру.<br>“Туган якны өйрәнәбез” альбомы белән танышу. |
| **Сөйләм үстерү** | “Туган авылым –Тирсә”, “Туган авыл” шөгыле |
| **Матур әдәбият әсәрләре белән танышу** | Тирсә авылында туып үскән каләм остазлары - Ч. Мусин, Г. Галиев, Ә. Закиров әсәрләре белән танышу. |
| **Уен эшчәнлеге** | *Әби – бабаларыбыздан күчкән җырлы-биюле уеннар:*<br>Кәрия-Зәкәрия<br>Чума үрдәк, чума каз<br>*Хәрәкәтле уеннар* |
| **Нәфәсати тәрбия** | Рәсем<br>Минем авылым нинди булган<br>Борынгы йортлар<br>Кисеп ябештерү<br>Агач өйләр<br>Әвәләү<br>Кошлар, хайваннар, үсемлекләр дөньясы. |
| **Конструкцияләү**<br><br><br>**Кул эше**<br><br><br><br>**Хезмәт** | Авылдагы биналар макеты.<br>Тәрәзәле өйләр.<br><br>Табигый материаллардан эшләнмәләр.<br>Балалар рәсемнәреннән күргәзмәләр.<br>Милли курчаклар өчен киемнәр тегү,бәйләү.<br><br>Агачлар утырту, бакчаны чиста тоту, бакча тирәли өмәләр ясауда тәрбиячеләргә булышу. |
| **Музыка тәрбиясе** | “Әгерҗем минем” җырын тыңлау. |
| **Социальләштерү үсеше** | Авылның мәртәбәле, мактаулы шәхесләре, ветераннары белән очрашу.<br>Авыл буенча сәяхәт. Китапханәгә бару. |
| **Экологик тәрбия** | Авылдагы климат шартлары турында әңгәмә. |

**“Хәтерләүдән курыкма син! Үткәнеңне онытма син!”**

Проектыбызның беренче өлешендә без, Тирсә авылының килеп чыгышы, аның бүгенгесе һәм киләчәгенә кагылышлы сорауларга җавап эзләдек.

Авылым тарихы белән тирәнтен танышу максатыннан Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбендә 40 елга якын татар теле һәм әдәбияты укыткан, авылыбызның күркәм шәхесе, хөрмәтле остазыбыз, ветеран укытучы **Гимазова Вәсилә Гәрәй кызын** балалар бакчасына очырашуга чакырып әңгәмә үткәрдек.

**Гимазова Вәсилә Гәрәй кызы** сөйләгәннәрдән**.**

**....** Әйе, туган авыл, туган як – һәркемгә якын, кадерле. Моны туган җиреннән читтә яшәүчеләр аеруча нык беләләр. Тирсә – элек – электән зур, бай тарихлы авылларның берсе. Ул мул сулы Чаж елгасы буенда урнашкан. Ундырышлы туфраклы киң кырлар, хуш - исле болыннар, җиләк – җимешкә бай катнаш урманнар белән чолганып алынган ул. Тукай әйткәнчә : “ урманында кып – кызыл кура җиләк тә, җир җиләк. Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк”. Авылдашыбыз Сәйфи ага Әмиров авылыбызның тарихын өйрәнеп, алдагы буыннарга әһәмиятле истәлек язып калдырды. Мин шул материаллар нигезендә һәм Хабирова Фәрхия апаның истәлекләренә таянып, авылының тарихы турында сөйләмәкче булам.

Татарстан АССР тарихында Оренбург өлкәсендә яшәгән борынгы болгар дәүләте таркалган чорда, Чынгыз хан илбасарларыннан качып, хәзерге Әгерҗе районы Чаж һәм Иж елгасы буйларында килүчеләр күп булуы турында әйтелә.

Оренбург өлкәсеннән килгән крестьян бабаларыбызның Чаж һәм Иж елгалары буенда урнашкан Тирсә, Мордва, Тоба, Наҗар, Чишмә һәм башка авылларга нигез салуга инде 700 – 800 еллар чамасы.

XIV – XV гасырларда борынгы бабаларыбыз Оренбург өлкәсеннән Чаж елгасы буенда килеп нигез салгач, авылга Тирсә исеме бирәләр. Алар Оренбург өлкәсендәге Тирсә елгасы буендагы Тирсә авылында яшәгән булганнар.

Тирсәавылы Чаж (Шэде) елгасы буена урнашкан. Бу елга Тирсәдән 40 чакрым ераклыктагы Чажы баш исемле удмурт авылы янындагы чишмәләрдән башлана. Удмуртчадан тәрҗемә иткәндә Чаж «тиз агучы» дигәнне аңлата. (Әгерҗе төбәге: тарихи сәхифәләр. Казан-2008.)

Борынгы төрки телдә һәм хәзерге татар теленең  кайбер сөйләшләрендә дә «тирес», «тирс» сузләре кире як, төньяк мәгънәләрен белдергән һәм белдерә.  Тирсә исеме дә элекке дәвердә төньяк мәгънәсендә кушылган булуы ихтимал. Чөнки Тисрә төбәге – болгар-татарлар яшәгән иң төньяктагы урыннарнын берсе. (Әгерҗе төбәге тарихы. Раиф Мәрданов, Ирек һадиев. Казан 2003.)

XVIII гасырында Россиядә эчке һәм тышкы базарлар киңәя, завод – фабрикалар барлыкка килә. 1803 елда Тирсә баяры да шырпы заводы салдырган. Заводта крестьяннар эшләгәннәр. Шул заводта агач хәзерләүче булып Кайтас Әхмәтша эшләгән. Улы Әхмәтҗанның кульязмасында мондый мәгълүматлар язылган: эш көне 12 сәгать була, эш хакы 6 тиеннән түлиләр, ләкин бу акча кулларына бирелми, төрле салымнар өчен тотып калганнар.

Шул ук чорда Мордыбыйның Тирсә ягы башында Чаж елгасы буенда пыяла заводы булган.

Бу чорда күпчелек авылларда мәдрәсәләр булмаган. Ә Тирсәдә мәдрәсә дә күптәннән яшәп килгән. Хәллерәк ата – аналар балаларын укытканнар. Шулай да күпчелек укыта алмаган. Ә Мордыбый авылында 2 классды рус мәктәбе эшләгән.

Ә 1919 елның 1 сентябрендә Тирсәдә 4 класслы башлангыч мәктәп ачыла. Бу Алабуга өязендә беренче совет мәктәбе Тирсә Тәфтилев боярның биек сараена өстенә урнаштырыла. Мәктәпне ачу тантанасында Иске Кызылъярдан Давыт Гобәйди дә катнаша. Аның чыгышында мондый сүзләр яңгырый:

- “Ирекле илнең яшәвенә әле ел да тулмады, шулай да ис- китәрлек уңышлар бар. Менә совет иленең беренче бүләге – балаларыбыз өчен өяздә беренче мәктәп – школа ачыла. Аның киләчәге зур”.

Гражданнар сугышы Тирсәдә зур фаҗигаләр китерә.

Бакиев Баһаветдин ага күп авырлыклар кичерә. Ул Тирсәдә туып үскән, беренче укытучы була. 1904 елдан Ленин партиясе члены. Халыкны белемле итү өлкәсендә тырышып эшли. Кадыбыш авылында да укыта. Тирсә кешеләре дә аннан русча укырга – язарга өйрәнәләр.

Менә мәрхүм укытучыбыз Фәрхия апа Хәбирова истәлекләрендә мондый юллар бар: "Әтием Камали да Баһаветдин абыйдан русча укырга өйрәнә. Аннан үзлегеннән укый һәм гомере буе секретарь вазифасы башкара. Шуңа күрә аны "Писарь Камали" дип йөртәләр". Баһаветдин ага ярлыларны байларга, изүчеләргә каршы көрәшкә өнди. Шуңа күрә аны авыл куштаннары, байлары күрә алмыйлар. Авылга аклар кергәч, тотып бирергә җыеналар. Ул качып яшәргә мәҗбүр була. Коега да, мәчет подвалына да, зыяраттагы тимер чардуганнар эченә дә яшеренеп яшәгән. Туганнары, якыннары төнлә яшеренеп ашарга илтәләр. Салкында яшеренеп йөрүләр аның сәламәтлегенә зыян китерә, соңыннан ул авырып 1926 елда үлә, кабере базар урамында.

Ногманов Миңлегали абыйны да авыл куштаннары бик нык кыйныйлар. "Үлде" дип, урамда калдыралар. Зарифуллин Фатыйх абыйлар алып кереп, яшерәләр һәм айлар буе дәвалыйлар. Шунан соң терелеп, Ижевскига күчеп китә.

Крестьян улы Галиев Ясәви абый – авылыбызның беренче коммунистларыннан берсе. Ул Вольный Труд исемендәге беренче күмәк хуҗалыкны оештыручы һәм больница салдыручы була. Ясави абый белән бергә яңа хуҗалыкка Гарифуллин Гыйният, Садыйков Садыйк, Аминов Хуҗа, Муллахметов Вәлиәхмәт һ.б. лар Вольный Трудка күчәләр.

Сугыштан соңгы илне тәргызу еллары да халык өчен җинел булмый. Аңлату, балаларны белемле итү эше укытучылар җилкәсенә төшә. Сугыштан соң да тормыш җиңел булмады. Ачлык – ялангачлык хөкем сөрде. Ул вакытта фронттан җину яулап кайткан бик көчле, тирән белемле укытучыларыбыз: Мифтах абый Курбанский, Мансур абый Насибуллин, Рәхимгәрәй абый Гараев, Мөнәвир абый Ибрагимов мәктәптә эшлиләр. Яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

**2. Гамәли этап** (январь -март)

**Максат**: Туган якның, туган авылның тарихында булган вакыйгаларны буыннан буынга саклап калдыру, балаларда иҗат итү, эзләнү омтылышы булдыру.

**Бурычлар:**

*максат һәм бурычларны тормышка ашыру өчен төп бүлекләрне үз эченә алган юнәлешләрдә эшләү;

*иҗат төркемнәре белән тикшеренү эшләре башкару;

*авыл халкы арасына чыгып, авыл тарихы турында, авылның күренекле кешеләренә багышланган материаллар, фоторәсемнәр туплау.

***<u>Бурычларны тормышка ашыруда бердәм эшчәнлек</u>***

| Программа бүлеге | Эшләү алымы һәм формасы |
|---|---|
| **Танып белү үсеше** | ✓ «Чаж" елгасы буйларына сәяхәт<br>✓ Китапханә, почта, хастаханәгә, мәктәпкә экскурсия оештыру.<br>Тирсә мәдәният йортының китапханә бүлегенә"Әбием сандыгы" исемле милли музейга сәяхәт кылу<br>✓ Мәчет –изге урын.<br>✓ "Тирсәм" балалар өчен слайд-шоу җыю. |

| | |
|---|---|
| **Сөйләм үстерү** | ✓ “Хәерле иртә, авылым!” әти-әниләр, тәрбиячеләр өчен күңел ачу иртәсе.<br>✓ “Салават күпере” әкиятен сәхнәләштерү.<br>Әңгәмәләр:<br>✓ Зыялы затлар.<br>✓ Күренекле якташларыбыз.<br>✓ Мәктәбем – горурлыгым.<br>✓ Без бәләкәй чакларда.<br>✓ Яшь чак истәлекләре.<br>✓ Авыл безнең киләчәк. |
| **Матур әдәбият әсәрләре белән танышу** | Туган авылыбызда туып үскән, үзләренең әсәрләрендә авылыбызга дан җырлаган Заһирә Байчурина, Хәмит Рәхим, Фазыл Шәех кебек күренекле шәхесләрнең әсәрләре белән танышу. |
| **Уен эшчәнлеге** | *Сюжетлы-рольле уеннар:*<br>Даруханә<br>Гаилә<br>Хастаханә<br>Почта<br>Банк<br>Мәктәп<br>*Җырлы-биюле уеннарны кабатлау :*<br>Кәрия-Зәкәрия<br>Чума үрдәк, чума каз<br>*Хәрәкәтле уеннар* |
| **Нәфәсати тәрбия** | *Авылыбыз рәссамы Асия Вәли кызының рәсемнәре белән танышу, күргәзмә карау.*<br>*Күргәзмәдән алган тойгыларны, кәгазьгә төшерү.*<br>Рәсем<br>✓ Минем авылым табигате!<br>Әвәләү<br>✓ Минем өйне күрегез! |
| **Конструкцияләү** | Авылдагы биналар макеты.<br>Татар халык уен коралы гармун макеты ясау. |
| **Музыка тәрбиясе** | *Тыңлау:*<br>“Дружат дети всей земли” (сл. В, Викторова, муз. Д.Львова-Компанейца)<br>«Улыбка» ( муз В.Шаинского, сл. Пляцкова)<br>***Авылыбыз күрке булган баянчылар гаиләсе Мулләхмәтовлар бездә кунакта.***<br>*Татар халык көйләренә тезмә тыңлау.*<br>*Өйрәнү:*<br>“Мин яратам сине, Татарстан! (Р. Рәкыйпов сүзл, Р. Андреев муз) |

| | |
|---|---|
| **Социаль үсеш** | Авыл буенча сәяхәт. Китапханәгә һәм башка оешмаларга бару.<br>Төркемдә “Туган як” почмагын тулыландыру. |
| **Экологик тәрбия** | Экологик әкиятләр сәхнәләштерү.<br>Табигатьне саклау буенча, әти – әниләр белән берлектә төрле чаралар уздыру.<br>Төрле хайваннар, үсемлекләр дөньясы, яшәү тирәлеге турында альбомнар булдыру. |

3. **Гомумиләштерү этабы** (апрель - май)

**Максат:** Теоретик яктан өйрәнелгән һәм практик яктан тикшерелгән материаллар белән төрле мероприятияләр аша тәҗрибә уртаклашу.

**Бурычлар:**

- презентация төзү;
- кургәзмә оештыру;
- авыл көненә багышланган чараларда катнашу.

***<u>Бурычларны тормышка ашыруда бердәм эшчәнлек</u>***

| Программа бүлеге | Эшләү алымы һәм формасы |
|---|---|
| **Танып белү үсеше** | Авыл урамнары, урман-кырларына, табигатенә багышланган “Минем авылым” исемле чагыштырулы - презентация тәкъдим итү. |
| **Сөйләм үстерү** | Авыл җитәкчеләре белән очрашып, әңгәмә оештыру. |
| **Матур әдәбият әсәрләре белән танышу** | Чынгыз Мусинның<br>✓ Туган туфрак.<br>✓ Авылым.<br>✓ Гузәллеккә омтылып<br>✓ Авылым таңнары<br>✓ Ата йорты<br>ырьләре белән танышу. |
| **Уен эшчәнлеге** | *Сюжетлы-рольле уеннар:*<br>Мин авыл җитәкчесе<br>Мин игенче<br>Мин савымчы<br>Мин төзүче<br>*Дидактик уеннар:*<br>Йорт хайваннары<br>Транспорт төрләре<br>Һөнәрләр<br>Сызым буенча авылымның урамын әйт.<br>*Әби – бабаларыбыздан күчкән җырлы-биюле уеннар:*<br>Челтәр элдем читәнгә<br>Нардуган<br>Күрсәт әле, Габдулла |

| | |
|---|---|
| | Хәрәкәтле уеннар. |
| **Нәфәсати тәрбия** | Чыңгыз ага Мусинның “Авылым таңнары” шигырен рәсемдә тасвирлау.<br>*Әвәләү*<br>Шигырьдә тасвирланган кошлар һәм хайваннарны әвәләргә. |
| **Кул эше** | Балалар рәсемнәреннән күргәзмәләр. |
| **Музыка тәрбиясе** | “Әгерҗем минем” (Габдулла Галиев, Әнвәр Закиров) җырын тыңлау һәм өйрәну.<br>Халык инструментларыннан торган “оркестр” оештыру. |
| **Социальләштерү үсеше** | Мәдәният йортындагы ярминкәләрдә, күргәзмәләрдә катнашу.<br>Авыл көненә багышланган чараларда катнашу. |
| **Экологик тәрбия** | Табигатьне саклау буенча төрле чаралар уздыру. |

**Йомгаклау.**

Туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, балаларга патриотик тәрбия бирүдә туган якны өйрәнү зур әһәмияткә ия. Проект шулай ук туган якның, туган авылның, аның буыннан-буынга сакланып калган гореф-гадәтләрен өйрәнү тәрбия эшендә зур ярдәм итә.

Шулай итеп, бүгенге көндә әхлаклы шәхес – Ватанга мәхәббәт хисе белән сугарылган, аның тарихы, мәдәнияте казанышлары белән кызыксынучы, милли символларга, изге урыннарга хөрмәт белән карауучы, җәмгыятькә һәм халыкка хезмәт итәргә әзер булган, әдәпле һәм итәгатьле шәхес тәрбиялим дисәң, эшне, беренчедән , балага кечкенәдән үк туган төбәге, халкы тарихын өйрәтүдән башларга кирәктер.

Икенчедән, әлбәттә, баланың күңеленә кешелеклелек, мәрхәмәтлелек орлыкларын салуга, тәрбия нигезенә халкыбыз тәрбиясе нигезләрен салу зур ярдәм булып торачак. Чөнки халыкның үткәнен, аның бетмәс – төкәнмәс күңел хәзинәләрен өйрәнгәндә генә, Ватаныбызны ярату хисләре тәрбияләп була.

Өченчедән тәрбия процессына ата – аналарны тарту да бу максатка ирешү юлларын якынайтачак. Шагыйрь дә юкка гына:

“Тәүге юлны бала күңеленә

Ата – ана тиеш үзе язарга”, - дип әйтмәгәндер. Тәрбиянең нигезе гаиләдә, эти - әни, әби – бабай катнашында салына, ул шулай дәвам итәргә дә тиеш.

Менә шуларны исәпкә алсак кына, без максатыбызга ирешә алырбыз һәм шулай ук балалар бакчасында тәрбия процессы да мәгънәле һәм нәтиҗәле булыр.

**Бөек Җиңүнең 78 еллыгына**
**багышланган әдәби кичә сценариясе.**
***(Фронтавик шагыйрь Фатыйх Кәрим шигырьләренә нигезләнеп әзерләнде)***

*Ягьфәрова Гөлназ Гамир кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*

*Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе мөдире.*

**Максат:** балаларның Бөек Ватан сугышы турыдагы белемнәрен тирәнәйтү, гражданлык һәм патриотик хисләр, туган җиренә, халкына карата горурлык хисе, ветераннарга, тыл хезмәтчәннәренә, сугыш чоры балаларына хөрмәт хисе тәрбияләү;

*(Слайд 1.* **«Бөек Җиңүнең 78 еллыгы”.** Талгын музыкага кереш олеш укыла)

(1- Беренче алып баручы, 2- икенч**е** алып баручы)

*1.* Әкрен генә җилләр исә,
Ел артыннан еллар үтә,
Ә халыкта тик бер теләк,
Гүя бердәм сулыш:
Мәрмәр һәйкәлләр каршында,
Катгый таләп:
Җирдә кабат
Кабынмасын сугыш!

*2.* Матурлыгы өчен бу көннәрнең
Кемнәр генә корбан булмаган!
Исемнәрен тарих безгә үзе
Саклап килә ерак еллардан!

*1 :* Нәкъ 78 ел элек безнең халкыбыз илебезне Герман фашистларыннан азат итте. Бу җиңү безгә җиңел генә бирелмәде. Миллионлаган солдатларның гомерләре өзелде. Бик күп солдатларның исемнәре дә билгесез, алар мәңгелек кә яу кырларында ятып калдылар. Аларга мәңгелек дан, аларның исемнәре мәңгелек.

(*Слайд 2. Иртәнге авыл куренеше.Еракта сабан туй аланы куренә)*

1. Язлар үтеп, ямьле җәйләр килде
Туган ягым күмелде чәчәккә.
41 нең җәен халык каршылый
Зур өметләр баглап киләчәккә.

**2.** 1941 нче елның 22 нче июнь таңы.

Бу иртә башка иртәләрдән бер нәрсәсе белән дә аерылып тормый иде. Шул ук сандугач сайрады, кошлар җырлады. Иртән авыл халкы көндәгечә көтүен куды.

Татарстанда бу иртә бәйрәм иртәсе иде. Бәйрәмнең дә нинди әле. Халыкның ел буе көтеп ала торган, тырыш хезмәттән соң үткәрелә торган сабан туе иде.

**“Печән өсте” көенә печәнче егетләр биеп чыга, аларга кызлар кушыла**

Менә шундый тыныч иртәдә илебезнең чигенә дошман бәреп керә. Бөек Ватан сугышы башлана.

**(Слайд 3. Левитан тавышы яңгырый.)**

**Алып баручы:** Бүгенге чарабызны Бөек Җиңүнең 78 еллыгына, Бөек Җиңүгә үз өлешен керткән ветераннарыбызга багышлыйбыз.

Әкрен генә «Солдатлар” җырының көе башкарыла (Роберт Әхмәтҗанов сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы)

**(Малайлар сугышчан формалар кигәннәр. Кызлар озатырга чыкканнар)**

**Сәхнәләндерү-күренешләр:**

**1нче күренеш. Солдат-атаны сугышка озату** *(сугышчы киеменнән, кулында –юл капчыгы).*

**Солдат-ата** (“Ант” Ф. Кәрим)

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә- балам . Син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм:
Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен , Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм.
**2 нче күренеш. Солдат-кызны озату** *(сугышчы киеме кигән кыз бала, кулында чемодан,карт әнисе озата)*
**Солдат-кыз** (*** Ф. Кәрим)
Соңгы тапкыр карыйм Иделгә,
Соңгы кабат күрим акканын,
Бәлки, бик тиз бире кайталмамын,
Сакланыр ул бары күңелдә.
Сакланыр ул соңгы хат кебек,
Искә алсам йөрәк сулкылдар;
Күз алдыма килер дулкыннар
Дулкыннарда кайнар ак күбек.
Син борчылма, күңел, яз килсен,
Кыр казлары кайтыр күлләргә,
Без кайтырбыз туган илләргә,
Башлар гына исән-сау булсын.
**3нче куренеш. Солдат-егетне озату (**сугышчы киеменнән, аны чиккән кулъяулыклар, чәчәкләр тоткан кызлар озата)
**Солдат-егет** ("Дусларга " Ф. Кәрим)
Мин вокзалда, ашыгып, соңгы тапкыр
Казан кипятогын агыздым,
Котелогым тулды... Күңелем тулды,
Кайчан күрешербез тагын без.
Канатланып оча зур эшелон,
Күксел төтен кала таралып;
Ачык вогон...Пушка, танкларга
Мин часовой булып барамын.
Соры шинелемнең итәкләрен
Җилфердәтә шаулап искән җил;
Ышанычлы, сөйгән улың булып,
Мин сугышка барам, туган ил.
*(Сугышка китүчеләр хушлашалар экрен генэ чыгып китэлэр)*
**Җыр. "Герман көе" Залялов Фэрхэн.**
**Алып баручы:** Китәсе кеше китеп бетте. Авыллар бушап калды.
**(Слайд 4. Сугыш вакытындагы өй эче. Ана һәм балалар өйдә мәш килеп йөриләр)**
**4нче күренеш - өй күренеше.**
**Кечкенә бала:** Әни безнең әти җиңеп кайтачак, әйеме?
**Ана:** һичшиксез балам.
**Кечкенә бала:** мин буген шигырь өйрәндем,хәзер сөйлим
Дошманнар килә,

Илгә куркыныч;
Мендем мин атка,
Кулымда кылыч.
Атым ярсыган,
Кылычым үткер,
Син, ярсу атым,
Әйдә, утка кер.
Таптыйк дошманны,
Тере калмасын;
Немец каскасы
Җирдә аунасын.
**Ана:** булдыргансың балам. Әтиеңә шулай көч биреп тор яме.
**5нче күренеш. Әтисен сугышка озаткан зуррак бала әнисе белән сөйләшә**
**Бала** (“Кайтыр әткәң” Ф. Кәрим)
“Нурын сибә кояш,тама тамчы,
Ерганаклар ага,әнкәем;
Тагын җитте бу яз, нигә кайтмый,
нигә кайтмый инде әткәем.
Тиздән безгә матур кошлар кайтыр,
Берсен-берсе куып уйнарлар,
Тәрәзәгә кунып алар миннән:
-әткәң кайттымы?-дип сорарлар.
Мине якын иткән бу кошларга
Ни дип җавап бирим, әнкәем?
Тагын җитте бу яз, нигә кайтмый,
Нигә кайтмый инде әткәем?..”
**Ана:**
Көт аны, көт сөйгән әткәеңне,
Ул да сине шулай сагына;
Я поездда, яки сомолетта
Очып кайтыр бер көн янына.
Ерткыч солдатларны куып беткәч,
Бер кояшлы көннең таңында,
Бик ерактан, сомолетта очып
Кайтыр әткәң, кайтыр яныңа.
**6нчы күренеш – бию**
**( Слайд 5. Ут сүнә, ут сүнгән арада уйнаучылар чыгып утыра .“Землянка” музыкасы яңгырый. Сугышчылар ял итә. Һәр кеше үз эше белән шөгыльләнә. Ут хат язучы солдатка төшә.**
**1. Хат яза – (Адель)**
**Хат язучы солдат** *(“Ватаным өчен” Ф. Кәрим)*
Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.
Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;

Үзем үлсәм, балаларым кала,
Минем гомерем булып,Ватаным.
Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул- Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

**2. Винтовка  чистарта (Владислав)**

Буш минутта прикладыма салып
Окопларда язган җырымны,
Туп гөрселдәп торган җирләрдән
Сезгә сәлам итеп җибәрәм.

**3. Шинель чистарта (Данил)**

(*"Соры шинелем" Ф Кэрим*)
Яттым исә, күкрәгемә ябам
Шинелемнең йомшак итәген;
Дошманнарны куа барган чакта
Итәкләрен канат итәмен.
Сугыш утларында көеп беткән
Өстемдәге соры шинелем-
Авыр елда туган улы итеп
Биргән бүләге ул имемнең.

**4. Аякка перевязка ясый   (Ильдан, Гузэл)**

Аягымнан кайнар каным ага,
Кар өстендә кала эзләре,
Син шаһит бул, кояш, язгы кояш,
Аккан каннарыма тезләнеп,
Мин ант итәм: соңгы тамчы каным,
Күкрәгемнең соңгы сулышын,
Бөтенесен сиңа, сиңа бирәм,
Ватанымның изге сугышы!
Җиргә тамган безнең һәр тамчы кан,
Кан түгел ул – матур ал чәчәк,
Алар безнең изге җиребездә
Бәхет гөле булып үсәчәк.

**5. Баянда "Хуш авылым" көе уйнала.**

**Беренче алып баручы**

Лачын кебек баһадирларыбыз, сугышка киткән хатын-кызларыбыз бер-бер артлы шәһәрләребезне азат иттеләр, Европа илләрен фашистлардан азат итә-итә, Берлингача данлы сугыш юлы үттеләр. Бик күпләре тиңдәшсез батырлыклар күрсәтеп  ятып калдылар.

Ә хәзер, хөрмәтле иптәшләр, хөрмәтле ветераннар, хөрмәтле кунаклар!

Сугыш кырында ятып калганнар өчен, сугыштан соң алган яралардан вафат булганнар өчен, хәзерге чорда хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булганнар өчен, инде олы яшькә җитеп гүр иясе булган ветераннар өчен бер минутлык тынлык.

**(Җиңү- Левитан сөйләве, артттан чәчәкләр, шарлар сәхнәгә аталар)**

1. Җиңү килде җирне нурга күмеп,
Шатлык белән күзне чылатып.

Килде ул көн — горур күкрәкләрдә
Орден-медальләрне чыңлатып.

2. Бөек Җиңүгә 78 ел! Илебез азатлыгы өчен көрәшкән солдатларны онытмыйк.
Исәннәрнең кадерен белик
Үлгәннәрнең каберен белик!
Бөек Җиңүгә 78 ел дип
Шатлык белән тибә йөрәкләр.
Тормышыгыз матур, күңелегез тыныч
Гомерегез озын булсын,
Безнең, сезгә шундый теләкләр.

**Икенче алып баручы**

Хөрмәтле ветераннар, тыл батырлары, сугыш чоры балалары, бүгенге көн яшьләре һәм балалары! Бөек Җиңүнең 78 еллыгына багышланган кичәбез ахырына якынлашты.Тагын бер тапкыр Жиңү көне белән котлыйбыз сезне! Күкләребез аяз, дөньяларыбыз имин, көннәребез тыныч булсын!

"***Матур булсын бу тормыш !" җыры белән кичәбез тәмамлана.***

**5-7 яшьлек балалар белән патриотик тәрбия бирү буенча шөгыль**
**"Минем кече Ватаным"**

*Гәрәева Флүрә Миннефаиз кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*Красный Бор авылы "Төремкәй" балалар бакчасы муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе мөдире.*

**Максат:** Кече Ватан турында элементар күзаллауларны формалаштыру,балаларның танып белү эшчәнлеген оештыру.

**Актуальлеге:** баланы әхлакый-патриотик тәрбияләү нигезендә аның әхлакый хисен үстерү ята. Кечкенә баланы туган илгә мәхәббәте аның иң якын кешеләргә – әтигә, әнигә, бабайга, әбигә мөнәсәбәтеннән башлана. Бу тамыр аны туган йорты һәм якындагы тирә-юнь белән бәйләүче, ә өлкәннәрнең, бигрәк тә якыннарының үрнәге бала шәхесен үстерүдә зур әһәмияткә ия.

**Бурыч:** балаларныңтуганавылтурындакүзаллауларынформалаштыру;
- балаларда туган авылына мәхәббәт һәм үз гаиләсенә, йортына, балалар бакчасына бәйлелек тәрбияләү;
- табигатькә һәм бөтен тереклеккә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру;
- балаларны халык иҗаты әсәрләрен тыңларга һәм аларның мәгънәсен аңларга өйрәтү.

**Методик алымнар һәм чаралар:** уен, күрсәтмә материал, сүзлек өстендә эш, математиканы кабатлау, сораулар, әдәби тел, үсендерү - мактау.

**Дәрес барышы:**

**Тәрбияче:**

Хәерле иртә балалар!
Хәерле иртә миңа
Хәерле иртә сина,
Хәерле иртә безгә,
Хәерле иртә сезгә!

- Балалар хәлләрегез ничек? Әйбәтме? Без бүген сезнең белән сәяхәткә барачакбыз.

Башта әйтегез әле - нәрсә ул Ватан?

**Балаларның җаваплары:** Ватан ул безнең әти –әни,Ватан ул безнең өй,Ватан ул безнең туган авылыбыз, Ватан ул без яши торган Красный Бор авылы.
**Тәрбияче: Туган ил каян башлана?**
Туган илем башлана
Үзем яшәгән өйдән.
Туган илен яратыр
Ата-анасын сөйгән.
Илдә булыр иминлек,
Гаилә булса ныклы:
Әби-бабай,әти-әни
Һәм дәвамлы-оныклы.
Оныклар күреп үсәр
Олы кешегә хөрмәт.
Әби-бабайлар өйрәтер
Бәхет башы,дип,хезмәт.
Тулы,матур гаиләдә
Үсәр лаеклы буын.
Яратыр ул Туган илен,
Урманын,җирен,суын.
"Туган ил каян башлана?"-
Сорый онygым миннән.
- Әби-бабаң,әти-әни,
Сеңелең белән синнән-
Башлана безнең өйдән

- Шигырь ошадымы сезгә балалар?Менә шигырьдә туган ил ул үзебездән, йортыбыздан, гаиләдән башлана диелгән, туган илен яраткан кеше анын суын, җирен, табигатен яратыр ди.Әни бергенә булган кебек, туган илебез дә бер генә була.

Балалар, без бик матур авылда, таулары, елгалары,урманнары, күлләре булган авылда яшибез.
- Ә авылыбызның исеме ничек соң?

**Балалар:** Безнең авылыбыз - Красный Бор.
**Тәрбияче:** Нинди соң ул безнең Красный Бор авылы? Авыл белән танышу өчен әйдәгез безсезнең белән сәяхәткә китәбез.Минем тылсымлы тартмамбар, нәрсә бар икән аның эчендә. Ковер самолет икән бу.Әйдәгез хәзер ковер самолетка утырып авылыбыз буйлап сәяхәткә китик. (Утыралар).
Син, ковер самолет, оч, безне күктә йөрт
Югарырак, югарырак күтәрел, тыныч,тыныч, селкенмә
Курыкма, балалар, бик яхшы утыралар!
Түбән,түбән төшегез,тыныч, тыныч кына төшегез!
- Менә без җиргә төштек,
Рәхмәт сиңа ковер самолет

- Туган җир...Туган авыл. Йөрәккә нинди якын, кадерле сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезебез урнашкан кадерле туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Кая гына барсак та, нинди генә матур урыннарны күреп сокланcак та, туган төбәгебезнең гүзәллеген берни дә алыштыра алмый. Авыллар... Аларда безнең үткән тарихыбызның бер өлеше, халыкның моңы, кайгы-шатлыгы, куанычлары һәм сагышлары. Аларның кайберләре бик борынгы,

икенчеләре шактый соң барлыкка килгән. Һәрберсенең үз үсеш тарихы, үз даирәсе, үз мохите, үзенең данлыклы кешеләре бар. Шуның өстенә авыллар милләтебезгә, халкыбызга җиң сызганып хезмәт итүче кадрлар бирә торган изге урыннар. Авыллар гөрләп яшәсә, милләт, халык яшәр, үсәр һәм көчәер.

- **Менә безнең беренче тукталышыбыз** – авыл тарихы музее. (балалар авыл тарихын чагылдырган алҗбомнар, фотографияләр карыйлар)

- Безнең Красный Бор авылына XVII гасырның икенче яртысында Иске Пьяный Бор авылыннан күчкән руслар нигез салган. Алар балык тоту, игенчелек, урман кисеп сату, терлекчелек, тимерчелек, аучылык, сәүдә һәм бурлаклык белән шөгыльләнгән. Чулман елгасыннан бишәр потлы җәен балыклары тотканлыклары билгеле. Авылдагы пароходлык конторалары бинкалары архитектура истәлекләреннән санала. Авылда бер православие чиркәве булган һәм аның каршында ирләр чиркәү училищесы эшләгән.

**Бирем. "**Борынгы һәм хәзерге әйберләрне тап".

- **Менә безнең икенче тукталышыбыз.** Безнең яратып йөри торган нарат урманнары. Нарат урманнары безнең авылыбызны өч яктан уратып алганнар.Бу урманнар гаҗәеп матур, искиткеч саф һавалы.

- Балалар нарат урманында ниләр үсә?
- Урманда нәрсәләр яши?
- Без урманда үзебезне ничек тотарга тиеш?

Балалар җаваплары.

**Бирем:** Бу билгеләр нәрсәне аңлата? (Табигатьтә үз-үзеңне тоту турындагы билгеләр).

**"Аю-бүре" җырлы, биюле уены.**

- **Менә безнен өченче тукталышыбыз –** Чулман елгасы.Чулман елгасы белән күп кенә тарихи вакыйгалар бәйле. Красный Бор авылы турында Агыйдел һәм Чулман елгалары бурлаклары очраша торган булган. Хуҗалары аларга монда хезмәт хакы түләгәннәр. 1901 елда бөек рус язучысы А.П. Чехов үзенең хатыны СССРның халык артисткасы О.Л. Книппер-Чехова белән Чулман елгасы буйлап Уфага ял итәргә баргандаКрасный Борда тукталып төн кунып чыгалар. Гражданнар сугышы елларында Н.Г. Маркин житәкчелегендәге сугыш флотилиясе Чулман елгасында Красный Бор авылы янында 7 дошман корабеле белән сугышалар. Бу сугышта "Ваня" судносына снаряд тиеп зарарлана. Ут судноның боеприпаслар урнашкан олешенә килеп җитә башлый, шунда Н.Г. Маркин "Барыгыз да борттан чыгыгыз!" дигән команда бирә, ә үзе сугышны дәвам итә. Шулай итеп команданың яртысы исән кала. Маркинның патроннары бетә, граната алып боеприпаслар люгына ташлый. Чулман дулкыннарында һәлак булган коммунист, комиссар Маркинга 25 яшь кенә була.

Безнең Чулман елгабыз, белгәнегезчә, балыкларга бик бай.

- Сез нинди балыклар беләсез, балалар?

**"Балык тоту" уены.**

- **Менә безнең дүртенче тукталышыбыз –** Һәйкәлләр. Һәйкәлләр кешеләр, яки күптән булган вакыйгалар хөрмәтенә салына.Безнең балалар бакчасы каршында урнашкан һәйкәл Ватаныбызны данлап, аның өчен гомерләрен биргән кешеләр хөрмәтенә урнаштырылган. Чулман елгасы ярындагы һәйкәл акгвардиячеләр белән сугышта һәлакбулган Гранданнар сугышы герое Идел флотилиясе комиссары Н.Г. Маркинга куелган. Һәйкәлләр ярдәмендә без үткән вакыйгалар турында беләбез, 9 май көнне Бөек Ватан сугышында илебезне саклап, чит җирләрдә ятып калган кешеләрне искә алабыз.

**Бер минут тынлык.**

- **Менә безнең соңгы тукталышыбыз.** Бу кайсы җир балалар?

- Безнең “Теремкәй” балалар бакчасы.
- Әйе, балалар, бу безнең бакчабыз. Безнең балалар бакчасына 1956 елда нигез салынган. Ә 1975 елда бакчабыз яңа бинага күчкән. (Балалар бакчасы тормышыннан презентация карыйлар)

**Балалар “Төремкәй” турында җыр башкаралар.**

- Безнең сәяхәт тәмам. Буген сәяхәттә без ниләр курдек?Кайларда булдык?

Балалар җаваплары.

- **Әфәрин! Булдырдыгыз. Бүгенге эшчәнлектә актив булганыгыз өчен рәхмәт.**